ТАТАРСТАН МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ
Г. ИБРАГИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ
УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕНЕҢ ТАТАР МИЛЛИ-МӘДӘНИ
АВТОНОМИЯСЕ

# ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙ

## Заман күзлегеннән бер караш

Казан

2015

МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ ТАТАРСТАНА
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени Г. ИБРАГИМОВА
АКАДЕМИИ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
УЛЬЯНОВСКАЯ ОБЛАСТНАЯ ТАТАРСКАЯ
НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ

# ГАБДЕЛЬДЖАББАР КАНДАЛЫЙ

## Через призму современности

Казань

2015

УДК 821.512.145(о82)
ББК 83.3(2Рос=Тат)я43
Г 12

Печатается решением Ученого совета
Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

*Проект осуществлен в рамках гранта
Министерства культуры Республики Татарстан*

**Редколлегия**

*К.М. Миннуллин, И.Г. Гумеров, Р.Г. Галиуллин, Р.Ф. Сафин*

**Научный редактор**

*Р.Ф. Харрасова*

**Составители**

*Ф.Ф. Хасанова, Л.Ш. Давлетшина*

**Г 12** **Габдельджаббар Кандалый: через призму современности** / Ф.Ф. Хасанова, Л.Ш. Давлетшина; под ред. Р.Ф. Харрасовой. – Казань: ИЯЛИ, 2015. – 240 с.

ISBN 978-5-93091-186-2

Сборник отражает историю и современное состояние изучения творчества татарского поэта Габдельджаббара Кандалый (1797–1860). Здесь представлены статьи, освещающие жизнь и творчество Г. Кандалый в различных аспектах, воспоминания потомков поэта, некоторые переводы его стихов на русский язык.

Для студентов, преподавателей и всех, кто интересуется вопросами татарской поэзии и литературы в целом.

**ISBN 978-5-93091-186-2**

© Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, 2015

## ПО СЛЕДАМ НАШИХ ПРЕДКОВ…

В последнее десятилетие в Ульяновской области проводится большая работа по увековечению памяти знаменитых земляков. Их имена присваиваются улицам, устанавливаются памятники, мемориальные доски, издаются их книги.

Общественная организация «Ульяновская областная татарская национально-культурная автономия» в соответствии с проводимым в регионе в этом направлении мероприятиями осуществляет большую работу для сохранения в памяти поколений выдающихся татарских деятелей.

Начиная с 2008 года установлены памятники поэтам Кул Гали, Хади Такташу, бюсты Габдулле Тукаю, Закиру Кадыри, в г. Ульяновске названы улицы в честь Б. Тарханова – создателя первого татарского театра в Симбирске в 1910-е годы, Г. Тукая – классика татарской поэзии, З. Кадыри – видного общественного деятеля начала XX века. Открыты мемориальные доски в честь Файзуллы Туишева в Новомалыклинском, Сахаба Урайского в Старомайнском, Габдуллы Шамукова в Чердаклинском, Азата Курчакова и Галимзяна Насырова в Цильнинском районах. По инициативе автономии принято решение о занесении в Галерею портретов знаменитых симбирян Г. Шамукова – народного артиста СССР и Габдельджаббара Кандалый.

– В текущем году совместно с Ульяновским государственным университетом и Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ проведена Международная научно-практическая конференция, посвященная виднейшим местным меценатам XVIII–XIX вв. Акчуриным с приглашением ученых, гостей из г. Казани, Крыма и Турции. В работе конференции участвовали потомки Акчуриных, впервые за 100 лет.

– В последние годы идет работа по сбору материалов к изданию книги «Татары Симбирско-Ульяновского края».

– Татары Ульяновской области гордятся тем, что в нашей области родился, жил и писал свои прекрасные произведения,

практически первые светские стихи в татарской литературе – Габдельджаббар Кандалый.

– Исполком автономии десять лет назад учредил литературную премию имени Г. Кандалый для местных писателей, пишущих на родном языке. За эти годы лауреатами областной литературной премии стали члены Союза писателей Татарстана Гакиль Сагиров, Рифкать Хисмет, Иделбике, Равиль Шафигуллин, член Союза журналистов России Ирек Сайфиев, кандидат исторических наук Рамзия Вильданова, поэт Шафик Иматдинов. Несколько лет назад в краеведческом музее г. Димитровграда прошла конференция по ознакомлению с творчеством великого нашего земляка. Во многих школах татарских сёл на уроках и на внеурочных мероприятиях учащихся знакомят с его стихотворениями, проходят конкурсы чтецов среди школьников.

– В 2015 году исполняется 155 лет со дня смерти великого татарского поэта.

– По инициативе автономии в области принято решение о занесении портрета поэта в Портретную галерею выдающихся личностей Симбирской губернии – Ульяновской области. Установлена новая ограда на его могиле, совместно с Институтом языка и литературы им. Г. Ибрагимова (г. Казань) проведена Межрегиональная научно-практическая конференция, посвященная ознакомлению наших земляков с его творчеством.

*Р.Ф. Сафин,*
*Председатель Исполкома Общественной организации «Ульяновская областная татарская национально-культурная автономия»,*
*член Общественной палаты г. Ульяновск*

## СҮЗ БАШЫ
## «Улыр иршад белән ир шад»

«Туры юл күрсәтү белән ир шарт булыр», дип белдергән Габделҗаббар Кандалый… Чиктән тыш белемле, яңача карашлы, тирәлеккә һәм катып калган нормаларга каршы барырга җөрьәт иткән рухани. Бунтарь холыклы, ирек сөйгән инсан. Хатын-кызны пьедесталга күтәргән, гүзәллегенә мәдхия җырлаган, гаиләдә һәм илдә бәхетле итү теләге белән янган ир. Баласын күз нуры кебек күреп, сөйгән, аерылышу хәсрәтеннән картайган ата. Йөрәгеннән ташыган мәхәббәт хисен яшермәгән, аларны тезмәләргә салган, үз чорында шигъри сүзне Рәсәйнең татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә яңгырата алган шагыйрь. Хәтта язганнары бик нык югалуга, таралып бетүгә карамастан, мирасы ул заманнар өчен чагыштырмача күләмле сакланган каләм иясе. Димәк, сүзе халык күңеленә якын булган, тыңланган, сөйләнгән, телләрдән – телләргә, илләрдән – илләргә күчкән, шәхесе йокыдагы кешеләрне уятып җибәргәндәй иткән.

Г. Кандалыйның кабатланмас поэзиясе, бүгенге көн китап сөючеләрне генә түгел, әдәбият мәйданында ат уйнатканнарны да таңга калдыра. Барлык әдәбият белгечләре дә Габделҗаббар Кандалыйның мәгърифәтчелек әдәбиятына зур борылыш ясаган күренекле фигура икәнлеген таный. Узган гасыр башында ук Г. Рәхим «Татар әдәбияты тарихы»нда аның хакында, дөньяви мәхәббәтне ачыктан-ачык тасвирлавы белән, борынгы шагыйрьләр арасында аерым бер урын тота, дип язган һәм аны саф татар телле үрнәкләр калдыручы итеп ассызыклаган була.

Кандалыйдан соң иҗат иткән һәм халык арасында шулай ук популярлашкан каләм ияләре дә аның исемен тоныкландыра да, халык күңеленнән оныттыра да алмый. Г. Чокрый шигырьләренең теле шактый чуар, гади укучыга аңлаешсызрак булса, әле соңрак әдәбият мәйданына килгән Ә. Уразаев Кормаши әсәрләрендә гомумсхемалы сюжетлар өстенлек итә, М. Акмулла шигъриятендә беренче планга мәгърифәтчелек идеяләрен уздырган социальиҗтимагый тематика чыга, ә менә Кандалый иҗаты тематик

планда да, эчтәлеге ягыннан да киң, күләмле, форма ноктасыннан бай, төрле; ул кулланган образлар мәйданы – зурлыгы белән шаккаттыра; иң мөһиме: шагыйрь җир мәхәббәтен күкләргә күтәрә.

Дөрес, алда аталган шагыйрьләрнеке белән Кандалый әсәрләре арасында билгеле бер янәшәлекләр уздырырга яисә, аларга таянып, әдәби күчемлелек проблемасы хакында сөйләргә булыр иде. «Әдәпкә вә әдәбиятка хилаф җирләрен» билгеләвенә карамастан, Кандалый традицияләрен беренчеләрдән булып һәм чын-чынлап Тукай дәвам итә. Ул «Шигырьләребез» мәкаләсендә гасырлар дәвамында татарларның әдәбиятка игътибарсызлыгы – камил үрнәкләрне сакламавы турында сөйли. Исемнәре һәм иҗатлары билгеле булган шагыйрьләрнең тәссаувыф бабында язуларын, искелекне күп катыштыруларын һәм шул сәбәпле халык тарафыннан артык игътибарга алынмауларын әйтә.

Һәрбер каләм иясенең мирасыннан яңа фикер, форма, образлар эзләп мавыккан совет чоры галимнәре тарафыннан башка төрки әдәбиятларда хәзергәчә ныклы һәм актив урта гасырчылык традицияләренә бераз бәя киметелде сыман. Һичшиксез, образлар системасы, сюжетлары һ.б., беренче чиратта, борынгы мифологиядән, төрле эчтәлектәгерәк, юнәлештәгерәк тамырлары да булган ислам әдәбиятыннан, башка диндәге халыкларның мистик карашларны чагылдырган сүз сәнгатьләреннән килгән һәм Аллага мәхәббәтне данлаган суфичылык шигъриятен кайберәүләрнең дини әдәбият белән тәңгәлләштерүе, поэтик юнәлеш буларак бәяләп бетермәве я булмаса дини-дидактик сүз мирасындагы образлар системасының тормышчан да, заманча да әсәрләр иҗат итәргә яраклылыгын танымаулары күзәтелде. Шушы шартларда Г. Кандалыйның яңа рухтагы, эчтәлектәге шигъриятенә дә берьяклырак бәя бирелде, әдәби күчемлелек проблемасы тиешле игътибарга алынмыйча, шагыйрь мирасын үзенә кадәр иҗат итүчеләрнекеннән кискен аерып куярга омтылыш ясалды шикелле.

Никадәр генә тормышчан язмасын, күпсанлы шигырьләрендә җир мәхәббәтен сурәтләү үзәктә тормасын, Г. Кандалыйның әдәби мирасында саф суфичылык әсәрләре дә бар иде; хәтта Сәхипҗамал, Фәрхи, Шәфгый кебек гүзәлләргә мәхәббәт хисләрен җиткергәндә, Г. Кандалый суфичылык әдәбиятының барлык мөмкинлекләрен эшкә җикте, аңа хас образлар системасын булдыра алганча мул файдаланды. Бигрәк тә кыска күләмле тезмәләрен гади халык телендә дә иҗат иткән Г. Кандалый поэзиясендә гарәп-фарсы алынмаларының күплеге әнә шуның белән

аңлатыла да. Суфичылык поэзиясендә актив кулланышта булган төрле тип конструкцияләр, бигрәк тә фарсы теле аша кергән изафәләр Яңа заман шагыйре поэзиясендә дә традицияләр тотрыклыгы хакында сөйли. Шагыйрьнең галимнәр поэма дип атаган, әмма асылда хикмәтләр циклы булган «Рисаләи-л-иршад»ны искә төшерик. Мөхәммәд пәйгамбәргә мөнәсәбәтле строфалардан башланып, Габделҗаббар мулла вәгазьләре рәвешендә дәвам итә ул, һәм төрле социаль төркемнәрне, бигрәк тә яшьләрне туры юлга тартуны, шуның белән бәхетләренә юл ачуны күздә тота:

Нәсыйхәт тыңлаган углан
Зәляләтдин үзен йолган,
Сәгадәтне алга куйган –
Һидайәт эчидә улан.

Кеше күңелен, Аллага мәхәббәтне ачкан суфичыларда гүзәллек тасвирлары, шул гүзәллекне чагылдырган исем төшенчәләрнең, эпитетларның зур күпчелеге Г. Кандалый поэзиясендә очрау гаҗәпләндерми. Бу урында аның каләменнән төшкән матур шигъри юлларны китереп тә узасы килә:

Җәмал базарларын гиздем,
Нәчә йирдә җәмал сиздем,
Нәзар дәрьяларын гиздем, –
Ки сәндин тапмадым әүла.

Г. Кандалыйның суфичылык әдәбиятыннан, суфичылык юнәлешләреннән хәбәрдарлыгы, шул юнәлешләрне нигезләгән шәхесләрне олылавы, бу юнәлештәгеләргә хас дини ритуалларны белүе мәхәббәт шигырьләрендә дә чагылыш таба.

Сәнең өчен күп егладым җомгада,
Хәер бирдем Баһаветдин хуҗага, –

дип башлый ул исемсез бер шигырен, суфичылыкның Нәкышбәндия тармагын нигезләгән Баһаведдин Мөхәммәд ибн Борһанеддин әл-Бохаравины телгә алып. Белгәнебезчә, әлеге орденга караучылар дөньялыкны бөтенләй инкарь итмиләр, аны рәсми ислам тәгълиматы белән каршы килми, диләр, Аллага иман китерүне ясалма ритуалларда чагылдыруга каршы төшәләр, хисфикердә ихласлылыкны яклыйлар. Һәм Көнчыгышның Нәваи, Җами кебек татарлар арасында бик танылган шагыйрьләре дә шушы караштa тора. Бу төр бәяләмә Г. Кандалыйны да өлешчә характерлый алыр иде.

Кайбер галимнәр, Г. Кандалый гади хезмәткә түбәнсетеп караган, гыйлемлелекне югары күтәргән, шуның белән үз чорында

башкалардан аерылып торган, диләр һәм моны белемлелекне югары күтәргән мәгърифәтчелек идеологиясе белән генә бәйләп карыйлар. Бу төр карашларның тамыры да ераклардан, суфичылык поэзиясеннән үк килә. Белемне Аллага якынайта дип санаучы узган заман шагыйрьләре аны бар нәрсәдән югары күтәрә, чөнки ул кешегә рухи үлемсезлек алып килә. Г. Кандалый да гади хезмәтнең кирәклеген аңлаган билгеле, ул да ашаган-эчкән, һәм, белем дигәндә, тормыш өчен кирәкле белемнәрне генә түгел, дини мәгърифәтлелекне дә күздә тоткан. Рухани шагыйрь башкача фикер йөртә дә алмый. Кандалыйдан сүзебезне раслаучы уңышлы мисаллар китереп була:

Иген икмәк – вирер икмәк,
Мәшәкать лә михән чикмәк.
Гыйлемлелек – максудә йитмәк,
Һәр ике дөньяда әйкан.

Бу урында Г. Кандалый белән кем бәхәскә керә алыр икән? Игенче хезмәте ул, никадәр генә мактаулы булмасын, хәтта бүген дә авырлардан санала, дөнья алып бару өчен дә, файдасыннан мәшәкате күбрәктер.

Суфичылык әдәбияты белән бәйләнешләре ничек кенә тыгыз булмасын, әлбәттә, Г. Кандалый – инде бөтенләй башка шагыйрь, аның әдәби иҗеге норматив шигърият кысаларыннан күпкә читкә чыга. Борынгылар рухында язган саф суфичылык әсәрләре булуга да карамастан, иҗатының зур өлешен җир кызларына ирештерергә теләгән мәхәббәт хисләре алып тора. Ир каһарман аларны үзендәге хисләрнең сафлыгына ышандырырга тели, кочакларында тәненә һәм җанына ял аласы килә. Бу образ, адресатларның төрлелегеннән чыгып карасаң, гыйшыкбаз сыфатында күз алдыбызга килә, әмма тоемчан һәм игътибарлы укучы шигырьләргә авторның бер генә объектка булган көчле ярату хисләре салынганлыгын аңлаячак. Тасвирлар охшашлыгы, кабатланган конструкцияләр, янып яраткан лирик мин, хатын-кызны гади крестьян кочагыннан тартып алырга омтылыш… – Г. Кандалый иҗатының буеннан-буена килгән мотивлар. Сәхипҗамал исемле кызга карата бер кабынган хисләр шагыйрьне гомер юлларыннан ахыргы тукталышкача озата бара сыман.

Г. Кандалый иҗат иткән лирик герой кыз күңелен яулауда рухани авторитетлар, әйтик, рәсүлебез Мөхәммәдкә, аның арадашчылыгында Алла ярдәменә өметләнә. Тасвир объекты үзгәрде дип кенә, ягъни Аллага булган көчле мәхәббәт хатын-кызга

булган мәхәббәткә алмашынды дип кенә, сурәтлелек мәйданы тулаем алмашына алмый. Суфи шагыйрьләрнең Аллага гыйшыкны чагылдырган үз әсәрләренә дә икепланлылык хас булу борынгыдан килгән тел-сурәтләү чараларының киләчәк чорлар шигъриятенә үтеп керүенә ишекләрне киң ача.

Совет татар әдәбияты тарихында гына түгел, рус әдәбият белемендә дә уртагасырчылык идеяләренә, шул чорның тасвир чараларына кимсетебрәк карау күзәтелде. Хәтта суфи эчтәлектәге шигырьләр авторы дип танылган Гомәр Хәйям әсәрләрен дә кайберәүләр, образларның асмәгънәлелеген исәпкә алмаганлыктан, объектив аңлатмады, авторны шәрабка, гыйшнушка, хатын-кызга мәхәббәт хисләре җырлаучы сыйфатында гына тәкъдим итте, тәрҗемәчеләр шигырьләрендәге төп мәгънәләрне үз телләрендә адекват җиткерә алмады. Бүгенге көндә белгечләр Хәйямның теләсә кайсы темага язылган әсәрләренең Коръән сурәләре белән тыгыз бәйләнешлелеген, еш кына алардагы эчтәлекнең образлы чагылышы, алга таба үстерелеше икәнлеген ачыклады.

Элекке чорларда белемне дини мәктәпләрдә алган татарлар дөньяви һәм дини гыйлемнәрнең кайсын да мәгърифәтлелек чагылышы дип бәяләде, хәтта заманга лаек алгарыш пропагандаланган егерменче гасыр башында да дини гыйльмияткә каршы кискен көрәш алып барылмады, каләм ияләре, нигездә, милләтне торгынлыкта яшәтергә азапланган иске карашлы муллаларга, сорыкорт ишаннарга каршы көрәште. Инде игътибарны Г. Кандалый иҗатына да киңрәк планда карап һәм дөньяви, һәм дини эчтәлектәге әсәрләр язганлыгын күрсәтергә, шул ук вакытта халык күңеленә якын хисләрне тасвирлаган тормышчан шигъриятенең ныграк таралганлыгына, сакланганлыгына юнәлтергә кирәк.

Татар әдәбиятында традицияләрнең тотрыклылыгын Г. Кандалыйдан соң шигърият мәйданына килгәннәрнең бер адым артка атлаулары да күрсәтеп тора. Нишлисең, зур талантларны беркайчан үзләре исән вакытта бәяләп бетермәгәннәр, аларны аңларлык башка каләм ияләренең туу кирәк булган. Андый шагыйрьләрне безгә егерменче гасыр башы биргән.

XX гасыр башында мәхәббәт лирикасын яңадан җанландырып җибәрүдә Г. Тукай зур роль уйнаган. Иҗтимагый моңнар җырчысы буларак ныграк бәяләнүенә карамастан, Г. Тукай мирасында күңел лирикасы гаять зур урын алып тора. Гаилә кормаган, хатын-кызларны үзенә артык якын җибәрмәгән Тукайның лирик герое, Г. Кандалыйныкы кебек үк, тормышка тәнкыйди һәм ак-

тив позициядә тора. Әле тәүге мәхәббәт, гаилә темасына язылган әсәрләреннән саналган «Бәхет юк, аның исеме генә бар» шигырендә үк Тукай, үзенең остазы кебек, кем белән яр булу мәсьәләсен күтәрә һәм, сөйгәнең тиң булырга тиеш, фикерен уздыра.

Г. Тукай башлангыч чор иҗатында Кол Гали, Харәзми, Сәгъди, Хисам Кәтиб кебек авторитетлар шигъриятендәге һәм фольклордагы мәхәббәт тематикасын тагын да тирәнәйткән, тормышка якынайткан, аларга хас поэтик алымнарны кулланган Г. Кандалый юлыннан китә, баштарак иҗади стилизация яисә тәрҗемә өчен һәм гомумән үрнәкләрне көнчыгыш поэзиясеннән сайлый, әмма соңыннан европа-рус шигъриятенә йөз тота.

Г. Кандалый шигъриятенең татар поэзиясенә гасырлар дәвамында ясаган шифалы тәэсире турында озаклап сөйләргә булыр иде. Шунысы сөенечле: бу йогынты бүгенгәчә дәвам итә. Кол Гали белән Г. Кандалыйны татар «Мәхәббәтнамә»сенең башында торган ике фигура дип кистереп әйтергә була. Зур сулыкларның нинди булуы чишмәләрнең аларны нинди су белән тулыландырып торуына да бәйле булган кебек, бүгенге татар шигъриятенең көче борынгылар каләменең егәренә дә барып тоташа, һәм безнең бу урында горурланырлыгыбыз да, мактанырлыгыбыз да бар!

Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән бу җыентык, бер яктан, Г. Кандалый исемен мәңгеләштерү йөзеннән башкарылса, икенче яктан, аның иҗатына заман фәне биеклекләреннән торып бәя бирү омтылышы белән дә аңлатыла. Иң мөһиме: әлеге китапны язышуга Кандалыйның күпсанлы җирдәшләрен дә тартып, китапны төзүчеләр иҗатының һаман да халыкка якынлыгын, укылышлылыгын, әлеге шәхескә якташларының мөнәсәбәтен күрсәтергә дә теләде.

Бай һәм озын тарихлы татар әдәбиятына күпсанлы талантлар бүләк иткән Сембер халкына, аның җитәкчелегенә, Г. Кандалый иҗатын яктырткан фәнни-гамәли конференция уздыруны, шуңа багышланган тупланма чыгаруны оештыруда активлык күрсәткән Рәмис Фарук улы Сафинга Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелеге, аның күпсанлы галимнәре, татар милли җәмәгатьчелеге исеменнән зур рәхмәтен җиткерә. Әгәр аларның теләге, ихтыяры, матди ярдәме булмаса, мондый саллы хезмәт дөнья күрә алмас иде.

Ким Миңнуллин,<br>Рифә Харрасова

# Беренче бүлек
# Г. КАНДАЛЫЙ ҺӘМ ТАТАР ФӘНЕ

## Г. КАНДАЛЫЙ ИҖАТЫ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ: әдәби-тарихи мәсьәләләр кысасында

*Ф.З. Яхин*

**Гомуми караш.** Габделҗаббар Кандалыйның (1797–1860) иҗат мирасына бәйле уртак бер фикри бәяләмә электән яши. Ул да булса, академик М. Госманов сүзләре белән әйтсәк, «аның әдәбиятыбыз үсешенә керткән бәхәссез яңалыгын ихлас күңелдән тәкъдир итә килү»дән гыйбарәт [1: 5]. Бу фикернең чыннан да дөрес, хакыйкать булуын раслау өчен, галим монографик пландагы мәкаләсен Г. Кандалыйның 1988 елгы шигырьләр җыентыгында тәкъдим итте. Шагыйрьнең әсәрләрен туплау кебек гаҗәеп катлаулы эш белән беррәттән, М. Госмановның төп анализлары, әдәби-тарихи мәсьәләләрне дә чишүе аерым мактауга лаеклы. Мәкаләсендә ул әдәбият галимнәренең фикерләренә бәйле әле бәхәсләр кузгата, әле аларның дөреслеген раслый, эзләнә, төшендереп яза. Капитал хезмәт.

Г. Кандалыйның иҗат мирасы XIX йөздән бирле татар әдәбиятын өйрәнүче галимнәр тарафыннан бәяләнеп килenә. 1869 елда Салихҗан Күкләшев «Татарская хрестоматия» китабын Казанда бастырып чыгара һәм анда шагыйрь иҗатына берникадәр урын бирә [2: 109–110]. Әмма шагыйрьнең иҗатына төп игътибарны юнәлткән галим Каюм Насыйри булды һәм ул «Кырык бакча» [3: 47–56], «Фәвакиһел-җөләса (фил-әдәбият)» [4: 556–583] китапларында Г. Кандалыйның әсәрләренә шактый урын бирде.

Тормыш юлын өйрәнү һәм иҗатын бәяләү эшен XX йөзнең 20–30 нчы елларында К. Иртуган [5: 30–32], Исхак Бәхтиев [6: 13–14], Г. Ибраһимов [7: 256; 338–339; 369–370; 387; 463]

мәкаләләрендә башкарылды, Г. Рәхим һәм Г.Гобәйдуллин аңа үзләренең «Татар әдәбияты тарихы» китабында төп урыннарның берсен бирде [8: 296–313], 1927 елда шагыйрь хакында Г. Сәгъди «Кандалый хакында» мәкаләсе белән чыгыш ясады [9: 29]. Аларга кадәр әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче Җәмал Вәлиди 1912 елда Оренбургта басылып чыккан «Татар әдәбияты барышы» китабында [10: 93–98] әдипнең иҗат мирасын бәяләгән, Г. Тукай, «Исемдә калганнар» истәлегендә тугыз яшьлек малай чагы икәнлеген искәртеп, Г. Кандалый шигырьләрен укуына бәйле, «бик яратып укыйм һәм аңларга тырышам», аларның тәэсирендә «хатыннардан көлә идем» [11: 25] дип язып узган иделәр.

Һәм, гомумән, әдәбият тарихын өйрәнүче галимнәр тарафыннан этрафлы яктыртылган Г. Кандалый иҗаты хакында нинди дә булса яңа сүз әйтү мөмкин дә түгел сыман. Мәктәп һәм вуз дәреслекләренә кертелгән бу иҗатны күз алдына китермәгән кеше юктыр. Аның «Мулла белән абыстай», «Сәхипҗамал» әсәрләрен кайсы татар белми дә исенә алмый? XIX йөзнең башында шушындый бөек татар шагыйренең яшәгәне һәм иҗаты белән халкыбызны яңача уйлый белергә, урта гасырлардан килгән дини-клерикаль карашлардан аерылырга юл күрсәтүе аерым игътибарга һәм олылауга лаеклы. Г. Кандалый – әдәбият һәм фикер үсеше тарихыбызның чыннан да зур мәртәбәсе.

Аны, иң тәүдә, «бунтарь», «гыйсьянчы», диләр. Һәм ул чыннан да шундый. Г. Кандалый, хәтта күп кенә бунтарь шагыйрьләрдән аермалы буларак, хистә, фикердә бөтенләй башка. Аның лирик героенда тынгысыз, буйсынмаучы, горур йөрәк. Әмма ул саф хисләргә ия йөрәк.

Дөрес, Г. Кандалый «бозык хисләр иясе», эротик шагыйрь буларак та билгеле. Ул интим күренешләрне шигъриятендә каләм очына да, куе сурәткә дә алмый калдырмый. Боларны ул мыскыллау, көлке-сарказм өчен дә куллана. Үтә нечкә хисләргә бай иҗатка андый тупаслык килешеп бетмидер сыман. Әмма укучыны шушылай хәйран итә алуы, икенче яктан, көчле бер әдәби алым да түгелме? Тик хисләрнең нечкәлеге әдәбилектә нечкәлек түгел әле ул, анысын да аңларга, бәяләргә тиешбез.

Г. Кандалыйны, иҗатындагы шушы үзенчәлекләре өчен, һаман да акларга тырышабыз. Ә мондый очракта аның башкача да язарга мөмкин булын исәпкә алмыйбыз. Әгәр дә ул үтә конкрет, хисси-женси тойгы-кичерешләр белән бәйле, мәсәлән: «Чү сәнә, абзый, чү сәнә, / Кысыбрак яхшы сөйсәнә, // Сөйгәчтин – күңлем

үсә лә, – / Дәйүб уйнар күшки кызлар» («Мәгъшукнамә») [12: 387] кебек шигъри юллар урынына, искечә суфийана хис-тойгылар тулы әсәрләр иҗат итсә, шигъриятенең сафлыгы белән без аны һәммә шагыйрьләргә өлге итәр идек.

Дөресе шул: Г. Кандалыйны нечкә әдәбиятның саф өлгесе дип санарга хакыбыз юк. Аның мәртәбәсе башка якта, иҗаты әдәби кысаларны ваткан, аңардан бик күпкә читкә чыгып киткән. Шушы сәбәпле хәтта диндарлыгы да юк кебек аңлашыла. Г. Кандалый шигырьләрендә «мужикчалык», «телле авылчалык», әйтергә кирәк, «дөньяви диваналык» күп. Бу – үртәп-үртәшеп чарланган күңелнең «егетлек» итүе. Шушы үзенчәлеге Г. Кандалыйны нечкә әдәбият вәкиле буларак күзалларга мөмкинлек бирми. Әмма хисләре кайвакытта шулкадәр нечкәрә, икенче урында күңел кыллары авыр аһәңнәр белән, тупас яңгырап куйганда – аһ итәсең. Болай булырга тиеш түгел сыман! Хәер, мондый сыйфат XX гасыр татар шигъриятенә дә хас. Һ. Такташ та, Р. Харис та, Р. Гаташ та, Р. Зәйдулла да – шундыйрак шагыйрьләр. Бу үзенчәлек – хәзер безнең татар әдәбиятының традицияләреннән берсе. Хәтта, чигенми әйтергә кирәк, Г. Кандалый тудырган шигъри рухның кичә дә, бүгенге көндә дә татар әдәбиятында яшәвен барларга мөмкинлек бирүче әдипләр алар.

Г. Кандалыйдагы темалар, мотив рәвешен алып, Г. Тукайның да мәхәббәткә һәм дин әһелләренә багышланган әсәрләрендә (әлбәттә, бары тик юмор һәм сарказм белән сугарылганнарында) кабатланмый калмаган. Димәк, ул «авылчалыклар», «егетлекләр» татар шигъриятенә Г. Кандалый иҗаты белән килеп кергән һәм, тамырланып, аның иҗат мирасы тәэсирендә үсеш алган. Бу тарихи һәм мәдәни фактларны, тормышыбыз һәм әдәбиятыбыз хакыйкатьләрен без юкка санарга һәм инкарь итәргә тиеш түгелбез. Г. Тукайның юмор-сатира тамыры кайдан килгәнлеге Г. Кандалый иҗатын белгән-өйрәнгән кешегә аңлашылып тора. Татар милли шигърият җене бер шагыйрьдән икенчесенә күчеп яши, аларны бөек ясый.

Г. Кандалыйның иҗат мирасы зәвык ияләренә ошамый, алар тарафыннан яратылып бетелми. Әмма бу әле «аның талантын кире кагабыз» дигән сүз түгел. Сүз юк, Г. Кандалый бөек талант иясе, шагыйрь булган. Аның таланты нечкә әдәбият кысаларын бозуга, какшатуга, яңа, заманча, тормыш күренешләрен сурәтләүгә корылган әдәбият тарихын башлап җибәрү өчен мәйданга чыккан. Ул тормышчан әдәбиятны тудырган. Бу яктан

аның бөеклеген һичкем кире кага алмас. Бу бөеклек тормышның үзен, аның ваклыкларына, шәхескә бәйле булуын, шәхси һәм шәхсани үзенчәлекләрдән торучы яшәеш икәнлеген конкрет кешеләргә мөнәсәбәтле сурәтләүдә кыю әдәби адымнар ясап ачыла барган.

Ә моның хикмәте дә бар.

Татар суфичылык әдәбияты урта гасырларда абстракт хакыйкатьләрне тасвирлауга һәм ачыклауга күчә. Әгәр дә XII гасыр мистик шагыйрьләре Ә. Ясәвидә дә, С. Бакырганида да хакыйкатьләрне ачу һәм ачыклау юлы шигърияттә шәхси һәм конкрет тормыш фактларына нисбәтле булса, инде XIII йөздә, Кол Гали әсәрен мисалга алабыз, хәтта Шәрык бөекләре Җ. Румида һәм Ф. Гаттарда да ул шулай – башкача, тормыштагы шәхси, конкрет фактлар исәпкә дә алынмыйча, абстракт поэтик фикерләүгә тәмам күчеп бетү күзәтелә. Моны – әдәби конкретлыктан әдәби абстракцияләргә күчүне – гомумтөрки әдибе Ә. Югнәки алданрак, Ә. Ясәвигә кадәр үк башлый, югыйсә. Хәер, инде Ә. Ясәви үзе дә конкрет тормыш фактларын сурәтләүдән абстракт фикер йөртүгә таба кискен борылыш ясаган әдипләрнең берсе булган, чөнки тормыш хакыйкатьләре, конкрет күзәтүләрдән бигрәк, абстракт фикерләү юлы белән тирәнрәк ачыкланыла һәм ачыла. Аннары, абстракт фикерләү юлы мистик аң үсешенә зур мөмкинлекләр ача. Илаһият гыйлеменең үсеш алуы шәхси, үз тормышың фактларыннан ерагаю, аерылу һәм абстракциягә, абстракт төшенчәләр дөньясына күчүгә бәйле. Шул сәбәпле суфичылык чорында әдәбиятта аерым, шәхси тормыш фактларын, бигрәк тә тормышның үзен, аның очраклы хәлләрен сөйләүне һәм тасвирлауны фикер йөртү алыштыра. Вакыйгалар һәм күренешләр гомуми, хәтта типик вакыйгаларга һәм күренешләргә бәйле тасвир кылына. Абстракт фикер йөртү хакыйкатьне ачуга, аны асылына үтеп ачыклауга корыла һәм аның белән табылган бер-бер фикер, мәкальдәге кебек, тормышның һәр очрагын аңлату өчен яраклы була бара. Моны без әдәбиятның *хакыйкатьне эзләү юлына керүе*, *танып-белүгә корылуы* дип тә атый алабыз. Менә шуңа да ул дәвер әдәбияты үгет-нәсыйхәт итүдән, фикер йөртүдән, фәлсәфә тудырудан, тормышның һәр очрагына ярашлы мәгънәләр тәкъдим итүдән гыйбарәт. Шуның аркасында ул тарихыбызны «әдәбиятның үгет-нәсыйхәтчелек дәвере» дип атыйбыз.

Татар әдәбияты тарихында, абстракт мәхәббәт, абстракт фикер, абстракт вакыйга, абстракт күренеш, абстракт мөнәсәбәтләр

челтәреннән күчеп, конкрет тормышны сурәтләүне «Собәтелгаҗизин»дә Суфи Аллаһияр кузгатып ала. Ә. Ясәви заманында әдәбият ничек абстракт төшенчәләргә күчә барса, С. Аллаһияр аны кабат конкретлыкка кайтару адымын ясый. Бу кайтару-кайту адымы, шулай итеп, әдәби абстракцияләрдән әдәби конкретлыкка күчү юнәлешен ала (дөрес, аның иҗатында бүтән төрле әдәби башлангычлар да бар, әмма, алар темадан читтә булганга, монда башкалары хакында сүзне кузгатмавыбыз хәерле). Ул үзенең ничек суфи булып китүен, байлыктан, гаиләдән баш тартуын, ата-бала, шәхес һәм гавәм мөнәсәбәтләрен конкрет сурәтләүдә бирә. Инде аңарда ук абстракциядән конкретлыкка күчеш көчле тәэсир итү һәм тәэсирләнүгә корылган. Бу алым исә әдәби конкретлаштыруның перспектив булуы хакында сөйли. Моның өчен, тормышны яхшы белү белән бергә, сурәтләү осталыгы да аерым әһәмияткә ия. Автор үзенең тормышны өйрәнүдә туган фикерләрен түгел, бәлки конкрет хис-тойгыларын сурәтләүдә тәэсир көченең югары булуын сизми-сиздерми калмый. Конкрет күренешләрне, вакыйгаларны һәм шәхесләрне сурәтләүдә татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни тагын да алга китә. Бу алым, әдипләр һәм укучылар тарафыннан хупланып, гомуми әдәби юнәлешкә әверелә. Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллин аны «элегик дәвер» дип атый.

Г. Утыз Имәни үзенең хатыннарына, балаларына, үлү вакыйгалары белән бәйле, әлбәттә, сагышлы мәрсияләрен багышлый. Әдәби тасвир өчен, ул конкрет тормыш детальләрен файдаланырга мәҗбүр була. Бу юнәлештә татар әдәбияты тарихында иң уңышлы иҗат эшен алып барган шагыйрь Г. Чокрый булган. Бездә мәрсия жанры әдәбиятны абстракциядән, фикер бирү юлыннан тасвирга, тормыш күренешләрен конкрет, очраклылык белән бәйле сурәтләүгә алып чыккан. Әмма абстракт әдәбиятны типиклаштыру алымнарына корылган әдәбият белән бутарга ярамый. Абстракция, типиклаштырудан аермалы буларак, гомумиләштерми, бәлки – аерымлый. Аерымлау исә хакыйкатьне аңлауга мөмкинлек ача. Конкретлаштыру да, анысы, гомумиләштерми-типиклаштырмый, бәлки очраклы күренеш, вакыйга, тормыш детальләрен бер-берсенә үзара бәйлелектә карый. Шушы сәбәпле конкретлаштыру әдәби күренешне һәм вакыйгаларны сурәттә бай ясый, шәхесләрне тормышчан детальләрдә ачык күрсәтергә мөмкинлек бирә. Монда «каләм каш», «ай йөз» кебек метафорик эпитетлар файдаланылса да, «бакча алмасыдай бит

очы», «кызыл чия иреннәр» отышлырак кебек тоела. Авторлар, детальләштерүдән, тормышчан төсләр һәм эпитетлар файдаланудан тыш, үз хисләрен төгәл һәм үтемле-ачык сурәтләргә корырга мәҗбүр булалар. Чөнки конкретлык детальләрнең үзара бәйле булуын таләп итә, тышкы күренешләрне эчке тойгыларга, ягъни күзаллауларга, хисләргә бәйли. Шунлыктан шагыйрь «алма кебек» дидеме, җитмәсә ул кызарып пешкән һәм татлы да итеп әдәби сурәттә бирелсә, мантыйк таләбе буенча, әлбәттә, аны яки тешләп алырга, иясә кабып йотарга теләр һәм шушы хисне тууны әсәрендә автор бирми калдыра алмас. Менә шушы әдәби конкретлылыкка омтылыш Г. Кандалыйны бөек шагыйрь ясап кына калдырмый, бәлки эротик хисләр җырчысына да әверелдерә. Бу исә татар әдәбиятының элгәре чорда абстракт юнәлештә югары үсешкә ия булуы сәбәбеннән дә килә. Ә болар дини күзаллау кысаларына сыямы?

**Дин һәм Г. Кандалый.** Бу мәсьәлә тәмам ачык кебек. Аның «Мулла белән абыстае» (исемне әсәренә укучылары куйган) мәктәптән үк һәркемгә яхшы таныш. Җиңел истә кала. Көлке дә, шаян да. Татар укучысы андый әсәрләрне сөя. Шул көлкедән, шаянлыктан һәм шаяртудан бездә олы мәгънәләр табалар һәм андый әсәрләрдән тәрбияви мәгънәләрне бик теләп барлыйлар, аларны кабул итәләр. Милләт бәхете гүяки уен-көлкедә, шуклыкта, шаянлыкта. Безнең андый үзенчәлекләребез үзләреннән-үзләре килеп чыга. Мәгәре мәхәббәт мелодрамасына, игезәкләрнең аерылуына, ахырда ананың балаларын табуына, апа-сеңел, абый-эне табышуга сюжеты корылмаса, һинд киносы бездә сәер хисләр тудыра. Һинд фильмнарының мотивлары һәм вакыйга корылышлары башкача булмаска тиеш сыман. Шуның кебек татарда да бераз көлке, бераз уен, бераз драма, бераз юләрлек, бераз мәгънә һ.б. шундый «беразлар» зур соклану тудыра. Ул «беразлар»ның микъдары-үлчәме дә бар. Килеп җитмәсә, яки артыкка китсә – җаныбыз корый башлый. Г. Кандалыйның «Мулла белән абыстае» нәкъ менә шундый, «беразлар» татар чамасына туры килеп тора. Аны төрек, үзбәк – аңламас, әмма башкорт, казакъ, уйгур – кабул итәр.

Әдәбиятта конкретлаштыру образ-тасвирда әдипләрне ваклыкларга алып кереп китә. Һәммә детальнең әһәмияте арта бара. Алар үзара бәйләнештә тасвир ителә. Мондый детальле тасвир укучыны фикерләүгә этәрә. Күңел кабул иткән һәр күренеш, сыйфат, үзенчәлек яңа мәгънә тууга китерә. Әмма мәгънәләр

төрлечә туа, төрлечә бәяләнә. Берәүләр өчен алар кызыклы тоела, икенчеләрнең гайрәтен чигерә. Һәр очракта да тәрбиявиэстетик әһәмиятләре югары дәрәҗәдә кала.

Г. Кандалыйның һәр әсәре дини тәгълиматлар, әдәп-әхлак системалары белән кисешеп тора. «Мулла белән абыстай»дагы дини ашлар, йола буларак, көлкегә алынган кебек, дин әһелләренең дә шул ашлар өчен генә яшәүләреннән мәзәк ясала. Автор дини йолаларның башкача булырга, үзгәрергә тиешлеген таләп итми төсле. Монда иҗтимагый тәнкыйть югары, чөнки дин әһелләре татар халкының өске сыйнфый катламына әверелгән. Татар халкы ул чорларда чын мәгънәсендә клерикализм кысаларында яшәгән. Автор бу хакта турыдан-туры яза. «Мужикның сыртын игәүләп» дигәне – шул вакыттагы яшәү рәвешенә аңлы, ачык бәяләмә. Шуңа да әсәр совет чорында әдәбиятыбыз тарихы фәнендә бик сөенеп кабул ителде, идеологик тәрбиядә актив файдаланылды. Бу юнәлештә әдәби-иҗтимагый фикерне Г. Кандалый кебек үк югарылыкта XX гасыр башында Г. Тукай үстерә алды. Икесендә дә клерикализмга карата сарказм катнаш юмор, дин кешеләреннән көлү, яңача яшәү рәвешен эзләргә чакыру, иң хикмәтлесе – клерикализмның киләчәге юклыгын сиздерү.

Г. Тукай белән Г. Кандалый шигырьләре арасында бер гасыр чамасы ераклык бар. Аларның әсәрләрендә сурәтләнелгән вакыйгаларга нигезләнеп, «тормыш һаман да искечә калган, үзгәрә алмаган» дияргә мөмкин. Әмма Г. Кандалыйның авангард фикерле шагыйрь булганлыгын бу факт тагын да ачык белдереп тора.

Тарихи яктан Г. Кандалый XIX йөз башында ук җәдиди юнәлештә иҗат итүгә алынган. Г. Курсави ничек иҗтимагый фикер үсешендә җәдитчелекне нигезләсә, Г. Кандалый аңа ишекләрне әдәби фикер бирүдә ачкан. Дөрес, ул үзенең иҗат дәверендә суфичылык әдәбиятына хас булган абстракт юнәлешнең көчен барлау өчен «Рисаләи-Иршадийә», «Кыйссаи-Ибраһим Әдһәм» әсәрләрен язуга керешә. Бары тик аларда ул системалы рәвештә суфичыл юнәлешен тота алмый, үз әдәби юлына, конкретлаштыруга кире кайта.

«Иршадийә» әсәре дини әдәп кагыйдәләрен һәм төшенчәләрен конкрет алып барлауга, тәрбия, белем-мәгърифәт мәсьәләләрен күтәрүгә, авыр кара хезмәткә һәм аны башкаручыларга, байлыкны белемнән өстен күрүчеләргә карата инкарь, хәтта чиркану хисләрен тудыруга бәйле төзелгән. Конкретлаштырылган

һәм үзара бәйләнештә үстерелә барган ул фикер һәм хисләр асыллары белән «автор мине»нә, аның уй-кичерешләренә бәйле, шәхси-шәхсани рамкаларда ачыкланылган. Бу юнәлештә С. Аллаһияр кузгалышны башлап, Г. Утыз Имәни беренче адымнарны ясаса, Г. Кандалый аларны дәвам иттергән. XIX йөзнең соңгы чиреге татар җәдитче романистларында ул фикерләр, хисләр тагын да конкретлаштырылып сурәтләнелгән. Фикер бирүдә аларда яңалык юк та кебек, мәгънәләрдә Г. Кандалыйны кабатлыйлар төсле.

Г. Кандалыйның «Ибраһим Әдһәм»е беренче бүлегеннән үк абстракт сурәтләр белән, суфичыл фикер бирү юнәлешен тотып башланып китә. Әмма автор алга таба дини-суфичыл хакыйкатьләрдән бөтенләй дә аерыла, үз чорына бәйле, үз заманының әхлагын бәяләү белән кызыксынып, конкретлылык юнәлешен ала. Урта гасырлардан килгән абстракт сюжетны конкрет вакыйга-күренешләрнең тасвиры алыштыра. Бу алым Ә. Каргалый иҗатына да хас. Аның «Кыйссаи-әүлия»сендә әле абстракт суфичыл хакыйкатьләр тасвирлана, әле шагыйрьнең шәхси һәм конкрет иҗтимагый тормыш фактлары бәян ителә. Ике шагыйрьнең дә әсәрләре бу яктан охшаш алымнары белән укучыны мавыктыру көченә ия. Мондый әдәби-эстетик күренешләр татар әдәбиятының XIX йөздә, дөресрәге, XVIII йөзнең соңгы чирегеннән башлап, алга таба тәмам үзгәрә баруын, абстракт хакыйкатьләрне раслауга һәм сурәтләүгә корылган суфичыл дәвернең тәмам үтеп, сыйфатлары югала баруын күрсәтеп торалар.

**Суфичылык һәм Г. Кандалый.** Бу мәсьәлә шулай ук тәмам ачык кебек. Әгәр дә Г. Утыз Имәни фәндә тулысынча суфи шагыйрь буларак бәяләнсә, Г. Кандалый исә бар асылы белән дөньяви. «Иршадийә»сендә ул мистик карашларын тасвирласа да, җәннәт, тәмуг, Ахирәт көне, башкалары хакында үз күзаллауларын бирсә дә, боларны рәсми юнәлешкә бәйле мөселман кешесе буларак, иман тәгълиматы һәм шәригать чикләреннән чыкмыйча, конкретлыкта һәм бәйләнешле сыйфатларда тасвир итә, маҗараларга бирелми. Бу исә Г. Кандалыйның диндә ныклыгы, ачык фикерле, аңлы караштa булуы, һәммә нәрсәне тәнкыйди бәяләү аша кабул итә белүе хакында сөйли.

Суфичылыкны бездә «Аллаһыга мәхәббәт һәм шул мәхәббәт хисенә бирелү, аның белән генә яшәү» дип аңлыйлар, аңлаталар. Әмма, «Аллаһыга мәхәббәт» дигәндә, асылда ни-нәрсә күз ал-

дында тотылуы бөтенләй дә искә алынмый. Менә шуннан «әфләтүн мәхәббәте» рамкаларына суфичылыктагы «мәхәббәт» төшенчәсе куып кертелә. Әмма «әфләтүн мәхәббәте» белән «суфичыл мәхәббәт» – икесе ике нәрсә. Суфи шагыйрь Аллаһының мәхәббәтенә лаек түгеллеге хакында зар елый икән, бу әле аның «әфләтүн мәхәббәте» фәлсәфәсе белән яшәве дигән сүз түгел. Шуны ачык аңларга кирәк, суфи өчен Аллаһы тәгалә – хакыйкать ул. Шуңа да аны «Хак», «Хак тәгалә» дип уйлый. Бу хакыйкать – абсолют һәм аңа бары тик абстракцияләнү юлы белән генә якынаерга мөмкин. Тормышның конкрет күренешләре, вакыйгалары, шәхесләре һәм яшәешнең үзара бәйләнешле сыйфатлардан, детальләр берлегеннән гыйбарәт булуы аңа хакыйкатькә ирешергә, ягъни хакны-асылны танып-белүгә комачау итә. Ул алардан котылу юлын эзли. Моның өчен «гаиләдән китү», «тормыштан аерылу», «сөекле яр белән бергә калу», «кавышу» кебек халәт кичерү күңеленә ярдәм иткәнен белә. Иман – аның өчен хакыйкать юлындагы тәүге баскыч, ул исә – хакыйкатьнең барлыгына абсолют-тәмам ышанудан гыйбарәт. Иманлы кеше ялганны сөйләми, ялганга ышанмый, хакыйкатьне ялганнан аера белә. Һәрвакыт Хак белән булуны ул – иманлы яшәү, хаклыкка тугыры калу дип белә. Кеше иманын югалтса, яисә имансыз икән – ул хата сөйли, ялган белән яши.

Суфи – хакыйкатьне танып-белү юлында яшәүче кеше. Коллыкны да бары тик шул кысаларда гына аңлый. Суфи конкрет тормыштан күңел-аң белән абстракцияләнүгә бара. Шуның өчен ул тормышны «каһәрле», аның котретлыкта бары тик хатага гына китерүен, хакыйкатьтән ераклаштыруын күз алдына дөрес китерә. Суфилар күп кенә, төрледән-төрле хакыйкатьләрне ачканнар, дини мәсьәләләрне төгәл билгеләгәннәр һәм чишкәннәр.

Тарихи үсеш барышында суфичылык үзенең әһәмиятен югалта бара, чөнки ул җәмгыятьне тормыштан аерган, яшәешнең үзгәреше, кешелек алдында куелган мәсьәләләрнең конкрет чишелеш таләп итүе, сәясәтнең динне читләштерүе, фән-техника дәверенең башланып китүе, кешенең үз иҗат көченә таянырга омтылышы, рәсми диннең үзенең дә суфичылыкка каршы баруы – болар халыкның суфилардан читләшүен китереп чыгарган. Г. Кандалый шушы читләшү, хәтта аерылу, яңа иҗтимагый катламның барлыкка килеп, ныклы адымнар белән үсешен иҗаты белән раслаган, шушы яңа кешеләргә әдип буларак хезмәт итүне үз җилкәсенә алган фикер иясе шагыйрь булды. Моның өчен аңа

үтә катлаулы, үзенчәлекле характеры да хезмәт иткән. Абстракт фикер бирүдән конкрет тормыш материалын сурәтләүгә күчү аның чорында диннән китү буларак та аңлашылган. Хәер, ул хәзер дә ортодокслар тарафыннан шулай төшенелә. Дини-суфичыл төшенчәләрнең урта гасырларда тормышның һәр очрагы өчен универсаль белем, хакыйкать рәвешен алуы, шулай кабул ителеп файдаланылуы, инде заманалар үзгәреп, һәр тормыш очрагы кешедән мәсьәләләрне үзләренчә, аерымлы, үзенчәлекле хәл итәргә тиешлекне замана кешесе тоймый калмаган.

Г. Кандалый яшәгән чорда тормыш вакыйгалары шактый кискен җанланып киткән. Монда Е. Пугачев җитәкчелегендә восстание-күтәрелеш, Ватан сугышы һәм аларда милли көчләрнең катнашуы, фикергә, аңга тәэсире, милли хисләрне көчәйтүе генә түгел, җәмгыятьтә иҗтимагый активлык арта барган чор бу (монда табигать үзгәрешләре дә, мөфтият ачылып, дин кешеләренең мәхәллә тарафыннан сайлануы һәм нәзарәт алдында, имтихан тотып, җаваплылыкны үз өсләренә алулары да, сәүдә һәм җитештерү капиталына үсеш мөмкинлекләре табылу да, төп халык массаларының кискен ярлылануы да төп рольне уйнаган). Бай халыкка мулла белән абыстайны ашлы-сулы итеп асрау берни түгел. Байлыкта юмартлык булмый калмый. Әмма ярлы халыкта эшләр башкача тора. Хис-тойгылар да үзгәрә. Кискен ярлылана баруы, тормыш авырлыклары аңарда күңел кысынкылыгын тудыра. Ә. Каргалый «Кыйссаи-әүлия»нең беренче хикәятендә үзләренә дә ашарга булмаган Мөхәммәд Ансарины искә ала, мосафир һәм бер җимеш вакыйгасын бәян итә. Суфи буларак, аның гаиләсен өлге итеп, халыкны шагыйрь суфийана юмартлыкка чакыра. Г. Кандалый исә, киресенчә, мондый юмартлыкка кискен тәнкыйть белән чыга һәм бу очракта: «Кайсы гуманлырак?»– дигән сорау куярга мәҗбүр булабыз. Г. Кандалыйның «Мулла белән абыстае» кешелеклелек өлгесе түгелме? Мулла белән абыйстайның «мужик җилкәсен игәләве» кешелексезлек буларак бәяләнгән шул. Динме аларны моңа өйрәтә?

«Мулла белән абыстай»да сурәтләнгән күренешләр динисуфичыл идеаллар белән яшәүнең заманы үткән, инде актуаль түгеллекләрен ачык күрер, аңлар өчен, көчле этәргеч бирер. Яңа идеяләрнең, фикерләрнең мәйданга куелуы өчен, әлбәттә, яңа карашлар системасын тудырырга кирәк булган. Монда Диния нәзарәтенең суфичылыкны үзенең рәсмилеге белән кире кагуы

да аерым, игътибарга лаеклы, зур әһәмияткә ия. Рәсмилек белән һәрдаим каршылыкта яшәгән суфичылык яңа иҗтимагый шартларда үзенең актуальлеген тәмам югалта. Суфичылыкта рәсми дин даирәләре бидгатьлек, буйсынмаучанлык, башбаштаклык барлыгын яхшы тойганнар һәм белгәннәр. Суфи кеше үзлегендә танып-белүне алга чыгара. Яшәешен абстракцияләргә буйсындыруы, күңеле һәм аңы абстракт төшенчәләр белән коралланып, уйда һәм гамәлдә туктаусыз абстракт идеалларга тартылуы, максатта абстракт хакыйкатьне эзләве аны, әлбәттә, үзфикерле, серләрне төшенүчән, аңлы-зиһенле кеше иткән. Тормышның даимилеге, үзгәрешләрнең азлыгы, яңалыкларның бөтенләй диярлек булмавы, яшәешнең бертөрлелеккә корылуы суфичылыкка иң кулай шартлар тудырган.

Татарда сәяси-тарихи үзгәрешләр еш барса да, эчке иҗтимагый яңачалык 1742 еллардан, Оренбургның сәүдә һәм сәүдәгәрлек үзәгенә әверелүеннән башланып китә. Шәрык илләре белән сәүдә эшен татар үз кулына ала. Россиянең эчке сәясәтендәге татарга карата аз гына үзгәрешләр дә милли тормышта активлыкны тудыра алган. Халык клерикализмнан котыла барган. Көчле сәүдә һәм сәнәгать буржуазиясе барлыкка килеп, 1774 елдан ул үзен бердәм сыйнфый көч итеп күрсәтә дә башлый. Бу процесс, 1920 елларда Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов тарафыннан өйрәнелә башлап, әмма хәзерге фәндә берникадәр читтәрәк калдырылып, аңа бәйле гыйльми мәсьәләләрнең чишелмәве сәбәпле, аңлашылып та җитмәскә мөмкин, шунлыктан, Г. Кандалыйның яңа идеаллар тудырудагы эшчәнлеген тикшергәндә, тарихи материалга артык киң тукталу да мөмкин түгел.

Г. Кандалый иҗатында мәхәббәт – төп мәсьәлә, ул һәм динисуфичыл, һәм дөньяви. Аны төгәл ачыклап аңларга-аңлатырга тиешбез.

Башта ук билгеләп кую дөрес: Г. Кандалый өчен мәхәббәт ул – шәхси, интим хисләр чыганагы. Шигърият өчен тагын нәрсә кирәк? Хикмәт күңел фантазиясенә бирелүдә түгел, бәлки тормыш фактларын, аның күренешләрен һәм кешеләрен шигъри анализ, ягъни күңел фәлсәфәсе аша уздыруда. Г. Кандалый нинди дә булса фактны, сурәтне, бәяне кабатламый, бәлки күңел фәлсәфәсе аша аларны уздыра, үзенчә бәяли, менә шуннан яңа фикер, дөньяга карашның яңа рәвеше, системасы барлыкка китерелә. Суфи өчен мәхәббәт – хакыйкатькә тугрылык, аны аңлау, танып-белү, аңлату, шуның белән хакыйкатькә, ягъни Хак

тәгаләгә, Аллаһыга берегү мөһим булса, шул абстракт хакыйкать бу һәм теге дөньяларның серләрен аңа танытса, аны күңел рәхәтлегенә, Хакны тою шатлыгына ирештерсә, Г. Кандалый өчен дә мәхәббәт шундый ук рольне башкара. Бу мәхәббәт абстракт хакыйкатьләргә ирешү түгел, бәлки конкрет дөреслекне табу, аны аңлау-төшенү һәм аның һәммә яшәеш белән бәйле икәнлеген тоюдан-тойдырудан гыйбарәт.

Суфиның юлы дини тәгълимат кысаларына буйсындырылган. Ул әүвәле шәригатьне, ягъни үзенә кадәрле билгеле булган хакыйкатьләрне үзләштерә, аннары гына үзенең танып-белү юлын эзли, таба, шулай белемгә ирешә. Аның өчен шәригать – абстракт идеяләрне үзләштерү, ягъни, аңлау, кабул итү генә түгел, бәлки аларны гамәлгә, яшәү рәвешенә әверелдерү, ә тарикать – абстракт фикерләүгә өйрәнү, ягъни һәр яңа, үзенчәлекле хәлдән-халәттән абстракт шартларга, абстракциягә күчүгә, абстракцияләнүгә ирешә алу. Аңа ирешкән суфи мәгърифәтле, ягъни аңлы була. Аң дәрәҗәсе хакыйкатьне танып-белүдә өченче баскыч, югары урын, әмма соңгысы түгел. Суфи хакыйкать белән кушылырга тиеш, ягъни аны тоя, аңлата, белдерә алырга. Ул шушы хакыйкатьтә тәмам «эри», анда аның иске «мин»е юкка чыга, үзе дә башка төрлегә, саф, чиста, аңлы – абстракцияләнгән кешегә әверелә. Аңа конкрет дөнья һәм аның үзенчәлекләре берни түгелләр, ул алардан аерымлана ала. Шулай Әл-Газали, Фәраби, Әбугалисина, Яссәви, Нәкышбәнди һ.б. бөек галимнәр барлыкка килгән. Аларны конкрет белемнәр түгел, абстракт хакыйкатьләр кызыксындырган. Һәм алар бу юлда зур уңышларга ирешкәннәр. Ул абстракт хакыйкатьләр конкрет очраклар өчен никадәр яраклы? Абстракт белемнәр абсолют хакыйкать түгелләр. Абсолют хакыйкатькә алар да ирешә һәм аңарда «эри» алмаган, чөнки бу хәл мөмкин түгел. Менә шуңа күрә дә суфичылыктан кешелек баш тарта һәм абстракциядән конкретлыкка күчешне яклый. Г. Кандалый иҗаты менә шушы күчешнең татар әдәбияты тарихында ничек барганлыгын һәм беренче уңышлары нәрсәдән гыйбарәт булуын тарихи яктан ачыклап күрсәтеп тора. Ул әдәбитарихи фактлар күңел тарихыбызның сәхифәләрен ачарга да мөмкинлек бирә.

Г. Кандалый иҗатын дингә, дини әхлакка, дини әдәпкә каршы корылган әсәрләрдән гыйбарәт дип булмый. Ул – дөньяви, әмма суфи шагыйрьләрнең иҗатлары белән чагыштырганда

гына дөньяви, идеяләре һәм идеаллары нигезендә караганда – шул ук Ислам дине тәгълиматлары кысаларында, аңа хезмәттә чәчәк аткан иҗат. Сүз хәтта «Сәхипҗамал»ы хакында да бара, әмма гомумкешелек идеалларына тартылган әсәрләре дә юк түгелләр.

Тагын да шунысы әһәмиятле: мәхәббәт хисе суфи шагыйрьләргә ничек абстракцияләнүгә, абстракциягә бирелүгә ярдәм итсә, аңа илтүче юл булса, Г. Кандалыйга да нәкъ шул мәхәббәт хисе тормыш хакыйкатьләрен танып-белүгә юл ача. Әмма бу очракта аңарда хисләр конкретлылык белән аерылып тора. Чөнки алар Җир кешесенә юнәлдерелгән. Шуңа да шагыйрьнең күңеле чуар буларак күзаллана башлый. Ул әле Фәрхине сөя, әле Сәхипҗамалны, әле башканы. Күп очракта аның шигъри детальләре, метафора-символ-образлары да бертөрле. Аларда аерма юк. Хисләре даими дә түгел, вакытлы, хәтта очраклы, әмма шагыйрьнең ул хис-тойгылары тормыш чынбарлыгын ачыклауга, танып-белүгә хезмәт итә, шушы яклары белән мәдәни-тарихи-иҗтимагый кыйммәтләргә дә ия. Монда иң калку сурәтләнелгәне – белемле кеше надан адәмгә, мәгърифәт – наданлыкка каршы куела.

Г. Кандалыйның иҗат манерасы хакында М. Госманов болай ди: «Ул тормышта нәрсә бар – шуны яза, үзе күргәнчә һәм бәяләгәнчә яза» [1: 36]. Анысы, чыннан да, шулай. Г. Кандалый, лирик шагыйрь буларак, күңел кичерешләрен тасвир итә һәм алар аша, хисләренә таянып, дөньяны бәяли. Ә иҗатының реалистик иҗат буларак тоелуы аның тормышны конкретлыкта сурәтли белүеннән килә. Бу әдәбият өчен ул вакытларда иң зур уңыш иде. Г. Кандалый әсәрләрен үз күңел дөньясына, тойгыхисләренә таянып яза. Конкретлылык аның әсәрләрен тормышчан итә, хискә иярү образларны, күренешләрне, шулай ук әдәби детальләрне тәэсирле ясый. Алар исә, үз чиратларында, укучыда тагын да яңа хисләрне, тойгыларны уяталар. Шушы рәвешле Г. Кандалый хыялый әдипкә әверелә, хәтта дуамал кебек аңлашыла башлый. Бу исә аның әсәрләре романтизм белән сугарылган булу хакында да сөйли. Г. Кандалый чын мәгънәсендә романтик шагыйрь. Конкрет тормышны, бигрәк тә аның шәхси-шәхсани якларын хис-тойгылар белән баетып сурәтли белүе татар әдәбиятында яңа, дөньяви романтизмны тудырды. Хезмәт кешесенә карата тискәре бәяләре дә, авыр хезмәттән, кара эштән чиркандырулары да, хезмәт кешесен «мужик» дип

мыскыллап атаулары да Г. Кандалыйның романтизм вәкиле булуыннан килә.

Строфика ягыннан ул һаман да шул ук «Мөхәммәдияче» иде, әмма аның уңышы – татар халык җырларына хас әдәби образ һәм символларны файдалана белүендә, таба һәм иҗат итә алуында булды. Бусы исә шулай ук әдипнең таланты, тормышны яңача танып-белүе, яңача аңлатып язуы хакында сөйли. Дөньяви булсын, романтизм шагыйре булсын, суфичылыктан баш тартсын, әмма Г. Кандалый Ислам динен инкарь итүче дә, аны читкә кагучы да түгел иде. Аны Ислам мәдәнияте үсеше генә әдәбиятка бирә алган. Ул рәсми Ислам тәгълиматлары кысаларыннан читләшми, әмма үзенең дөньявилыгы белән бунтарь-бидгатьче шагыйрь буларак тоела. Бу безнең, аның укучыларының, дини дә, дөньяви да гыйлемнәребез, күзаллауларыбыз, Г. Кандалыйныкы белән чагыштырганда, фәлсәфи-мәдәни яктан караганда, шактый аермалы булуы хакында гына сөйли.

ӘДӘБИЯТ

1. Госманов М. Габделҗаббар Кандалый: Бер гомердә ике чор // Кандалый Габделҗаббар. Шигырьләр һәм поэмалар / Төз., текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, кереш сүз авт. М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

2. Кукляшев С. Татарская хрестоматия / Диваны хикәяте татар. – Казань, 1859.

3. Насыйри К. Кырык бакча. – Казан, 1880.

4. Насыйри К. Фәвакиһел-җөләса (фил-әдәбият). – Казан, 1884.

5. Иртуган К. Шагыйрь Габделҗаббар Кандалыйның кыскача тәрҗемәи хәле һәм шәхси хәяты // Безнең юл. – 1927. – № 8.

6. Бәхтиев И. Шагыйрь Габделҗаббар Кандалый турында // Яңалиф. – 1929. – № 13.

7. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. Т. V. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

8. Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. Икенче басма. – Казан, 1925.

9. Сәгъди Г. Кандалый турында // Безнең юл. – 1927. – № 9.

10. Вәлиди Җ. Татар әдәбияты барышы. – Оренбург, 1912.

11. Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда. Т. V. Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

12. Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҮСЕШЕНДӘ Г. КАНДАЛЫЙНЫҢ УРЫНЫ ҺӘМ РОЛЕ

*Х.Й. Миңнегулов*

**«Ни язганым, ни дигәнем – җәелеп беткән илләрдә».** Әдипләр төрле була: берәүләрнең әсәрләрен яшьләр яратып укый, икенчеләрен – хатын-кызлар, өченчеләре исә укымышлылар күңеленә хуш килә... Әмма төрле буын, төрле катлам укучыларның барысын да кызыксындырган, җәлеп иткән каләм әһелләре чагыштырмача сирәк очрый. Г. Кандалый – әнә шундыйларның берсе. Инде менә ул – XIX гасырның урталарыннан бирле татар укучыларының яраткан шагыйре. Аның ялкынлы мәхәббәт шигырьләре, гуманистик рухлы әсәрләре халыкның күңел хәзинәсенә әверелгән.

«Сәхипҗамал» поэмасының лирик каһарманы үз мәхәббәтенең Уфа, Казан, Сембер, Сарытау, Самара, «Нижний», Сарапул, «Орынбур», Бәләбәй һәм башка татар төбәкләренә, ягъни Идел-йортка таралуы, «фаш булуы» хакында сөйли. Бу исә – Кандалый әсәрләренең автор исән вакытта ук бөтен татар дөньясына мәгълүм булуына ишарә. Аның шигырьләре халык арасында еш кына фольклор әсәрләре кебек таралганнар, укылу, күчерелү һәм басылу барышында төрле үзгәрешләргә дә дучар булганнар һәм вариантлары да барлыкка килгән. Аерым юллары һәм парчалары хәтта тәмам фольклорлашып та киткән.

Отыйм дигәндә – отылдым,
Тотыйм дигәндә – тотылдым, –

дип яза Г. Кандалый бер поэмасында. Шәхси тормышында, бәлкем, шулайдыр. Әмма әдәби иҗатында шагыйрь һич тә «отылмаган» да, «тотылмаган» да. Киресенчә, ул үзенең һәр юлы, һәр әсәре белән укучыларның күңелен яулаган да яулаган. Бу исә – каләм әһеле өчен иң зур җиңү!

**«Якутлар табыладыр вакыт берлән...»** Г. Кандалый 1797 елда хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районы Иртуган авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Бу авылның элек Иске Кандал дип йөртелүе мәгълүм. Шагыйрьнең әдәби кушаматы да шуңа мөнәсәбәттә алынган.

Габделҗаббарның тәүге укытучысы әтисе була. Аннары ул Мораса, Кизләү, Кышкар һәм Идел-йорттагы кайбер башка мәдрәсәләрдә белем ала, шәкертлекнең күп кенә баскычларын үтә.

Г. Кандалый 1824 елда туган авылында мулла булып тора, балалар укыта.

Кандалыйның, үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, төрек, рус, чуваш телләрен дә белүе, татар әдәбиятыннан һәм фольклорыннан, Шәрык мәдәниятеннән яхшы хәбәрдар булуы мәгълүм.

Укымышлы һәм шигъри сәләтле Г. Кандалый табигате белән хис-тойгыларга бай һәм тынгысыз холыклы, туры сүзле һәм хөр фикерле, горур кеше була. Мөгаен, шуңа күрәдер гомер юлында ул төрле кыенлыкларга очрый: мәдрәсәләрдән куыла, эшеннән алынып тора, гаилә тормышында да үкенеч-кайгыларны башыннан еш кичерә, әләк аркасында ике еллап төрмәдә дә утырып чыга[1].

...Бу тәкъдир дигәнең нидер? –
Изеп, йәнчеп, орыр йиргә;
Бары тыкмасын ул гүргә, –
Китермәсен әҗәлләргә.
Кеше дигән дә мәзлумдыр (*җәберләнгәндер. – Х.М.):*
Йөгерер, егылыр, торыр,
Башыны ташларга орыр,
Сөренмим дип әҗәлләргә...
Икенче бер шигырендә автор болай ди:
И кояшым, чыгармусән болытдин?
Алырмусән бәне бу ялкын-утдин?!

Г. Кандалый 1860 елда 63, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр, Мәхмүд Болгари яшендә вафат була. Кабере – туган авылында.

**Иҗат мирасы.** Кандалый язу-сызу, әдәби иҗат эше белән бала вакытта ук шөгыльләнә башлый. Ул ярты гасырлык иҗат юлында зур күләмле поэмалардан алып икеюллык шигырьләргә кадәр иҗат итә.

Г. Кандалыйның иҗат мирасы шактый бай һәм катлаулы. Шагыйрь үз иҗатын традицион рухлы һәм әхлакый эчтәлекле әсәрләр язудан башлый. Аның «Рисаләи-л-иршад» («Тугры юлга күндерүче китап») исемле зур күләмле поэмасында, мәсәлән, кешеләрнең үз-үзләрен ничек тотуы, башкалар белән ни рәвешле мөнәсәбәткә керүе хакында сүз бара. Автор, татар, гарәп, фарсы һәм төрки телләрдәге күп төрле әсәрләрдән файдаланып, тормыш, яшәеш хакындагы күзаллауларын бәян итә. Укучысын гыйлемле булырга, олыларга «гыйззәт», «хөрмәт», «кечеләргә... шәфкать» итәргә, нәфескә иярмәскә чакыра. Кандалый да бу

дөньяны, нәкъ Мәүла Колый кебек, бизәнеп, ясанып һәм кыланып кешеләрне алдый торган «карый» (карчык) белән чагыштыра. «Котадгу белек»нең лирик каһарманы үз гомерен кәеф-сафа, ашау-эчү белән бушка уздыруы хакында яза. «Рисаләи-л-иршад» авторы да гомерне хайван кебек «йимәк-эчмәк» белән гамьсез уздыруны кискен тәнкыйтьли.

Сәгъди-Сараиның «Гөлестан»ында гөл янында торган туфракның да хуш ислегә әверелүе хакында әйтелә. Шушы ук мотив Кандалый поэмасында да бар. Автор фикеренчә, яхшы кешеләр белән аралашсаң, үзең дә яхшырырсың. Кыскасы, «Рисаләи-л-иршад» – һәм исеме, һәм эчтәлеге белән адәм балаларын игелеккле, тугры юлга чакыручы китап.

«Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасы да Г. Кандалыйның башлангыч чор иҗатына карый. Ул тулысынча сакланмаган.

Ибраһим Әдһәм – диндарлыгы һәм изгелеге белән Урта гасыр Шәрык дөньясының атаклы шәхесе. Аның хакында күп әсәрләр язылган. Поэмада Ибраһим Әдһәмнең сәяхәте, аның белән булган гыйбрәтле хәлләр тасвирлана. Автор иске киемле, фәкыйрь тормышлы бу затның үз сүзендә нык торучы, иманлы, намуслы кеше булуына басым ясый. Әсәрдә байлык туплауга, хакимияткә тискәре мөнәсәбәт белдерелә.

«Рисаләи-л-иршад» һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмаларының тел-стиле, образлар системасы бүгенге укучылар өчен шактый авыр. Шуңа да карамастан бу әсәрләр шагыйрьнең көчле талантын, элеккеге әдәби казанышларны яхшы үзләштерүен ачык күрсәтә.

Г. Кандалый иҗади эзләнүләрен дәвам итә. Аның әсәрләрендә лирик башлангыч, ихласлылык көчәя, шәхескә, аның рухи халәтенә һәм чынбарлык белән бәйләнешләрына игътибар арта. Шигырьләренең тел-стиле чагыштырмача гадиләшә, фикер-кичерешләрнең үтемлелеге арта. Автор, Габдессәлам (XVIII йөз) традицияләрен дәвам итеп, фольклор казанышларын мул файдалана. Нәтиҗәдә язма поэзия белән киң катлам укучыларның арасы якыная төшә. Дөрес, Г. Кандалый кайвакыт, тезгеннән ычкынып, шигырьләренә урынсызга тупас сүзләр, рус алынмалары да кертеп җибәрә. Әмма күчеш чоры өчен бу күренеш тә билгеле бер дәрәҗәдә аклана.

Г. Кандалый әсәрләренең үзәгендә – кешеләргә хас уйланулар, хис-кичерешләр. Менә аның «Иляһи, барча галәмне...» дип башланган шигыре. Биредәге лирик каһарманның күңеле

моң-зар, сагыш белән мөлдерәмә тулы. Ул, «туганын» сагынуга түзә алмыйча, искән җилләргә, очкан кошларга, үскән агачларга мөрәҗәгать итә, алардан ярдәм сорый, әмма янган йөрәгенә барыбер дәва таба алмый:

Йыгачлардин нә чыкмагай?
Сачаклардин нә булмагай?..
Бу дәрдемә дәва тапмай, –
Дәйүб кайтдым ки анлардин.

«Сабырлык бирсәнә, Алла!» шигырендә лирик каһарманның эчендәге ут-ялкыны, кайгы-хәсрәте дөньядагы карны «эретеп су итәр» дәрәҗәдә көчле.

Г. Кандалыйның бер өлеш әсәрләрендә ата һәм бала мөнәсәбәте яктыртыла. Бу аңлашыла да. Чөнки бу мотивны яктырту татар сүз сәнгатендә бик күптәннән килә. Бу – бер. Икенчедән, Г. Кандалый – үзе дә берничә бала атасы. Алар белән дә төрле хәлләр булгандыр. Мәсәлән, шагыйрьнең Садреддин исемле улын 25 елга солдат хезмәтенә алалар. Моңа, әлбәттә, ата бик кайгыра. Өченчедән, баласыннан, якыннарыннан аерылу – колониаль изелү астында яшәүче бу чор татар тормышында киң таралган күренеш.

Г. Кандалыйның баладан аерылу кайгысын яктырткан шигырьләре өчен үтә дә лиризм, үтә дә эмоциональлек хас. Укучы күз алдына бала кайгысыннан аптыраган, йөдәгән, Йосыфын югалткан Ягъкубтай Ата образы килеп баса:

Иляһи, хәсрәтем агыр,
Ничек итим икән сабыр?
Газиз балам фиракендин (*аерылудан. – Х.М.)*
Янып бетде йөрәк-бәгырь!
...Озак бергә торалмадым,
Йөзең күреп туялмадым,
Ерак йиргә китеп баргач,
Гомергә хәсрәтең калды!

Икенче бер шигырендә автор бала хәсрәтеннән «кара сачләре»нең агаруы, күзеннән «инеш»тәй яшьләр агуы хакында яза.

Г. Кандалый – рухани даирәсеннән, мулла. Шуңа күрә аның дин әһелләре турында язуы да табигый. «Мулла белән абыстай» һәм кайбер башка әсәрләрендә ул, халык турында кайгыртмый-

ча, руханилык вазифасын шәхси мәнфәгатьләре өчен генә файдаланучы дин әһелләрен тәнкыйди планда сурәтли.

**«Тән туфрак булмыйча, гыйшык бетмәс».** Мәхәббәт – кешелекнең даими юлдашы, асыл сыйфатларыннан берсе. Шуңа да ул сүз сәнгатендә элек-электән җырланган һәм көйләнгән. «Кеше кем гашыйк ирмәз – җаны юк, бел», «Әгәр гыйшык булмаса, булмаз ирде адәм», – ди XIV йөз шагыйре Котб. Харәзми, Сәйф Сараи, Габдессәлам өчен дә мәхәббәт – иң олы хис һәм яшәү мәгънәсе.

Бәдига исемле кызга багышланган шигырендә Г. Кандалый Йосыф – Зөләйха, Сәйфелмөлек – Бәдигылҗәмал, Ләйлә – Мәҗнүн, Фәрһад вә Ширин кебек мәшһүр мәхәббәт каһарманнарын телгә ала да болай ди:

Барысы да җиһанга килде-кичде,
Бу дөньядан ахыр беркөнне күчде.
Ки мән дәхи бу арага тезелдем,
«Бәдигам!» – дип өзелдем дә өзелдем!

Әгәр дә Кандалыйның лирик герое мәгълүм гашыйклар арасына «тезелсә», автор исә мәхәббәт хисен җырлауда мәшһүр шагыйрьләр рәтенә баса. Аның күпчелек шигырьләре һәм поэмалары («Шәфгый», «Фәрхи», «Мәгъшукнамә», «Сәхипҗамал» һ.б.) сөю-мәхәббәт турында. Г. Кандалый аларда Мәгъшукның (гашыйк ир-егетнең) рухи халәтен, сөйгән ярының гүзәллеген, мәхәббәт хисләрен күп төрле сурәтләр ярдәмендә төрлечә тасвирлый:

Камыш бармак, көмеш тырнак, каләм каш,
Сезнең өчен ике күздин ага яшь...
Сәнең өчен эчем-тышым янадыр,
Итем бетеп, коры сөяк каладыр!

* * *

...Сәнең дәрдең белә даим йөримен,
Сәне күргәч, сары майтик эримен...

* * *

Кыяфәтдә сыйфатың – суда кондыз,
Үзең былбыл, күзең манәндә йолдыз
(*йолдыз шикелле. – Х.М.*).
Сәнең дәрдең бәндә(дер) кичә-көндез,
Җиһанда юк сәңа охшашлы бер кыз.

Лирик каһарман сөйгәнен тәндәге җаны дәрәҗәсенә күтәрә, аның белән бергә булуны таҗ-тәхетләрдән дә өстен куя, хәтта сөйгән ярына табына да:

Бәңа сәндин бүтән ярлар кирәкмәс,
Бәңа сәнсез бу тәндә җан кирәкмәс.

* * *

Бу сүзем чын, сөйләшәмен алдамый:
Тәмам оныттыра яздың Алламый *(Алламны. – Х.М.)*.

* * *

Күз-кашыны мәсҗедә михраб[2] идем.

Гашыйкларның үзара мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерүдә Г. Кандалый еш кына Йосыф – Зөләйха мәхәббәтен өлге итеп ала:

Сәлам яздым сәңа, җаным, хәкыйкать,
Йосыф – Зөләйхадин алгы л нәсыйхәт.

* * *

Ул Зөләйха түзмәде лә, бер өмиден өзмәде,
Бер тоташ им (*дәва, чара. – Х.М.*) эзләде лә,
бетереп мал-казнасын...

Мәхәббәт – мәңгелек тема. Аны яктыртуда билгеле бер охшашлыклар, хәтта аерым кабатланулар да булуы табигый. Болар Г. Кандалый иҗатында да күзәтелә. Мәсәлән, ул сөйгән ярны хур кызы, тешне энҗе, йөзне кояш, зифа буйны тал һәм кипарис (сәрв), татлы сүзне шикәр белән чагыштырырга ярата. Бу төр сурәтләр фольклорда һәм элеккеге әдәбиятта бик күп очрый, әмма Г. Кандалый аларны еш кына үзгә бәйләнешләрдә куллана, нәтиҗәдә алар яңача төсмер, башка яңгыраш ала. Мәсәлән, кара чәчне төн, матур йөзне көн (кояш) белән чагыштыру Урта гасырның күп кенә шагыйрьләрендә (Котб, Харәзми, С. Сарай һ.б.) очрый. Кандалый исә бу сурәтләрне бер строфа эчендә куллана:

Сачең кара ирер төндик,
Сачең ара йөзең көндик.

Г. Кандалый әсәрләрендә үзенә кадәрге язма әдәбиятта бик күзгә ташланмаган сурәтләр дә еш очрый: «Күрер күзем сән, ... сүләр сүзем сән», «Юаш дигәнгә рәнҗемә. Кесәл дә булма, кәл-

җемә», «Кардай беләгеңне буйнына салып», «Бәңа бер кош теле дик хат сала күр», «Сабыйлык төш..., егетлек кош... кеби улыр», «Сән уласән ике күземнең бере», «Яман хатын – зиндан, бел», «Җәмал *(матурлык. – Х. М.)* дәхи китә торган буяу-тик, Китәр тәндин көздә төшкән кыраутик», «Сәнең буең Ак. Иделнең камышы» һ.б.

«Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта», – дигән иде заманында Һ. Такташ. Г. Кандалый да, шушы «иске нәрсә»не үз күңеле, үз иҗади казаны аркылы уздырып, аңа шактый яңалык, шәхси төсмер бирә. Аның лирик каһарманы,– авторның үзе кебек үк, тынгысыз, эзләнүчән, кайнар табигатьле һәм олы хисле зат. Ул инде абстракт кеше түгел, ә билгеле бер чор һәм билгеле бер халык вәкиле. Аның сөйгән ярлары да моңа кадәр үзгәләр җырлаган Ләйләләр, Шириннәр, Зөһрәләр, Зөләйхалар түгел, ә татар авылларындагы Гөлестаннар, Сәхипҗамаллар, Җәмиләләр, Бәдигалар, Фәрхиләр һ.б. Шагыйрь шушы гадәти татар хатын-кызларының мәхәббәтен һәм матурлыкта патша кызларыннан ким булмавын романтик югарылыкка куеп тасвирлый. Бу – халыкның үзаңы кузгала башлау белән дә аңлатыла. Татар кавеменең алдынгы вәкиле булган Г. Кандалый хатын-кызларны олы, бөек, әхлаклы шәхес, инициативалы зат рәвешендә күрергә тели.

Шагыйрь, мәхәббәт темасын яктыртканда, күп кенә реалистик детальләр куллана. Шуның нәтиҗәсендә татар тормышына хас булган күренешләр, вакыйга-хәлләр укучы күз алдында шактый ачык рәсемләнә. Менә «Җәмиләкәй» шигыреннән аерым строфалар:

...Камыл эчендә лапырдап,
Юеш балчыкта чапырдап,
Йөрисең лә син аһылдап,
Җыеп көлтә, Җәмиләкәй...

Кара гарәп кеби бите,
Тузан-туфрак булыр бите,
Иренләр, күзләрең чите, –
Ябыкканга, Җәмиләкәй...

Ки көз көне дә кыш көне –
Мужикның бар да эш көне;
Буламы елда биш көне
Тыныч, эшсез, Җәмиләкәй?..

Бу юллар колониаль изелү астында яшәүче татар крестьяннарының, бигрәк тә хатын-кызларының авыр хезмәттә көн уздыруларын күрсәтә. Икенче бер язмасында автор үз персонажының тормышын «бояр колы» язмышы белән янәшә куя.

Г. Кандалый әсәрләре арасында үзенең эчтәлеге, идея-сәнгати ягы белән аеруча «Сәхипҗамал» поэмасы игътибарга лаек. Ул – шагыйрьнең визит карточкасы кебек. Анда авторның шигъри казанышлары, иҗади һәм шәхси үзенчәлекләре, ничектер, фокустагы кебек бергә тупланып бирелгән.

Поэмада Парау авылындагы Сәхипҗамал исемле бер гүзәлнең күркәм сурәте, лирик каһарманның бу кызга олы мәхәббәте гаҗәеп оста гәүдәләнеш тапкан. Әсәр реалистик детальләргә, тормышчан күренешләргә шактый бай. Кыз белән бергә булу, аның белән гаилә кору – лирик «мин»нең асыл максаты:

Гөлем бул, гөл йыгачым бул,
Йә былбыл-сандугачым бул,
Бу дәрдемгә гыйляҗем *(дәва. – Х.М.)* бул,
Сәхипҗамал абыстай ла...
Хисабың-сагышың кайда:
Болай тормакта ни файда?
Кауышыйк инде бу айда, –
Вакыт йиткән, и җанкай лә!..

Г. Кандалыйның лирик каһарманы, – авторның үзе кебек үк, укымышлы һәм зыялы кеше. Мондый зат татар әдәбиятында күп гасырлар буе уңай образ, идеал рәвешендә тасвирланып килде. Традицион тәрбия алган шагыйрьнең дә наданнарга, укымаган «мажик»ларга мөнәсәбәте тискәре. «Сәхипҗамал» поэмасында да бу ачык күренә:

Мажик ир булса юлдашың,
Күзеңдин китмәгәй йәшең;
Гакыл йитмәй, азад башың
Үзең салдың ла коллыкка!..
...Әгәр дә меллага (*укымышлыга. – Х.М.*) барсаң,
Сәнең урның булыр түрдә,
Күреп дөньяда күп файда,–
Кыямәтдә ки һәм гүрдә...

Наданны хурлау һәм укымышлыны зурлауның әдәби чара булуын да хәтердән чыгарырга ярамый. Бу алым лирик каһар-

манның үз сөйгәненә мөнәсәбәтен тагын да тулырак һәм тәэсирлерәк бирергә ярдәм иткән.

Шунысы да бар: укый-яза белмәгән кеше Кандалый яшәгән чор татар җәмгыятендә дә тискәре бәяләнгән. Казан университеты профессоры, мәшһүр галим Карл Фукс, «Казан татарлары» исемле китабында (1844) шул дәвер татарларның Европадагы аерым халыкларга караганда укымышлырак булуын искәртеп, болай ди: «Укый-яза белмәгән татар кешесе милләттәшләре арасында түбән бәяләнә һәм хөрмәт ителми».

**«Димәгел йөзени күркәм, Үзеңни даимән күр кәм».** Бу юлларның мәгънәсе болай: йөзеңне күркәм дип әйтмә, ә үзеңне һәрчак ким күр, ягъни тыйнак тот. *Күркәм* һәм *күр кәм* сүзләре берберсе белән үзара омонимик мөнәсәбәттә. Әдәбият белемендә бу күренеш **тәҗнис** дип тә йөртелә. Элек-электән үк әдәбият тарихында иркен кулланылучы бу әдәби чарага Г. Кандалый да мөрәҗәгать итә һәм аны аеруча эчке һәм тышкы рифмалар рәвешендә куллана:

Улыр **иршад** (*тугры юл. – Х.М.)* белән **ир шад.**
Бу нидән булды **чи генә?**
Эшем дә йитде **чигенә,**
Сахибем (*Сәхипҗамал. – Х.М.)* кире **чигенә,**
Исем китәр, ә җанкәй лә!

**Кичәләрдә кичәләр дә...** Урта гасыр әдәбиятында берничә телне катнаштырып шигырь язу гадәте була. Андый әсәрләрне мөләммәгъ дип йөрткәннәр. Г. Кандалыйның да бу ысул белән язылган шигыре бар:

Че хушемән мийайәд тарилдә орех,–
Вә ин ләм йөэкәл булырса грех.

Татар, рус, фарсы, гарәп сүзләрен катнаштырып язылган бу икеюллыкның (фәрднең) мәгънәсе болай: «Миңа бик тә ошый бу тәлинкәдәге чикләвек, Әгәр аны ашамасаң булыр гөнаһ»[3].

Шагыйрь, үз элгәреләре Ясәви һәм Бакырганый, Хисам Кятиб һәм Өмми Кәмал кебек, шигъри строфаларны еш кына бер үк сүзләр яисә юллар белән тәмамларга ярата. Мәсәлән, «Сарып башка кара өрпәк (*бөркәнчек. – Х.М.*)» әсәренең барлык строфалары диярлек «Җәмиләкәй» сүзенә тәгәлләнә. «Ходадин һәм теләп сине» шигырендә күпчелек строфаларның ахырында «Әйа җаным, фида җаным» юлы кабатлана.

Г. Кандалый, эмоциональ якны күздә тотып, юлбаш анафораларны да бик теләп куллана. Мәсәлән, аның 75 строфалык бер шигыренең 73 е «Әйа гариф» (*акыл иясе. – Х. М.*) эндәше белән башлана. Икенче бер әсәрендәге күп кенә юлларның тәүге сүзе – «бәңа» *(миңа. – Х.М):*

**...Бәңа** сәнсез газап ирер бу рахәт,
**Бәңа** сәнсез йөрәкдә мең җәрахәт.
**Бәңа** сәнсез хәрам ирер бу сохбәт *(әңгәмә. – Х.М),*
**Бәңа** сәнсез бу сохбәтләр чү михнәт (*михнәт кебек. – Х.М.).*

Г. Кандалый үз әсәрләрендә хат алымын да куллана һәм кайвакыт язганнарын хат дип атый:

...Бу хатымны кабул идеб ала күр,
Моңа каршы үзең дә хат яза күр...

Шагыйрь, әдәби чара буларак, төш күрү, сәяхәт кылу алымнарына да мөрәҗәгать итә. «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасының композициясе төп каһарманның сәяхәтен сөйләүгә корылган. «Шәфгый» һәм «Сәхипҗамал» әсәрләрендә сурәтләнгән төшләр мәхәббәт хисләренең олылыгын, персонажларның рухи халәтен тулырак яктыртуга ярдәм иткән.

Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Габди, Габдессәлам, Утыз Имәни традицияләрен дәвам итеп, Г. Кандалый төп игътибарын татар дөньясына, татар кешеләренә юнәлтә. Бу хәл аның тел-стилендә, образлар системасында һәм шигырьләренең эчтәлегендә дә чагыла. Ул үз әсәрләренә авыл һәм шәһәр атамаларын (Казан, Бәләбәй, Парау, Төгәлбай, Борнай, Кандал, Малмыж, Рәҗәп һ.б.), кеше исемнәрен (Фәрхи, Әминә, Вәдига, Фатыйма һ.б.), «үзсүзле мишәр» кебек сөйләм гыйбарәләрен кертеп җибәрә. Г. Кандалый әсәрләрендәге лирик каһарман авторның үзе белән шактый якын, хәтта урыны белән алар бөтенләй керешеп китә. Мәсәлән, шагыйрьнең Сәхипҗамал исемле кызга мәхәббәте күпләргә мәгълүм, әмма аларга кавышырга язмый. Ялкынлы мәхәббәттән бары мәшһүр поэма туып кала.

Габдессәлам кебек, Г. Кандалый да халык иҗаты хәзинәләреннән аеруча мул файдалана. Бер-берсеннән аерылган гашыйкларны ул Сак белән Сокка тиңли, надан, ахмак кешене шүрәле белән чагыштыра. Халык җырларына хас булган «каләм каш», «буе тал», «тулган ай», «кыйгач каш», «күземнең карасы», «йөрәк маем» кебек сурәтләр шагыйрь иҗатында бик еш очрый.

Башлангыч чор иҗатында Г. Кандалыйның тел-стиле шактый авыр, әмма бераздан, чынбарлык, татар тормышына игътибар арта барган саен, шагыйрьнең теле дә чагыштырмача гадиләшә, киң катлам укучыларга якыная төшә. Автор үз әсәрләренә сөйләм теленә хас элементларны да уңышлы гына кертеп җибәрә. Гомумән, Г. Кандалыйның тел-стиле бик бай. Ул – тел тарихын, бигрәк тә язма телне өйрәнүдә менә дигән чыганак. Аның әсәрләрендә хәтта Уган (Алла), кани (кайда), Изи (Алла, Тәңре), күз ягы (күз мае, күз нуры), каты ут (каты үлән) кебек архаик сүзләр дә күзгә ташлана.

Г. Кандалый әсәрләрендә башка авторлардан алынган юллар да очрый. Мәсәлән, «Бисмилла дип... башладым...» шигырендә мондый строфа бар:

Сәнең дәрдең бәңа дәрмандин артык,
Сәңа йар булганым солтандин артык.

Бу строфа XII йөз әдибе Бакырганый әсәреннән алынган. Анда әлеге юллар Аллага мәхәббәтне белдерүгә хезмәт итә. Ә Г. Кандалый шигырендә исә бу строфа җир кызына («каләм кашка») мәхәббәтне белдерә.

Г. Кандалый шигърияте үзенә кадәрге бай мәдәни хәзинәгә ныклы таяну, аннан иҗади файдалану нәтиҗәсендә туган. Шагыйрь мирасында Котб, Харәзми, Хисам Кятиб, Сәйф Сарай, Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, фарсы әдипләреннән Гаттар, Низами, Сәгъди һәм башкалар белән охшаш, аваздаш якларны табу һич тә кыен түгел. Г. Кандалый да, Мәүла Колый кебек,

Иген икмәк бирер икмәк,
Белеп иксәң бирер күпләп, –

дип, игенчелеккә дан җырлый. Хисам Кятиб кебек, «Рисаләи-л-иршад» авторы өчен дә гомер фани (вакытлы, чикле): кеше, бу дөньяда, ул кем генә булмасын, ничек кенә яшәмәсен, ахырда барыбер туфрак була. Ул аеруча Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренә, андагы персонажларга, сурәт һәм мотивларга кат-кат мөрәҗәгать итә:

Сачең охшый Зөләйханең саченә.
Бәне салдың Зөләйханең утыйга *(утына. – Х.М.).*

Йосыф – Зөләйха мәхәббәте – шагыйрь каһарманнары өчен өлге, үрнәк.

Г. Кандалыйның берничә шигыре форма ягыннан да «Кыйссаи Йосыф» поэмасына охшаш. Мәсәлән, аның «Назмы Йосыф» әсәрендә строфа төзелеше, рифмалашу, үлчәм нәкъ Кол Гали поэмасындагыча. Биредә автор хәтта «Кыйссаи Йосыф»ның күп кенә сурәтләрен дә файдалана:

...Тулган айга охшар сәнең йөзләрең бар,
Бал-шикәрдин татлы сәнең сүзләрең бар,
Зөһрә йолдыз кебек сәнең сүзләрең бар –
Кыяфәтең фәрештәгә биңзәр *(охшар. – Х.М.)* имди.

Г. Кандалый иҗаты – күп гасырлык әдәби традицияләрнең дәвам ителешендә һәм татар шигърияте үсешендә мөһим күренеш. Аны шул чор тормышы, әдипнең шәхси таланты, элеккеге мәдәни мирас тудыра. Шагыйрь иҗаты өчен көчле лиризм, чынбарлыкка якынлык, кешене, шәхси хөрлекне зурлау, ихласлылык, сәнгати камиллек хас.

Г. Кандалый мирасы укучылар арасында киң таралыш тапты, үзеннән соңгы татар шигъриятенә көчле йогынты ясады. Акмулла, С. Рәмиев, Г. Тукай, Ш. Бабич һәм башка шагыйрьләрнең иҗатларында «Сәхипҗамал» авторының тәэсире ачык сизелә. Г. Кандалыйның юмористик эчтәлекле мондый шигыре бар:

Сәнең башың ирер мисле пудаука[4],
Колакларың гүя торыр лаука (*лавка. – Х.М.*).
Күзең елтырыйдыр сулы чиләкти (*чиләк кебек. – Х.М.*),
Авызың җәйрәгән иске иләкти.
Нәсыйб булып, ала калсам, җанашым,
Савыт-саба, табаклар да кирәкми.

Бу шигырь тәэсирендә Г. Тукай «Егет илә кыз» әсәрен иҗат иткән. Аның соңгы строфасы болай яңгырый:

...Сине алсам, чүмечле һәм иләкле
Булам ич – акча туздырмак кирәкми.

Мәхәббәт темасын эшкәртүдә, юмористик әсәрләр язуда, фольклор һәм язма әдәби казанышларны иҗади файдалануда Ш. Бабич Г. Кандалый традицияләрен уңышлы дәвам иттерде. С. Рәмиев тудырган мәхәббәт геройлары арасында да Г. Кандалый персонажларына аваздаш яклар бар.

Заманында Г. Кандалый: «Ни язганым, ни дигәнем – җәелеп беткән илләрдә», – ди. Әйе, шагыйрь хаклы. Аның бу сүзләре уз-

ган гасырларда гына түгел, бүгенге көндә дә урынлы яңгырый... Г. Кандалый калдырган «якутлар» һаман да балкый, һаман да кадерле!

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Зиндан һәм татар әдибе... Мәгънәви яктан бер-берсеннән ерак торган бу төшенчәләр, кызганычка каршы, тарихи чынлыкта, ничектер, гел янәшә йөриләр. Утыз Имәни һәм Һибәтулла Салихов, Кандалый һәм Акмулла, Г. Исхакый һәм С. Рәмиев, Г. Ибраһимов һәм Ф. Бурнаш, Ф. Кәрим һәм К. Тинчурин, И. Салахов һәм А. Гыйләҗев... Төрмә газапларын үз башларыннан кичергән татар әдипләренең бу исемлеген алга таба да дәвам итәргә мөмкин. Бу хәл нәрсә белән аңлатыла соң? Моның төп һәм мөһим сәбәбе татарларның озак гасырлар буе империя тырнагы астында яшәвендә. Рәсми хакимият табигый хокукын теге яки бу дәрәҗәдә таләп иткән, бераз гына «күндәмсезлек» күрсәткән татар кешесен төрмәгә аткан, үтергән, кырган. Үз милләтенең уй-теләкләрен белдергән туры сүзле, вөҗданлы татар әдипләренә җәза таягының иң юан башы төшкән.

[2] Михраб – изге урын; мәчетнең мулла намаз укый торган өлеше, түре.

[3] Сөйләүләренә караганда, Г. Кандалый Сембер шәһәренә кунакка килә. Хуҗа табынга чикләвек куя һәм шагыйрьне сынарга теләп, төрле телләрдәге сүзләр катнаштырып шигырь әйтүен үтенә. Бары шуннан соң гына чикләвекне ашарга ярый. Имеш, Кандалый бу икеюллыкны шунда әйткән.

[4] Мисле пудаука – зур чиләк кебек.

## Г. КАНДАЛЫЙНЫҢ ИҖАТ СТИЛЕ ТУРЫНДА

*М.И. Әхмәтҗанов*

Татар әдәбиятының күп гасырлык тарихында иҗат эше белән нык танылган күп язучы-шагыйрьләр билгеле. Аның алтын дәвере XIV гасырда булып, соңыннан Казан ханлыгы чоры һәм аның соңгы гасырларда мәгълүм, иҗатлары белән милләтебез мәхәббәтенә тиенгән Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый, Габдессәлам, Утыз Имәни һәм XIX йөздә яшәгән Габделҗаббар Кандалый иҗаты гасырлар аша үтеп, безнең буыннар күңеленә дә килеп кергән.

Шулар арасыннан бу очракта мәшһүр шагыйрь Габделҗаббар Кандалый иҗатына тукталып үтәсе килә.

Әлеге шагыйрьнең иҗат җимешләре, үзе исән чакта ук халык мәхәббәтенә тиенеп, XIX йөздә үк кульязма китап сәхифәләренә кереп, татар укучылары арасында киң таралган.

Аның иҗатын киң күләмдә туплау һәм өйрәнү максатында эшләгән атаклы татар тарихчысы, археограф, тарих фәннәре

докторы Миркасыйм Госманов хезмәтләреннән күренгәнчә, шагыйрьнең шигъри әсәрләре, авторлыгы күрсәтелмичә, 1859, 1870, 1880, 1881, 1912 елларда басылуын һәм аларга карата татар укымышлыларының фикерләре булуы әйтелә[1].

Соңгы еллардагы археографик экспедицияләребез вакытында ачылган борынгы язмалар безгә шагыйрь иҗатының татар әдәбиятында тоткан урынын тагын да тирәнрәк күзалларга мөмкинлек бирә.

Моңа кадәр без Г. Кандалыйның мәхәббәт лирикасын фольклор белән генә бәйләнештә карый килдек. Әлбәттә, бу шагыйрьнең шигырь техникасында бик ачык күренә. Ләкин алар, шагыйрьнең үз стиле белән берегеп, аның шәхси иҗаты икәнлеген каплый алмый.

Шагыйрьнең татар фольклоры белән иҗаты аваздашлыгы аның шигъри хат үзенчәлекләрендә чагыла. Ләкин бу хәл Кандалыйның үзеннән генә килмәгәнлеген элекке гасырлар татар поэзиясе традициясе икәнлеген безнең тарафтан табылган XVII, XVIII гасыр мирасларыннан ук таныла. Мәсәлән, безнең тарафтан табылган XVIII йөзнең беренче яртысында иҗат ителгән бер үрнәкне игътибарыгызга тәкъдим итәм. Ул Габдессәлам (1700–1766) исемле Казан артының Олы Мәнгәр авылыннан чыккан шагыйрь. Аның иҗаты, тулы рәвештә 1979 елгы археографик экспедиция вакытында табылган кулъязма җыентыгы аркылы мәгълүм булып, 1984 елда басылып чыккан «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында милләтебезгә җиткерелде[2]. Шагыйрь иҗатының зур гына өлеше бераз соңрак чыккан бер антологиядә текстологик яктан эшкәртелеп басылып чыкты[3]. Менә шул басмада дөнья күргән бер шигырь – «Илаһи бәет» (50–51 б.) дип атала.

**Илаһи бәйет**

Гаҗәп сәнең намишың,
Буйныңа кул салышың.
Хәрир зибага охшар
Һәрбер айак басышың.

Йөрер йулым төзедер,
Кичә бәңа көндездер.
Рөхсәт биргел китәлем!
Йарыш анда йалгыздыр.

Баг эче, бадам эче,
Барчадин буйым кече.
Ни бакарсың буйыма,
Куйным Гөлбостан эче.

Мулламәтлек үзеңә,
Гашыйкмын бар сүзеңә.
Җаным фида кылырым
Коңгыр кара күзеңә.

Бу гөли хыйнаммыдыр?
Йарыйм багыйдамыдыр?
Йарыйм багыйда булса,
Мине сагынамыдыр?

Әфтаб вә әлза...ле (?)
Ай йордының тәхете.
Кашың – әнә «Фатиха
Сурәсе, хак айәте.

Сыв акап гөлдер-гөлдер.
Сәндин үзгәне дуст тотсам,
Пычак ал, бәни үлдер!

Барырмын йулым, имеш,
Йавлыгым тулы йимеш,
Йарымдин хәбәр килмеш,
Тормасын, йитсен, димеш.

Барырыңны белмәдем,
Барып йулда тормадым.
Тотлыгты мәнем телем,
Хуш калыңыз димәдем.

Бу стильдә язылган шигырь үрнәкләре Габдессәләм иҗатында (матбугатта чыкканнарда) әлегә 20 ләп мисалда мәгълүм.

Аннан соң әйтеп үтәргә ихтыяҗ зур, бу үлчәүдә язылган поэтик әсәрләр XVII гасыр татар поэзиясе үрнәкләрендә дә еш күренә. Мәсәлән, XVII гасыр татар шагыйре әсәрләренең басмасында аларның саны шактый зур, аның 104 хикмәтеннән 30 лабы шушы ысулда язылган[4]. Шулардан бер өзек китерәбез:

**Хикмәте хаким...**

Адәм угълы бизәнүр,
Дөньйаны бакый саныб.

Гөнаһ тохмын шәрләр,
Билен баглаб, йасаныб.

Дөньйа милкен төзәрләр,
Тән-җан берлә теләйеб.
Ахирәткә күчерәләр,
Гөнаһ атына атланыб һ.б.

Бу шигырьләрнең стиле, XII гасыр татар шагыйре Сөләйман Бакыргани заманында ук мәгълүм булып, татарның милли шигырь өслүбенең башында торган. Мәсәлән аның 140 санлы хикмәтеннән бер өзек:

Килең, дуслар, бу дөнья
Кичте, ахры булдия,
Тотты әйран һиммәте,
Бер сүзем яд килдия.

Сүзем ишеткел, мөэмин,
Китәр дөнья зәңгәре,
Исмәгыйльнең кыйссасы
Җанга сафа килдия һ.б.[5]

Китерелгән мисаллар Г. Кандалыйның үз иҗатында моннан 800 еллар элек элек формалашкан татар шигырь өслүбе үрнәгендә иҗат итүен күрсәтә. Бу хәл бездә генә шулаймы соң, безгә генә шулаймы соң, башка безгә якын кардәш халыкларда да шул мирас саклана мы? Моңа уңай җавапны без кыргыз халкы фольклорында булган өлгеләрдә күрәбез. Мәсәлән:

Талпынган таләп берсин,
Чалкыган канат берсин,
Баянду бакыт берсин,
Карыбае убакыт берсин,
Акылчы бол, даннабал,
Калкыңа кашкор панабол,
Җакшыга җанашып җүр.
Жардыга карашып жүр,
Жамандан адашып жүр,
Жоога тик марашып жүр,
Чалкыгандын чамасын бил,
Аккарның арасын бил! һ.б.

Сүзлек

Чалкыган –җәелгән.
Баяндуу–сөйләүчегә.
Бакыт – бәхет.
Карыбас – «Коръән» укучыга.
Убакыт – вакыт.
Даана – донлы.
Калкыңа – халкыңа.
Камкор – юлбашчы.
Паана – мәгънә.
Җанашып – җан булып.
Жардыга – ярлыга.
Карашып – булышып.
Җамандан – яманнан.
Жоога – юанга.
Марашып – карап.
Чалкыгандын – чайкалганның.

Югарыда бәян ителгәннәргә таянып, Габделҗаббар Кандалый иҗаты турында түбәндәге фикерләргә киләбез.

Шагыйрь үзенең иҗатында борынгыдан килгән татар милли поэтик өслүбендә язган. Аның бу иҗатын гади татар фольклорына иярүче генә түгел, халкыбызның милли үзенчәлекле шигырь техникасын кулланучы зур шагыйрь икәнен бүтән яктан да яктырттык.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Габделҗаббар Кандалый. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 5–6 һ.б.

[2] Әхмәтҗанов М. Габдессәлам // Татар әдәбияты тарихы. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 404-411.

[3] XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. Б. 41–73.

[4] Дәүләтшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый. Уку кулланмасы. Уфа: РИЦ Баш ДУ, 2010. Б. 49.

[5] Бакырган китабы. XII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 184.

## Г. КАНДАЛЫЙ ИҖАТЫНДА ЯКТЫЛЫК ҺӘМ КАРАҢГЫЛЫК МИФОЛОГЕМАЛАРЫ

*Р.Ф. Харрасова*

Г. Кандалый шигърияте – унтугызынчы йөзнең беренче яртысында иркенрәк сулыш алып киткән татар әдәбиятының уникаль күренеше, шунлыктан хәзергә кадәр бик күп белгечләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә дә. Ул көчле һәм тотрыклы традицияләрне алга сөргән поэзиябез җирлегендә талантлы куллар эшкәрткән кабатланмас якут кебек балкый.

Бер яктан, урта гасырлар әдәбияты ирешкән уңышларны да кире какмаган, аның катлаулы образларын, алымнарын,

формалар системасын үзләштергән, икенче яктан, дөнья тарихының башыннан килгән яктылык–караңгылык көрәшен инде мәгърифәтчеләрчә дә тасвирлаган, чишкән, күпсанлы яңа образлар уйлап тапкан Г. Кандалый, аның гадәттән тыш эмоциональ яңгырашлы әсәрләре шагыйрь исемен әле аннан соң – унтугызынчы гасырның икенче яртысында да башкалар күтәрелә алмаган биеклекләргә алып менә.

Фольклорда, дини эчтәлектәге китапларда, дидактик әдәбиятта яктылык рәвешендә оҗмах, аңа бару өчен кылган игелекләр, фәрештәләр, хур кызлары, бәхетле тормыш, кояш, нур, яхшылык ягыннан торып көрәшүчеләр, шулар кулланган предметлар, җан ияләре һәм башка образлар белән ассоциацияләнсә, караңгылык тарафдарларын җен-пәриләр, шайтаннар, тәмуг, төн, гөнаһ гамәлләр, яман холыклы затлар тәшкил итә. Билгеле ки, әдәбиятта образларның борынгыдан килгән функцияләре оригиналь фикер йөртүче шагыйрьләр тарафыннан үзгәртелергә дә мөмкин. Бу үзгәрешләр зур тизлек белән бармый, һәм глобальлеккә, универсальлеккә ия мифологемаларның беренчел мәгънәләре дә бервакытта да югалмый. Шуларны күздә тотып, бүгенге язмабызда Г. Кандалый шигъриятендә тасвирланган ак һәм кара көчләр көрәшенә тукталырбыз, яктылык-караңгылык образларын мифологик комплекс сыйфатында анализларбыз.

Яктылык һәм караңгылыкны барлыкка китерүче предметлар, күренешләр, детальләр күп, һәм, чорына бәйле рәвештә, алар аерым бер идеологияне пропагандалауга хезмәт итә. Г. Кандалый әсәрләренең 1988 елгы тупланмасы шагыйрь иҗатында яктылык образларының гыйлем-мәгърифәт тарату идеясенә алып килүен раслаган әсәр белән ачыла:

Гыйлем нурани җәүһәр
Ки мөэминнәр содурында;
Һәуаи бер аждаһа кеби
Чыгар җисмең кобуреңдә.

(Гыйлем нур кебек җәүһәр
Ки мөэминнәр күкрәгендә;
Борын чөйгән бер аждаһа кебек
Чыгар (ятар) җисмең каберләрендә).

Шигырьнең тәүге строфасыннан ук гыйлемлелекнең уңай сыйфат икәнлеге аңлашыла, ул иманлы кешедә, мөселманда, һичшиксез, була. Әле алда киләчәк юллар белән бәйләнеш уздыр-

саң, шагыйрь гыйлемне – кеше белән үлгәннән соң да, димәк, җанында, рухында калучы нурга, ә нурны асылташка тиңләгәндәй тоела. Г. Кандалый татар фольклорында тискәре бәяләнүчән мифик персонаждан кешенең холкын, кылган гамәлләрен, яшәү рәвешен чагылдыру максатында файдалана. Телгә алынган образларның Кандалыйдагыча кулланылышы суфичылык әдәбиятында еш очрый.

Беләбез ки, әкият геройлары белем, тапкырлык, тырышлык һәм башка яхшы сыйфатлар ярдәмендә кара көчләргә каршы көрәшә, аларны җиңгәч, мәҗлес түренә утыртыла, һәм аларның үлгәннәре дә кайчак терелергә мөмкин. Димәк, бу әсәрдә сюжет шулай ук мифологема булып тора. Сөйләгәннәрне раслау йөзеннән, әсәрнең чираттагы строфасын китереп узыйк:

Гыйлем сәхибе һичбер дә
Черемәс, үлсә дә, гүрдә.
Тереклек җире – түрдә,
Булыр мәҗлес хозурында.

Г. Кандалый каләменә уңай һәм тискәрене тәгаен гамәлләрне атап тәфсилләү хас. Соңгы юлларда шагыйрь, шул рәвешчә, күңел теләкләрен алга куючы, дөнья көтмәүче, начар эшләргә бирелүче геройның портретын тудыруны дәвам итә; караңгылык тасвиры өчен төшенчәләрнең шактый бай комплексын куллана:

Һәуа сахибе зурланыр,
Кәсеб итәргә хурланыр,
Зәмимә берлә болганыр,
Булыр нәфесе зурында.

Инде белем – наданлык каршылыгын ачкан әсәрләрне бер кырыйга куеп торып, язмыш, гомер турында уйлануларны чагылдырган кыска күләмле «Сачәк бер вакыт атадыр» шигыренә тукталыйк:

Сачәк бер вакыт атадыр,
Коела, йиргә ятадыр,
Кибәдер, корып катадыр,
Көзенә керсә яриндә.

Китерелгән строфада тормышның күңелсез мизгелләре күбрәк тасвирланса да, укучы күз алдына аның матур чагы да шактый тулы килә, һәм ул шуның белән тәэсирле дә. Моның сәбәбе бик борынгыга, кешеләрнең тормыш барышын семантик

оппозициядә торган Туу – Үлем, Кояш чыгышы – Кояш батышы, Көн – Төн, Тереләр һәм Үлеләр дөньясы кебек төшенчәләр ярдәмендә дуалистик күзаллауларына барып тоташа. Тора-бара семантик каршылыклы сүзләр мәйданы тагын да киңәя, төрле оялар да тәшкил итә башлый. Китерелгән өзектә Г. Кандалый, «ату»га каршы мәгънә аңлаткан берничә сүз ярдәмендә градация тудырып, дөньяда яшәүнең кыскалыгы турында сөйли, туунын хәтта гомер ахырына беренче адым икәнлеген күрсәтә. Үлемнең соң дәрәҗәдә ямьсезлеген чагылдыру өчен, шагыйрь «корып ката» сүзтезмәсеннән файдалана.

Чираттагы строфада Г. Кандалый хәсрәтле кеше гомерен дә иртә вакыты чыккан чәчәкнекенә тиңли һәм бу очракта туры мәгънәсендә үк яктылыкны аңлаткан әдәби детальдән файдалана – андый инсан йөзенең нуры, яктысы бетәр, дип хәбәр итә. Гомумән алганда, нур образы Г. Кандалый иҗатында иман нуры, йөз нуры, таш нуры һәм башка тезмәләр эчендә төрлечә мәгънәләр алып килә.

Шигърияттә нур, нигездә – яктылык позициясендә тора, ә күп нур (нар, ялкын, ут) аңа оппозициядә очрый. Кандалыйда да бу шулай. Әлеге күренешнең тамырлары шулай ук борынгыдан килгән ышануларга барып тоташа. Тәмугны нар (көчле ут) дип күзаллаган, атаган һәм төрле ырым-шырымнарга ышанучан кайбер мөселманнар нар сүзен исемнәр компоненты итүдән саклана. Әле узган гасыр ахырынача татарларның, кемнеңдер исеме «тәмуг иманы яисә иман тәмугы» дип тә аңлашылмасын өчен, еш кына Нариманны (иман уты) Нуриманга (иман нуры) алмаштырулары, кыз балага исем сайлаганда, беренчесе җәһәннәм гөле мәгънәсендә дип фаразлап, Гөлнарга (анар-гранат чәчәге, утлы гөл, гөл уты) караганда Гөлнурны (гөл нуры, нурлы гөл) хуп күрүләре шуны сөйли.

Рухани шагыйрь каләменнән төшкән әсәрләрдә мифологемалар мөһим һәм зур урын алып тора, алар еш кына текст берәмлекләре эчендә доминанта позицияләрдә килә. Без бу фикерне Г. Кандалый иҗатына карата да әйтә алабыз. Кайвакыт аның кече күләмле әсәрләренә дә «Коръән» һәм башка дини китаплардан кергән предмет һәм җан ияләренең саны берничә була. Мәхәббәт темасын ачкан өч строфалы «Иляһи, бу асыл кошны» шигырендә, мәсәлән, тасвирлау объекты җәннәттә яшәүче **асыл кош** төшенчәсе белән атала, лирик мин аны **Илаһе**дан бәхетле итүен – оҗмахта үсүче **Тубай агачы**на кундыруын үтенә. Текст-

та көрәш күренешләре юк, әмма мәгъшуканың якты тасвирына каләме тайган, йөзе сулган, авырлыкларга, гомерлек кайгыларга тарган шагыйрь портреты каршы куела.

Әсәр күләмлерәк һәм анда урын алган сюжет элементлары мулрак булса, мифологик комплекс та, гадәттә, зуррак. Әйтик, тугыз строфалы «Бу илләрдә торып калсам»да дини мифологиягә нисбәтле Әзәл (мәңгелек), әгъля-гаршә, Җен, Иблис образлары бар; егет кеше, фольклордагыча, арыслан, юрга белән чагыштырыла, сөйгәне «ярамас кыз» («тиң түгел кыз») дип атала. Иң мөһиме: әдәбиятта тискәре персонажлар саналган Җен һәм Иблис монда кыю, батыр, теләгәненә ирешүне максат иткән уңай герой портретын тудыруда катнаша, ягъни лирик мин үзен, югарыга, күккә ашкынуда Җен, Иблистән дә битәр кеше дип бәяли.

«Бу илләрдә торып калсам» шигырендә дини риваятьләрдән, мифлардан ук килгән ата-ана каргышы мотивы мәхәббәт темасын яктырткан юлларга үзенчәлекле трансформацияләнә:

Бу илләрдә торып калсам,
Ярамас кызга күз салсам,
Атамның каргышын алсам… –
Качыйм тизрәк бу илләрдин!

Кандалыйның күп кенә әсәрләрендә лирик герой, мәхәббәттә ирек даулап яисә сөйгәнен үзенеке итәр өчен, тирәлек, руханилар катламы, җәмгыятьтә хакимлек иткән традицион карашлар белән генә көрәшсә, бу шигырендә аның ата-аналар ризалыгын да алмавы аңлашыла; яр сыйфатында лаеклы яисә тиң саналырлык кызны сайламаган улны әткәсе каргышы сагалау укучыны имәндереп җибәрә, чөнки лирик мин үзе дә башын әйләндергән уйларыннан айнып киткәндәй була.

Кандалый иҗатында һәм гомумән дә яктылык чыганакларын аңлаткан төшенчәләр, көтелмәгән контекстларда килеп, караңгылык күренешләрен дә тасвирларга мөмкин. Аерым очракларда, әйтик, түбәндәге икеюллыкта алар уңай һәм тискәре көрәшендә капма-каршы позицияләрне чагылдыру максатыннан кулланыла:

И **кояшым,** чыгармусән болытдин?
Алырмусән бәне бу **ялкын-утдин?**

Аталган күренешнең сәбәп-шарты гади: яхшылык, игелек, яшәеш башы булган яктылык табигатьтә негатив күренеш тә

булып тора. Янгын, янартаулар, яшен алып килгән афәтләр һәм башкаларны искә төшерү дә житә. Моңсу, бигрәк тә фажигаи рухтагы әсәрләрдә кеше күңелендәге көчле мәхәббәт әлеге образлар ярдәмендә тасвирланганда, аларның негатив төсмере яисә мәгънәсе исәпкә алынмый калмый, чөнки мондый төр мәхәббәтне җанда йөртү, кичерү герой өчен авыр булып тора.

Кандай алсу кояш, кан төсендәге чәчкә, канлы шәфәкъ кебек кан сүзе кергән гыйбарәләр, компонентларының икенче, өченче кисәкләре нинди төшенчә булуга карамастан, тискәре мәгънәгә ия, чөнки аларда үтереш, кан коеш һәм башка фажигаләрне тасвирлаганда кулланылучан тәүге сүз доминанта позицияне алган. Ә бит аерым торганда, кояш лексемасы да күбрәк яктылык мифологемасы булып килә, икенче мисалда очраган чәчкә төшенчәсе исә нәфис текстларда матурлык, яшьлек, сафлык кебек символлар сыйфатында кулланыла. Моннан чыгып, без яктылык мифологемаларының рәхәтсезлек, шомлылык, курку хисләре житкерергә мөмкинлеген әйтик. Г. Кандалый кебек трагик мәхәббәтне еш тасвирлаучы шагыйрьләр иҗатында бу аеруча шулай. Яктылык образлары, нәкъ менә күңелгә ятышсыз мәгънәләр белдергәндә, үзара капма-каршы позицияләргә басканда, аерымачык текстның ачкыч төшенчәләренә әйләнә. Югарыда китерелгән шигырь шуңа бер дәлил булып тора.

Яктылык һәм караңгылык көрәше төсне, нурны яисә караңгылыкны белдергән образлар белән генә чикләнмәгәнлекне күрдек. Наданлыкны – караңгылык, белемлелекне яктылык дип санаган мәгърифәтчелек әдәбиятында уңай геройлар, билгеле ки – белемлеләр, алдынгы идеяләрне пропагандалаучылар, ә тискәреләре – җаһиллар, рухи сукырлар, искелеккә ябышып ятучылар. Төбәк һәм рухани каршылыгын чагылдырган «Бу илләрдә торып калсам»да да шулай, тик лирик миннең кемлеге текст ахырында гына һәм кием-салым детальләре ярдәмендә беленә:

**Төреп чалма-чапанларны,**
Йөресәм кыр-япанларны,
Онытмам сез наданларны, –
Элеп салмыйча һич калмам!

Илдән куылган, дөнья гизгән геройлар әкиятләрдә еш очрый, әмма аларның миссиясе – бер, гашыйк шагыйрь-каһарманныкы – икенче. Әле генә атасы каргышы төшүдән сакланырга уй-

лаган яшь мулланың тиз арада фикере үзгәрә; ул инде яңадан көрәшләргә алгысына, гомумнормаларга туры килмәгән гамәлләрне дә ташларга теләми, аны хәтта үзен «чалма-чапанлы»лар социаль төркеменнән чыгарулары да куркытмый. Әдәби герой халык күңелендә тынычлыкка, буйсынучанлыкка өндәүче хәзрәт түгел, ә бунтарь рухлы шагыйрь булып калуны сайлый.

Г. Кандалыйның ахыр чиктә, инде хак эшенә сабыр итәм, ут эчләренә төшмим, дип белдергән әсәрләрендә дә лирик миннең сабырсызлыгы, тынгысызлыгы, күңел дөньясы белән генә яшәве ачык күренә. Мондый чакта Г. Кандалый әдәби каймага ут, кан кебек образларны кертә («Ки кяшки дөньяга килмәгәй идем»). Тарихы гасырларга сузылган татар поэзиясендә кемнең дә булса каләме Г. Кандалыйныкы дәрәҗәсендә ут, ялкын төшенчәләрен мул кулланды микән, дигән сорау туа. Күләмгә мөнәсәбәттә – ешлык яссылыгыннан караганда, һич исәпләмичә дә кистереп әйтергә була: юк!

Җан януларын чагылдыруның бик отышлы юлын таба шагыйрь, – ул шул хакта беренче строфада ук максималь дәрәҗәдә көчле яңгырата:

Бәнем эчемдәге нарым,
Дөньяга чыгарсам барын,
Эретеп су итәр карын,–
Сабырлык бирсәнә, Алла!

Г. Кандалый югарыда яктылык образларына, күргәнебезчә, шигъри фикернең психологик биеклегендә мөрәҗәгать итә. Ул язган күп кенә шигырьләрнең тәүге юллары ук көчле яңгырый, дидек, ә бит андый әсәрләрдә шагыйрь бу биеклекне алга таба да ничек тә югалтмаска тырыша. Әгәр теге яки бу строфа соң дәрәҗәдәге накал белән башланмый, башланып та чираттагы юлларда сүз тәэсиренең көче кимеп китә икән, автор аны дүртенче юлда барыбер көчәйтеп җибәрәчәк. Лирик миннең эчке тирәнлектәге хисләрдән, киеренкелектән арына алмавы аркасында, автор үзе музыкаль инструментның тартылып, озак вакытлар җибәрелми торган кылы кебек тоела.

Г. Кандалый, гадәттә, строфа ахырына куйган Аллага эндәшле, үтенеч-ялварулы шигырь юллары лирик миннең үзәгеннән сыгылып чыккан газаплы иңрәү кебек ишетелә. Әйтерсең, тартылган кыллар өзелсә шул вакыт өзелә дә. Аерым очракларда әлеге мөрәҗәгатьләрнең иң көчле яңгырашлысы текст ахырына

калдырыла. Фикергә мисал булырлык икенче бер әсәрне карап узыйк:

Ходауәндә, яна бәгърем:
Бу йирдә юк бәнем кадрем,
Чыдарга калмады сабрым,–
Сабыр бирсен үзе Алла!
(«Ходауәндә, яна бәгърем:»)

Башта, Алла сабырлык бирсен, дип теләү белән канәгатьләнгән лирик мин бераздан аны Ходайдан тартып алыр хәлгә килә:

Бәнем ошбу ахым-зарым,
Җиде кат күкләргә ашды,
Фиракъ уты бәни басды,
Илаһи, бир сабырлыкны!

Г. Кандалыйның урыны белән – үтә дә, кайвакыт җиңелчәрәк сагышлы иҗатында яктылык образлары лирик миннең генә түгел, башка персонажларның кабул ителешендә дә зур роль уйный. Әйтик, «Моңаеп сайрыйдыр кошлар»да гүзәл фасылларда да моңсулыкка бирелүчән герой яшел чирәмнәргә, язга мактау укыган агачларга шатлана, ул «ал, кызыл йөз»ле Котлыбай, Ихсаннарның җылылык тапканыннан канәгать.

Г. Кандалый, нәрсә турында гына язмасын, вакытның кыскалыгы, егет чакның мизгеллеге турында фикер әйтеп үтәргә тырыша. Бу авторның шәхси кичерешләренә турыдан-туры кагыла. Ул кызлар караткан, чын мәхәббәт кичергән, бәхәсләр мәйданында яшәгән, ирлек күрсәткән чорын югалтудан башкаларга караганда да ныграк курка сыман. Мәсәлән, алда телгә алынган шигырьдә дә «Бу егетлек, имеш – бер көн – / Йомып ачканчы бер күз дә» философемасы белән очрашабыз.

Г. Кандалыйның бигрәк тә мәхәббәт лирикасына эстетик идеалны чагылдыруның төрле лирик формалары хас булса да, аларны үзара бәйләгән уртак структуралар, әдәби алымнар һәм образ-символлар бар. Карашларын, эстетик зәвыгын, нигездә, көнчыгыш фәне, фәлсәфәсе, әдәбияты һәм ислам дине формалаштыруга карамастан, аның әсәрләрендә кулланылыш тапкан образ-символлар – гомумкешелек мәдәниятендә дә киң таралыш алган образлар, архетиплар ул. Әйтик, изгелек, гыйффәтлелек һәм башка мәгънә йөкләрен алып килүче хурия (гурия), өлгергәнлекне белдерүче тулган ай, гадел Хаким булган бер Алла (Бог), мәхәббәт кошы гандәлиб (былбыл, сандугач, соловей) ке-

бек образлар теләсә кайсы әдәбиятта очрый, без аларның русча атамаларын да биреп бардык. Шул ук вакытта намазлыкта Алладан мәхәббәт сорау кебек образ-хәрәкәт, килешү язуын аңлаткан гаһеднамә, соң дәрәҗәдә сафлык билгесе булган Аппак кыз, исерткеч иркәләүне белдергән пәри назы, күкләргә ирештерә алган ат – Порак, ука яка, мамык калпак, раушан йөз, каләм каш, мәхәббәт гамбәре образларын ислам һәм милли мәдәният җирлегендә туганнар дип карарга мөмкин.

Г. Кандалый шигъриятендә автор яшәгән, булып узган җирләргә мөнәсәбәттә туган образлар, урынчалык атамалары да күп. Кайберләре халык авыз иҗатындагы образларны күңелгә китерә. Татар әкиятләрендә башка персонажларны төп башына утырткан Алдар Күсә исемле герой бар. Г. Кандалый исә ишаннар ялагае булган Алдар Чумай турында түбәндәге дүртьюллыкны яза:

Алдар Чумай – агадин ага,
Ник йөри ягадин яга?
Ишан биргән, имеш, сага,
Шуның өчен җиңел чаба.

Көнчыгыш телләрне камил белгән Г. Кандалый иҗатында көнбатыш-рус шигъриятеннән кергән төшенчәләр һәм образлар да җитәрлек. Болар пылута (плутовка), малчук (мальчик), бедняшка (бедняжка), муклашка, пудаука (пудовка – потлы чиләк), душа, мухнатый тән, сбижий биннек (свежий венник – яңа миллек), грех, гуре (горе), орех, тариль (тарелка) һәм башкалар. Алар милли телдә яңгыраган сүзләр я булмаса гарәп-фарсы алынмалары белән отышлы үреләләр-берегәләр, үзенчәлекле стиль тудыруда катнашалар, агымдагы яисә гомуми яңгырашны үзгәртеп җибәрәләр. Алынмалар, әйтик, җитди сүзгә еш кына шаяру төсмере бирәләр, лирик минне уенчак яисә мут итеп күрсәтергә мөмкиннәр яисә ямьсезлек категориясенә хезмәт итәләр һ.б.

Рус лексикасын мул кулланган, аларны текстка бигрәк тә эпитетлар рәвешендә керткән Г. Кандалый әсәрләрен укыганда, һәрдаим, янәшәлекләр эзләп, көнбатыш әдәбиятлардагы образлар системасын да күз алдыннан үткәрәсең, аерымлыклар һәм охшашлыклар эзлисең, һәр икесен дә табасың. Мәсәлән, гареб шигъриятендә еш кына укны яктылык мифологемаларына караган уңай образлар – гашыйк кеше, мәхәббәт фәрештәләре атса,

Г. Кандалыйда әлеге төшенчә караңгылык мифологемасын (әҗәл угы) тудыруда катнаша:

Әҗәл угын әгәр корса атарга,
Әман вирмәз мишәргә һәм татарга.

Югарыда китерелгән кечкенә генә шигырь яшәешкә мөнәсәбәтле дини фәлсәфә яисә хикмәтле сүз түгел, аңа тормышчан эчтәлек яшерелгәнлеген, ике юллыкта тарихи барыштан чыккан нәтиҗә икәнлеген башкалар тарафыннан басып алынган миллэт укучылары ачык аңлый. Шагыйрь гасырлар дәвамында кан-кардәшләрне сагалаган физик үлемгә, ягъни теге яки бу халыкның сәяси-иҗтимагый мәйданда юк ителешенә кагылышлы фикерен бик үзенчәлекле – фаҗигаи тарихлы татар һәм мишәр кавемнәрен атау ярдәмендә җиткергән.

Г. Кандалыйның поэтик каләме татар әдәбиятына яңа образлар алып килүе, милли җирлеклеләрне активлаштыруы белән дә әһәмияткә лаек. Алдарак аталганнардан тыш, боларга Ак Иделнең камышы, Мәкәрҗә калфагы, Парау яисә Борнай иле, абыстай яисә абызтай, мишәр һ.б.лар керә. Бу уңайдан, гүзәл образларны тышкы кыяфәте куркыныч булган сөлек, кондыз (корт һәм хайван), дөлдел (Гали хәлифә качыры, чабышкы ат) кебек образлар ярдәмендә тасвирлаган татар шигърияте чит халыкларны әле һаман да гаҗәпкә калдырганны әйтик. Андый төшенчәләр ярдәмендә чагыштыру, троплар тудыру Г. Кандалый каләменә дә хас. Шуңа бер мисал китереп узыйк:

Күзеңнең нуры йолдыздай,
Керпекләрең дә кондыздай,
Җәмалең мисле хур кыздай,–
Яратыбдыр сәне, валлаһ!
(«Сезнең йортыңыза вардым»)

Гүзәллекне тасвирлаганда, Г. Кандалый татар әдәбиятында тотрыклы урын алган мифологемалар белән генә чикләнмәгән. Үз заманында гына түгел, хәтта хәзер дә ул әдәбиятка керткән әдәби детальләрнең, халкыбызга хас этик-мораль кагыйдә нормаларга бәйле рәвештә, активлашып китә алмаганнары бар. Бу урында шагыйрьнең бигрәк тә хатын-кыз тәненә, аның интим зоналарына зур игътибар бирүен билгеләргә кирәк. Дөрес, андый тасвирлау көнчыгыш поэзиясе, бигрәк тә мәхәббәт лирикасы өчен яңалык түгел. Бу урында Г. Кандалыйның татар укучысы-

на кайвакыт әдәпсезрәк тоелган тасвирларын чамасыз уздырган, берәүләр иҗтимагый сатира, икенчеләр исә эротик эпос дип исәпләгән «Вис һәм Рамин»ны искә төшерү дә җитә.

Унберенче гасыр фарсы-таҗикъ шагыйре Фәхретдин Гурганиның әлеге әсәре инде чираттагы гасырда ук грузинчага («Висрамиани»), соңрак башка телләргә, шул исәптән русчага тәрҗемә ителгән, хәзерге көндә бөтен дөнья халыклары арасында яңадан популярлашты. Шул ук вакытта ул әле дә зур күпчелек татар укучысына, хәтта шагыйрьләренә дә таныш түгел дип уйлыйм. Телгә алынган поэма янында Р. Харисның «Өч үбешүе» дә бик тыйнак тасвирлардан тора кебек тоела башлый.

«Вис һәм Рамин»да сарай әһелләренең, югары катламнарның үзара мөнәсәбәтләре еш кына натуралистик планда гәүдәләнеш таба, ә Г. Кандалый үзенең белемле героена каршы куелган «мажигы» белән аңа барган бәхетсез кыз арасындагы хәлләрне шулай сурәтли. Ике автор каләменә хатын-кыз портретын тудыруда да охшашлык-уртаклыклар хас.

Ф. Гурганиның Вис исемле патшабикә белән патша абыйсы Рамин мәхәббәтен үзәккә куйган, кульъязмалары илләрдән-илләргә йөреп-таралып, битләре югалып беткән, аерым өлешләре генә сакланып калган романтик эпосы белән танышканда, күңелгә Г. Кандалыйның шундый ук хәлләргә дучар булган мәхәббәт лирикасы, образлы әйткәндә, «Сәхипҗамалнамә»се килә. Шунысын да әйтеп узыйк: үз чорында нинди зур тәнкыйтьләргә дучар ителмәсен, юк итәргә көч куелмасын, «Вис һәм Рамин»нан алынган өзекләр урта гасыр антологияләренә кертелгән.

Г. Кандалыйның хатын-кыз тәненә игътибар иткән әсәрләренә мисал рәвешендә «Үзең анда тик торасән»не атарга булыр иде. Әлеге шигырьдә автор күзе-кашы чокыр аша сикерешеп уйнагандай, күкрәкләре сазда сүзләр көйләгәндәй сөйләшкән кыз портретын тудыра:

Күз дә кашың уйнаш ла,
Биегәнди баз илә,
Күкселәрең сүзләшәдер
Төрле сүзи саз илә.

Г. Кандалыйның караңгылык мифологемасына хезмәт иткән һәм милли тормышыбыздан алган образлары да шактый үзенчәлекле, шунлыктан күңелгә кереп кала. Әйтик, боларга туфрак күмәче, җил-куык, аю кебек кочу, б…ы чабата, мачы

кебек образ-детальләрне кертергә мөмкин. Контекст эчендәге мисал да китереп узыйк:

Ки туфрак күмәче кеби
Булыр тозлы, ачы кеби,
Ялынырсың мачы кеби,
Дисә: «Үп!» и абыстай ла!
(«Мәгъшукнамә»)

Әле шул да бар: бер үк образ һәр халык шигъриятендә очрарга мөмкин, әмма аның әйтелеше, нинди лексемаларда һәм контекстларда чагылышы, теге яки бу әдәбиятта кулланылыш ешлыгы беренчел чыганакларга күрсәтеп тора. Мәсәлән: караңгылык мифологемаларына караган миһе әлим (кайгы кадагы), гыйсъян алла (Аллага каршы баш күтәрүче), фиракъ уты (аерылу уты), мәнкүрә кыз (кире кагылган кыз), гашыйклар тыйгыны һәм башкалар; яктылыкны тудыруга хезмәт иткән оядашлар – баде сәмум (сәмум җиле), сәнавар (нурлы йөзле), Хәүзи Кәүсәр (Кәүсәр чишмәсе), Шәҗре Тубый (бәхет яисә җәннәт агачы) кебек образларның дини әдәбияттан, гарәп-фарсы шигъриятеннән кергәнлеге ачык күренә. Г. Кандалый җыентыгындагы сүзләр кайвакыт дөрес язылса яисә аңлатылса, аерым җирләргә сораулар куеп калдырылмаса, аларның мәйданы тагын да киңәеп китәр иде.

Г. Кандалый тудырган караңгылык һәм яктылык тасвирларында безнең якларда булмаган нигъмәтләрнең, эш-гамәлләрнең телгә алынуы шагыйрьнең ни дәрәҗәдә чит әдәбиятлардан һәм тормыштан хәбәрдарлыгын гына сөйләп калмый, татар кешеләренең аралашу тирәлеген, сәүдәсен, яшәү рәвешен дә ачыкларга булыша. Әйтик, җыентык авторлары түбәндәге текстта «хәшмиш (?) төхмедик аша» җөмләсен аңлата алмаганнар. Шагыйрь насыйхатендә егетлек вакытындагы кешеләрне гамь-госсаларны йотмаска – бәгырьне яндырмаска, кыздырмаска, аларны кишмиш, ягъни аркылы күренүчән, ут уйнаткан виноград орлыгы кебек кенә ашарга, югарыга карамаска, коры калган ботакларның ботак кына икәнлеген, ташланырга тиешлеген (боларны да йөземе җыелган яисә яисә йөземнең киселергә тиешле сабаклары дип уйлыйк), шуның белән начарлыгын аңларга чакыра:

Чү, хәшмиш төхмедик аша,
Юкары чикмәгел баша,
Хаша төшек калган хаша,
Ки бәд тәрке белән, и җан!

Текстта тасвирланган күренешнең мәгънәсе эчкә яшерелгән булса да, шагыйрь тормыш фәлсәфәсен җиткерсә дә, яктылык образлары кулланылган текст туры мәгънәсендәге эш-хәл тасвиры буларак та кызыклы.

Г. Кандалыйның оригиналь шигъриятендә образлар дөньясы бик бай, һәм шулар эчендә яктылыкны турыдан-туры да белдергәннәре аеруча зур урын тота. Болар: ак алтын я якут, кызыл алтын яисә якут, кызыл алма, алтын йөзек, әфтаб (кояш нуры), яшен, кисәү, җәһәннәм, атәш, валә (рәшә), көнәш табан (кояш ялтыравы), дегет, сумала, шәм, караңгы, томан һ.б. Күләм ягыннан чагыштырмача кыска йөз шигырьне ирекле сайлап тикшергәндә генә дә аларның саны текстларныкыннан бихисап артып китте, һәм бу фикеребезне раслый булса кирәк.

Г. Кандалый иҗатында объектны тасвирлаучы яктылык төшенчәләре, контекстка бәйле рәвештә, төрле мәгънә эчтәлеге алып килә. Әйтик, алда телгә алынган тулган ай образы, шәхеснең өлгергәнлеген билгеләү өстенә, кызның камиллеген, йөзе гүзәллеген ассызыкларга, теге яки бу тасвир объектының формасын билгеләргә мөмкин.

Тулган ай, хурия образлары, Г. Кандалый тарафыннан тиңләштерелгәндә, бергә кушылып та китәләр. Хурия – шагыйрь идеалы, лирик мин аның дөньясын яраткан кешесен сагалаган авыр җир тормышына каршы куя; үзенеке булырга ризалашса, аңа җирдә җәннәт тудырырга вәгъдә бирә, шуның белән бергә, үзен дә идеаллаштыра. Сөйгәне бергә булудан баш тартса, шагыйрь аны төрле авырулар, тәмуг газаплары белән куркыта. Адресатка, тасвир объектына бу рәвешчә эндәшүләр фольклорда да, дини-дидактик әдәбиятта да күзәтелә. Татар кешеләрендә, фәлән кешенең, остазларыңның я булмаса хуҗаларыңның йөзенә нурлы күрен, дип теләү киң таралыш алган. Г. Кандалыйда бу төр теләкләрне үзенчәлекле куллану очрый. Әйтик, ул үзе өчен «якты» күренгән кызны сөйгәне күзенә «нурсыз» күрсәтергә тырыша – «Җамалеңдин кара төтин кебек күрсә иде», дип тели.

Тасвирда контрастлылыкны төп әдәби алым иткән Г. Кандалый иҗатында яктылык янәшәсендә караңгылык булуга гаҗәпләнергә кирәкми. Укучы күз алдында, гомумән алганда, контрастлы дөнья торып басса да, сан һәм төрлелек ягыннан туры мәгънәсендәге дә яктылык образлары караңгылыкныкыларны узып китә шикелле. Һәрхәлдә, саф мәхәббәт әсәрләрен укыганда, аларның күплегенә игътибар итми калмыйсың. Дөрес, бу очракта

без үз эченә башка төр образ-детальләрне дә алган яктылык һәм караңгылык мифологемаларының комплексы турында сүз алып бармыйбыз, аларның шагыйрь мирасында гомуми мәйданнарын ачыклау әле бурыч булып тора.

Г. Кандалыйның гомуми иҗатында, аерым төр шигъриятендә генә түгел, мөстәкыйль әдәби берәмлекләрендә дә яктылык мифологемалары комплекс рәвешендә очрый. Мәсәлән, теге яки бу образны калкуландыру өчен, шагыйрь ниндидер космогоник җисемне телгә алу белән генә чикләнмәскә, ай, кояш, йолдызларның барысы турында да язып узарга мөмкин. Кайвакыт ул әдәби-дини геройларны бер-бер артлы искә ала, шулар янәшәсендә яктылык хәрәкәтләрен дә әдәби деталь итә.

Г. Кандалый еш кына мәгъшукасы аксессуарларын берничә яктылык образы ярдәмендә тасвирлый. Шулай итеп, «көмеш алкаң», «каләмең тутыя биңзяр», «Башыңа киясең калпак, сыйфаты кар кебек һәм ак» юллары Г. Кандалый шигъриятенең үзенчәлекле бизәкләренә әверелә. Яктылык һәм караңгылык мифологемаларына нигезләнгән әдәбиятыбызда алар янәшәсендә, билгеле, караңгылыкны белдерүче төсләр, ямьсез күренешләр тудыручы хәрәкәтләр, предметлар дә бар. Г. Кандалый каләменең бер үзенчәлеге шунда – еш кына алар бер строфа эчендә дә бик тыгыз урнаша:

Сарып башка кара өрпәк,
Киеп пәҗи кара күлмәк,
Гүя маластаулы чүлмәк,
Йөрисең, и Җәмиләкәй.
(«Сарып башка кара өрпәк»)

Күргәнебезчә, беренче өч юлдагы киемне, материалын, киелү рәвешен, формасын аңлаткан барлык төшенчәләр тик тискәре тасвир тудыруга хезмәт итә. Һәр көне эштә узган крестьян хатынкызын соң дәрәҗәдә арган, таушалган Җәмилә образын тудырган әлеге шигырьдә кара сүзе генә дә дүрт мәртәбә кулланылган.

Г. Кандалый Җәмиләне кара гарәп, кара кол сүзләре белән бәяли. Ул төнен каранып йөргән өрәккә, тузан-туфрак каткан йөзле кара гарәпкә; укучыда, бер яктан, камыл эчендә лапырдаган, юеш балчыкта чапырдаган, һәмишә аһылдаган, аяклары чебешләгән, санын көчкә күтәргән Җәмиләне кызгану хисе барлыкка килә. Икенче яктан, аның героинядан күңеле дә кайта, авторга әнә шул поляррак торган тәэсирләргә ирешү кирәк тә.

Шуңа ирешүгә үк, ул «мажик хатыны»ның каршысы булган Җәмилә абыстайны тасвирларга керешә.

Г. Кандалыйның эшчән крестьянканың бәхетсез тормышы һәм гүзәл иркә, сөйгән һәм сөелгән кыз-ханымнарның җәннәттәгечә көн итеше турындагы фикерләре – шулай ук борынгы чорларга барып тоташкан философемалар. Автор нәрсә турында гына язмасын, ул аның махсус эзләнүләре, уйланулары, тапкыр хөкемнәре, бер үк вакытта үз чорына хас карашлар чагылышы да булып тора, әмма бу карашларны уздыруда Г. Кандалый замандашларыннан бик алга китә – шигъриятенә мул рәвештә тормыш прозасын алып керә.

Мәгъшуканың әгъзалары, герой җанын яндырган хисләр, нигездә, яктылык образлары белән янәшә куела, чагыштырыла, атала. Герой күңелендә кабынган көчле утның төп ике сәбәбе бар, һәм ул образлар аша төгәл чагылыш таба. Аның беренчесе – аерылу (фиракъ) уты, ә икенчесе гыйшыклык уты булып тора; дошманнарга каршы нәфрәт уты, көрәш уты һәм башкалар болар янында тоныграк сыман тоела. Лирик миндә кабынган көчле ярату хисе «бәгърем яна», «йөрәгем яна» образ-хәрәкәтләре, ут, нур, нар кебек төшенчәләр ярдәмендә тудырыла. Алар еш кына мәгънә ягыннан якын сүзләрнең оясын хасил итә:

Үзеңне күрмәен күңлемне алган,
Көйдереп тә яндырып утка салган.
(«Кечекдин сәүдем, и күңелем зыясы»)

Күргәнебезчә икенче юл эчке януларның өч дәрәҗәсен чагылдырган сүзләр төркеменнән төзелгән.

Г. Кандалый еш кына күзе төшкән хатын-кызны да мәхәббәт өчен көрәшергә, бу көрәштә егеткә тарафдар булырга әйди, хәтта иреннән үч алырга да чакырырга мөмкин.

Надан ирне көтеп алмак,
Ирер мөшкел кочып ятмак,
Аның малын утка якмак,–
Нә данә гасбәи Алла,–
(«Бән сезләрә бер сүземне»)

дип, шагыйрь карашынча, гүзәлләргә тиң түгел ир белән яшәгән мәгъшукасының хәленә игътибарны юнәлтүенә дә карамастан, укучы лирик миннең калебен баскан караңгылыкның бу хәлләрдән авыррак икәнлеген нык тоя.

Г. Кандалый мәхәббәт темасын ачканда сурәтләгән лирик герой сөйгәненең хыянәтен, иң беренче чиратта, үз-үзенә хыянәт, алдагы бәхетсезлекләренә бер юл дип саный; хатын-кызның беркатлылыгына, тормышны аңламавына шакката, шул сәбәпле хәтта рәнҗи; үзен сайламаган, кеше сүзләренә караган, ихлас хисләрне аяк астына салып таптаган сөеклесен каргап та куйгалый:

Йә, сөйәмен, дип алдап, бер мут алсын,
Утырыр йиреңне, баргач, ут алсын!
(«Сөйгәнемә инанмасаң, Бәдига»)

Лирик миннең үчләшүләре генә – йөрәгендәге борчуларын оныттырырлык, рухи хасталыгыннан чыгарырлык түгел. Ул моны үзе дә танырга мәҗбүр, ситуацияне йомшарту, кызның күңелен күрү өчен: «Бәдыйга, рәнҗемә, каргадым уйнап», – ди. Шулай әйтүенә дә карамастан, лирик мин әледән-әле үзен сайламаган сөйгәненә карата катылык күрсәтә, аны ямьсез күренешләр эчендә тасвирлый:

Кыйнап-кыйнап та тиңсенмәс…
Җибәргән чакта ир селтәп,
Ки кайгы берлә гөрселдәп,
Егылып егълама, аппак.
(«Кыйнап-кыйнап та тиңсенмәс…»)

Лирик мин күзе төшкән кызны, авырлыкларга тарса, кызганмый, җае чыкканда, каргышын исенә төшереп ала. Төрлечә куркытулар, караңгы дөнья тасвирлары аңа гүзәл кызны «ялгышлардан саклау», ягъни үзенеке итү өчен кирәк:

Язылган булса тәкъдирдә,
Тап улсаң шундаен иргә,
Бәнем дә каргышым бергә
Киләчәк, шөбһәсез, аппак.

Бу төр шигырьләр вакыты белән рухны баса, авырайта, «күңел генәм дә жәлләми» дип язган шагыйрьгә аптырый да башлыйсың. Шул ук вакытта укучы аңлый да: хәвефкә алып барган сюжет элементлары ярдәмендә автор мәхәббәттән – нәфрәткә, яктыдан – караңгыга бер адым гына икәнне күрсәтә.

Кандалыйның трагик хәлне шактый ачык күзаллаган лирик герое сабырсыз. Бер караганда, бу мөселман һәм милли фәлсәфәсенә, эстетик идеалларына туры килми кебек. Шуны акларга

теләгәндәй, шагыйрь даими рәвештә Алладан сабырлык сорый, сабыр булуның юлларын күрсәтүен үтенә, эзли. Лирик миннең шигырь, хат, бәет язулары хәсрәт таратуның бер юлы шикелле аңлашыла. Лирик геройның Алла белән «сөйләшү»ләре баласына багышланган шигырьләрдә укучыга аеруча көчле тәэсир ясарлык:

Иляһи, хәсрәтем агыр,
Ничек итим икән сабыр?
Газиз балам фиракындин
Янып бетте йөрәк-бәгырь.
(«Ки әүвәл ибтида итдем»)

Аллага эндәшле текстлар эчендә борынгыдан, дини әдәбияттан һәм халык авыз иҗатыннан, бигрәк тә мөнәҗәтләрдән, бәетләрдән килгән философемалар еш күзәтелә. «Ки әүвәл ибтида итдем»нең беренче юлларында «Хода исемен яд иткән» лирик мин:

Ки һәркем исми йад итсә,
Вирә максудыни Алла,–

дип белдерә. Баласы белән очраша алмаган атаның көне-төне хәсрәттә, караңгылыкта уза. «Юлларга багып» елаган геройның хәсрәте Йосыфны югалткан Ягъкуб кичергәннәргә аваздаштыр кебек. Әлеге әсәрнең караңгылыкны тудыручылар даирәсен сары суккан кызыл йөз һәм ике күз, янган йөрәк-бәгырь кебек образлар тәшкил итә.

Г. Кандалыйның мәхәббәт шигърияте – лирик миннең мәгъшукасына бәйле тормышка ашмаган хыяллары хакында фәлсәфә дә ул. Герой тормышын исә сөйгәненнән башка һәм аның белән генә яшәгән утлы дөнья, дип бәяләргә, гомумиләштерергә булыр иде.

Укучы лирик миннең прототибын бик хаклы рәвештә шагыйрь үзе дип фаразлый. Әлеге герой мәгъшукасына сәҗдәдә, аңа тулысынча бирелгән, чөнки ул аның дөньясын үз яктылыгы белән тулысынча тутырган. Искә төшерик: суфичылык әдәбияты вәкилләре бу рәвешчә бары тик Алла, аңа баш-аяк гашыйклыйк турында гына яза иде. Кыскасы, Г. Кандалый яктылык һәм караңгылык мифологик комплексларын яңа шартларда, яңа темаларда куллана; дини әдәбияттан килгән мотивларны җир мәхәббәтен сурәтләү максатыннан файдалана.

Шунысы кызыклы: Г. Кандалый шигъриятендә еш кына нәкъ менә яктылык образлары мәгънәви, интонацион, тематик фокусларны тудыруда төп эш башкара, һәм аларның өч төре дә һәр әсәрдә очрый. Мәгънәви каршылыклар ату – коелу, яту; чәчәк ату вакыты (димәк, яз) – көз һәм башка төшенчәләр ярдәмендә белдерелә. Шул ук хәрәкәт фигыльләре (образлары), янәшә килеп яисә градация ярдәмендә бер төр хисне бик кискен икенчесенә күчерә яисә үстерә. Моннан чыгып, образлар фокус кысасына керә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Алда телгә алынган текстка тагын бер әйләнеп кайтыйк:

Сачәк бер вакыт атадыр,
Коела, йиргә ятадыр,
Кибәдер, корып катадыр,
Көзенә керсә ярендә.

Бу әсәрдә гомер үзгәрешләре, кыскалыгын чагылдыру өчен, негатив төсмергә ия фигыльләрдән тыш, көз фасылы телгә алына. Ул кызгану, читсенү, ассызыклау һәм башка интонацион төсмерләрне үкенеч һәм сагышныкына алмаштыра.

Югарыдагы ике төп структур өлештән торган һәм ике строфалы шигырьнең беренче өлеше аның кереше буларак каралырга хаклы. Ул, халык җырларындагы кебек, тыңлаучыны иң мөһим фикерне ишетергә хәзерли. Тәүге юллар һәрберебезгә таныш табигать күренешеннән хәбәр биреп кенә калмый, тематик каршылыкны да тудыра. Алга таба, әлеге каршылык яңа текстта бирелеп, шигъри фикер киңәйтелә.

Гомернең кыскалыгы, үлемнең көтмәгәндәлеге, вакытсызлыгы беренче строфада табигать кануннары кебек кенә тоелса, икенче строфа теманы мораль планда ача. Г. Кандалый, кешеләр арасында этик нормалар бозылганны я булмаса социаль гаделсезлекләр яшәгәнне «яшьтән үк кайгыга керү» гыйбарәсе аша шактый үзенчәлекле җиткерүгә ирешә. Шушы гыйбарә ярдәмендә без геройны бәхетсез итеп күзаллыйбыз да. Гомер, яшәеш темасы әнә шулай тискәре планда чишелә, ягъни аларда чагылыш тапкан төп конфликт уңай герой файдасына хәл ителми.

Кеше мөнәсәбәтләрен, лирик мин мәхәббәтен тасвирлау, күләм зурлыгы һәм образлар ноктасыннан караганда, башта алдагысыннан аерымрак торган кебек тоелган «Көләрмен мин» шигыре дә структур яктан шундый ук:

Көләрмен мин, елый дошман,–
Бәнем бәхтем ачылганда.
Йөрәгенә төшә хәсрәт,–
Уты бездә басылганда.

Әлеге шигырьдә беренче ике юл рәвешендә формалашкан мәгълүмати өлеш лирик геройның башкалар белән гадәтигә, ягъни даимигә әйләнә барган мөнәсәбәтләрен аңлату һәм бер үк вакытта тематик каршылыкны да хәбәр итү вазифасын башкара. Укучы алардан, герой элек – хәсрәттә, ә дошман бик бәхетле булган, ниһаять, бу урыннар алмашынган, дигән фикер чыгара. Бәхет һәм бәхетсезлекнең эчтәлеге чираттагы юллардан аңлашыла: ул эчке уйларга, кичерешләргә, күңел хисләренә бәйле. Әдәбиятта хәсрәт уты дигән символик образ бар, бу очракта ул мәгънә якынлыгындагы образларга таркатыла.

Кандалыйда кызыл төс, тутыя (цинк төсе), көмеш төсе, якутның кызыл һәм ак сирпелеше образны якты, ачык итеп чагылдыру максатыннан кулланыла, һәм аларга мисаллар чамасыз күп. Берсен китереп тә узыйк:

Кызыл гөл булмаса иде,
Кызарып тулмаса иде,
Шул айрылу белән үлем –
Икесе булмаса иде.

(«Кызыл гөл булмаса иде»)

Югарыдагы ялгыз строфалы шигырьдә туры мәгънәсендә дә яктылык образы беренче өлешкә кергән, икенче өлештә исә борынгы бик борынгыдан килгән мифологемалар кулланылган. Китерелгән әсәрләрнең структур охшашлыгы Г. Кандалыйның бер сайланган отышлы алымнар, конструкцияләр белән эш итүен күрсәтә. Бу – каләм иясенең үз стиле, әдәби иҗеге барлык турында сөйли.

Г. Кандалыйның мәхәббәт лирикасында әсәрләрнең һәр строфасы, һәр структур кисәге үзара тыгыз береккән, мәгънәви бербөтен тәшкил итә. Автор мәхәббәтле һәм якты шәхси күңел дөньясын сөйгәненең генә түгел, барлык гади халыкның, бигрәк тә җир кешесенең, крестьянның тормыш прозасына каршы куя һәм моңа ул фокус позицияләрендә ачык бирелгән традицион образлар ярдәмендә ирешә. Бу символларны төрле яссылыкларда төркемләргә булыр иде, без үзебез алган юнәлештә атап карыйк.

Әйтик, кызның тышкы сурәтен тудыруда катнашучы я булмаса лирик геройның рухи халәтен ачучы мифологемалар.

Язмабызда әлегә кадәр сатирик пландагы әдәби берәмлекләргә аз тукталдык. Тәнкыйди рухтагы әсәрләрдә Г. Кандалый яктылык һәм караңгылык образларын күбрәк үз идеалына туры килмәгән ир-ат яисә хатын-кыз портретын тудыру максатыннан куллана:

Күзең елтырыйдыр сулы чиләкди,
Авызың җәйрәгән иске иләкди.
(«Сәнең башың ирер мисле пудаука»

Шагыйрьләр беренче юлдагы төшенчәләрдән мәхәббәт сагышыннан елаган кыз образын тудыру өчен дә файдалана алырлар иде, чираттагы мисрагъ беренче юлның негатив мәгънәсен генә калдыра.

Теге яки бу текст эчендә генә түгел, гомумән, иҗатта мифологемалар төрле комплекслар барлыкка китергәндә, яңа заман тудырган образлар шул җирлектә бигрәк тә ачык, җетеләнеп күренә башлый. Әйтик, Г. Кандалый «Сурәтең дөшемә керер» әсәрендә кызны күкрәген калкытып биюче рәвешендә күрсәтә, ә лирик минне водолазга тиңли, хыялында булса да кочагында ятуын – суга чумып, сөйгәне белән кочышкан, очышкан егет сурәте аша тасвирлый.

Тәүге чор әдәбиятларда караңгылык һәм яктылык көрәшен тасвирлау омтылышы табигать күренешләренә, теге яки бу предметларга шул көрәштә символик мәгънә бирүгә китергән; алар элементар хисси кабул итешкә нигезләнгән; алга таба бу образлар мәгънә үзгәрешләре кичергән, чөнки төрле эчтәлектәге текстларга трансформацияләнгән. Г. Кандалый иҗат иткән яңа образлар да, бигрәк тә милли җирлектә барлыкка килгәннәре кеше тоемчанлыгының үзенең дә бинарлыгын күрсәтә, аерым әсәрләрендә исә мәгърифәтчелек карашларын уздыруга хезмәт иткән төп тормыш антиномияләрен (наданлык-белемлелек, рухи байлык-рухи кысырлык; игелеклелек-игелексезлек; руханилар яшәеше һәм мужиклар тормышы һ.б.) тасвирлауда катнаша. Шунысы кызык: социаль тормыш каршылыклары шагыйрь иҗатында мәхәббәт темасы үзәккә куелган әсәрләрдә аеруча калку чагылыш таба.

Г. Кандалый каләменнән төшкән әсәрләрдә хатын-кыз һәм ир-ат; галим һәм укымышсыз гади кеше, ирек сөйгән мулла һәм

гавам халкы мәңгелек антогонизмда яши; яктылык, ут, металл, таш, корал һ.б. төшенчәләрнең оясы яисә рәте булган кебек, алар арасында мифик бәйләнешләр барлыгы да ачык тоемлана; мифологик комплексларның күпчелеге тамырлары белән дини-суфичыл әдәбиятка барып тоташа.

## «БАР ГАЕБЕҢ ИХЛАСЛЫК БУЛГАН, ШАГЫЙРЬ!» ЯКИ МУЛЛА МӘХӘББӘТЕ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

*Ф.Ф. Хәсәнова*

Шагыйрь Г. Кандалыйның исеме, иҗатының бер өлеше татар җәмәгатьчелегенә күптән мәгълүм. Шул таныш материалдан чыгып та, шагыйрьнең язу осталыгын, аның татар әдәбияты үсешенә керткән бәхәссез яңалыгын танымаган кеше юктыр. Бу яңалык бигрәк тә шигырь поэтикасы, мәхәббәт лирикасы өлкәсенә карый. Кандалый шигърияте нигездә авыл мулласының крестьян кызына булган җавапсыз мәхәббәтен тасвирлый.

«Ни өчен җавапсыз?» дигән сорау туа. Безгә мәгълүм әсәрләрдән чыгып әйтергә мөмкин: ул вакытта дин әһелләренең авылларда вәкаләтләре чиксез зур булган. XIX гасыр прозаигы Закир Һадиның (1863–1932) «Бәхетле кыз»ында бу мәсьәлә бигрәк тә ачык чагылган [Һади, 1957: 22–63]. Бу чорда күп кенә атаана үз кызын абыстай ролендә күрергә теләгән. Еш кына кызның теләге белән хисаплашмаганнар да.

Мәсьәләгә сыйнфыйлык позициясеннән якын килик. Гадәттә дин әһелләре гаилә кора торган парны үз даирәсеннән сайлаган. Тик җиде буын нәселе муллалар булган Кандалыйга гына бу тәртип ярамаган. Аңа крестьян кызы кирәк булган. «Ни өчен?» дигән сорау туа.

Авыл мулласына ул чорда мәхәлләдә мулла, хәлфә, полиция, загс, нотариус, судья, прокурор хезмәтләре йөкләнгән. Кандалый әле шулар өстенә шагыйрь дә. Әлеге һөнәр ияләренә куелган таләпләрнең барысын да үтәп бетерә алган шәхес кенә түгел, әдәби геройлар да сирәк очрый. Билгеле, Гариф Ахуновның Кандалыйдан соң бер гасыр үткәч тудырган Габбас мулласын шундый үрнәкнең берсе итеп карап булыр. Әмма ул да фаҗига белән тәмамлана.

Димәк, Кандалыйның шагыйрь һәм мулла буларак беренче фаҗигасенең сәбәбе – татар гаиләсе традицияләрен үз мәнфәгатьләре файдасына бозуы. Дөрес, З. Һадиның «Җиһанша хәзрәт»е (1908), дини даирәдә кабул ителгән язылмаган кагыйдәдән чыгып, хатыннарының составын «төрләндерә»: бер хатыны мулла кызы булса, икенчесенә бай кызын ала [Һади: 1957, 140–186]. Кандалый да «бу тәртип»тән читтә калмагандыр дип фаразлыйк.

Җәмәгатьчелек Кандалыйны, нигездә, «Мулла белән абыстай» шигыре, «Сәхипҗамал» поэмасы буенча белә [Кандалый, 1988: 388–428]. Хат стилендә язылган бу поэма лирик геройның мәгъшукасына ялваруы, яшьлегенә соклануы, кызның алдагы тормышында бердәнбер лаеклы кандидат-ир булачагы, хыялдагы планының барып чыккан очракта әкияттәгедәй киләчәге турында сөйләү белән үрелеп бара. Әмма кыз күрәсең күктәге торнага түгел, кулдагы күгәрченгә күбрәк ышанган булса кирәк. Кандалыйның поэмада куркыту, өркетү, крестьян ирләрен соңгы сүзләр белән хурлавын, кыскасы, шантаж юлына басуын башкача аңлатып булмый.

Кандалыйның әлеге гамәлләрен акларга да мөмкин. Бу очракта Закир Һадиның 1904 елда язылган «Бәхетле кыз» хикәясеннән бер өзек китерү кулай булыр. Хикәянең төп герое иске карашлы авыл мулласы – Ибәт абызагай. Ул алдау юлы белән, яучы аша, җитеш, бай тормышлы гаиләдән укыган, белемле, әхлаклы Хәдичә исемле кызны хатынлыкка ала. Аның хатын-кызга карашы авылның башка ирләреннән аерылмый. *«Бу авыл халкы хатыннарны ат, ишәк кеби хезмәт өчен яратылмыш бер хайван дип белә иде»* [Һади: 25]. Менә авыл мулласының үз фикере нинди: *«Ибәт абызагайның игътикадында* (ышануында) *хатыннар кәнизәк кебек ихтыярсыз* (ирексез) *затлар: ирләр аларны никадәр җәберләсә дә, аны җәбердән санамый иде. Бәгъзе вакытларда хатыннар, ирләре бик җәбер кыйлгач, ирләренә нәсихәт кыйлмас микән дип, Ибәт абызагайга баралар иде. Ибәт абызагай ирләрен чакырып: “Хатыннарыгызның тезгенен каты тотыгыз! Бик сикермәсеннәр!” – дип, орышып җибәрә иде»* [Һади: 24]. Кандалый үлгәннән соң кырык еллап вакыт үткәч язылган фактлар белән танышкач, шагыйрь үз чорын алдан яшәгән, күпкә алга китеп күргән дигән фикер туа. Ярты гасыр тирәсе алданрак бару сәбәпле, Кандалый үз яшьтәшләре тарафыннан һәм үзе яшәгән даирәдә хуплау тапмагандыр.

XIX гасыр әдәбияты – ул мәгърифәтчелек әдәбияты [Гайнуллин, 1979]. Бу чор әдәбияты – дидактик әдәбият. Ул балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә ислам әдәбияты кануннары буенча яшәргә чакыра торган әдәбият. Мәгърифәтчеләр фикеренчә, бала ата-анасы сүзеннән чыгарга тиеш түгел, алар кушканны үтәргә, тыңларга, алар өйрәткәнчә яшәргә тиеш. Билгеле, мәгърифәтчеләр ата-ананың үзенә дә зур таләпләр куйган: әдәпле, белемле, һөнәрле, димәк, җитешле гаилә булырга һәм булдырырга. Мәгърифәтчелек әдәбияты баланың мөстәкыйльлеген дә яклап чыккан. Шул ук З. Һадиның «Мәгъсум»ен (1906) искә алу да җитә. Аны әнисе Хәят абыстай унике яшендә авылларыннан шактый ерак булган кадими мәдрәсәгә укырга озата. Мәгъсум, бер дә барасы килмәсә дә, әтисе васыяте, әнисе теләге буенча үзен егерме яшькә дә җитмичә кабергә китерәчәк мәдрәсәгә китеп бара.

Ә менә Кандалый кызларны ата-ана сүзен тыңлау тиеш дигән традицияне бозарга чакыра, ягъни, ата-ана сүзенә каршы барып, үзең теләгән кешегә чыгарга. Шигырьләрдән аңлашылганча, бу «үзең теләгән кеше» күбесенчә Кандалыйның үзенә кайтып кала. Онытмыйк, аның кулында шактый зур власть. Ул үгетнәсихәтсез генә дә үзе теләгәнен кулына төшерә алган булыр иде. Шулай итеп лирик геройның һәр кылган гамәленә ике яклап бәя бирергә була. М. Госманов юкка гына Кандалыйны ике кеше итеп карамыйдыр. Берсе – аның шагыйрь, икенчесе – дин әһеле [Кандалый, 1988].

Тарихтан билгеле, Кандалыйның аш мәҗлесләрендә ачыктан-ачык хуҗа кызларына карата «әдәпсез» шигырьләр чыгаруы, үзен яшермичә азгын мулла кебек тотуы авыл халкының ачуын чыгара, ул берара муллалыгын югалтып та тора, ике еллап төрмәдә дә утырып чыга. Сәбәбен хәтта М. Госманов та әйтми. Бу очракта рухани сыйныфка куелган таләпләр, регламент кагыйдәләре үтәлмәү, билгеле бер сыйныфка куелган тәртипләрнең сакланмавы сәбәп булгандыр, дигән нәтиҗәгә киленә.

Билгеле, Кандалыйның шигырьләре бик халыкчан яңгырашлы, эмоциональ характерлы, кыскасы, җырлап тора торган. Ул чын халык шагыйре. Шул сәбәпле Кандалый халык тарафыннан яратып кабул ителгән. Кандалый әсәрләрендә күтәрелгән проблемаларның халыкчан булуы бәетләрдә дә урын ала. Мисал өчен «Әткәй бирде чи наданга» һәм «Наданга бирелгән кыз бәете»нә игътибар итик [Бәетләр, 2001: 179, 180].

Алтын микән, көмеш микән бишмәтемнең баулары,
Надан ярның кочагында сызыла йөрәк майлары.

Наданнарның бармаклары сазда үскән тал кебек,
Галимнәрнең һәрбер сүзе шикәр белән бал кебек.

Бәеттә үзе яраткан Бәхтияр исемле шәкерткә бара алмаган кызның газаплы тормышы турында сөйләнелә. Шулай ук аның үз этисен каргавы да урын алган. Бу бәетнең 1920 елда Рязань өлкәсе Вәрәкә авылында язып алынуы күрсәтелгән. Икенче бәеттә галимә кызның көчләп надан иргә бирелүе турында әйтелә. Бу әсәр дә каргау сүзе белән тәмамлана, ләкин бу юлы каргыш яучыга яудырыла. Аннан аңлашылганча, белемле кеше тормыштагы бар проблеманы хәл итә ала. Киресенчә булганда, кызны эт тормышы көтә. Әле алай гына да түгел:

Зифа буем үсеп җиткәч, эткәй бирде наданга,
Надан егетләр саналыр шайтаннан да яманга.

Надан ятса йокыга, каткан тунын ябыныр,
Йокысыннан уятсаң, бусагага абыныр.

Бу бәет 1900 елда чыгарылган дип санала. Димәк, Кандалый үлеп, 40 ел вакыт үткәч тә проблемалар үзгәрмәгән дигән нәтиҗәгә кабаттан киләбез.

XIX гасырда укый-яза белгән кешеләрнең «галим» диеп йөртелүе билгеле. Кандалыйның мәгъшукалары да хәреф таный белгәнгә охшап тора. Шагыйрь алар белән хат телендә сөйләшә, җавап та көтеп яши. Эпистоляр жанрга хас булганча, лирик герой үз хисләрен ачыктан ачык яза, яшерми, хәтта элементар әдәп саклауны да кирәк тапмый.

Бер күрүдә һәм еш гашыйк булучан, дәртле Кандалый һәртөрле көндәшлекне кабул итмәгән дип уйларга нигез бар. Ул чорда авылда муллалар күп була алмаган, димәк, көндәшләр крестьян арасыннан гына табылган. Кандалыйның көндәшлекне кабул итә алмаганлыгы шигырьләрендә ярылып ята. Шуның өстенә әле ул «кара мажик» көндәшне генә түгел, бай көндәшне дә кабул итми. Дөрес, байга ул факт буларак кына карый, һәрхәлдә тупас зәһәрен яудырмый.

Бу дөньядан киткәненә 155 ел булган Г. Кандалый иҗаты белән бүген дә кызыксыну кимеми. Шагыйрьләр аңа тулаем уңай карашын белдерә, мәхәббәт лирикасын үзенә үрнәк өлге итеп ала.

XIX гасырда яшәп иҗат иткән татар мәгърифәтчеләренең XX йөз ахыры XXI гасыр башы әдәбият тарихын язган галимнәргә, дин эшлеклеләренә, татар язучыларына да бернинди дәгъвасы була алмас. Бүген дә язучылар еш кына XIX гасыр әдәбиятына, бу гасырның күренекле шәхесләренә, алар калдырган хезмәтләргә мөрәҗәгать итеп яши.

Күренекле сатирик шагыйрь Гамил Афзал, XIX гасырда туган язучыларга багышлап, унлап шигырьне туплаган аерым бер цикл тудырды [Афзал, 2004: 189]. Шуларның берсе Г. Кандалыйга тәгаенләнә. Шигырь, Кандалый үлеп йөз ел үткәч, Хатип Госман тарафыннан чыгарылган шигырьләр китабы турында [Кандалый, 1960].

Шагыйрь юлы – кометалар юлы,
Ялтырый да, көмеш юл ярып,
Йөз ел буе әллә кайда йөри,
Галактикаларда югалып.

Шагыйрьләр дә форсат көтеп ята,
Җыры, эзе калган бу җиргә,
Онытылып беткәч тагын кайта,
Бер ялтырап, балкып йөрергә.

Ә менә XX гасырның фәнни җәмәгатьчелектә дә, язучылар тарафыннан да мәхәббәт шагыйре буларак танылган халык шагыйре Рәдиф Гаташ Кандалыйга газәл багышлый [Гаташ, 2009: 52]. Газәлнең эчтәлегенә Кандалыйның хатлары, мәхәббәт лирикасы, мәңге гашыйк шагыйрьнең күңел ярасы, аңа каршы фикерләр, бүгенге җәмәгатьчелекнең аны ничек кабул итүе – барысы, барысы кереп бетә. Мисал өчен газәлнең үзенә мөрәҗәгать итик:

Пакь яшьлегең саклый алса ялгыштан,
Сакласын шагыйрь яшеннән – каргыштан.

Гомереңә җитәр төшсә рәнҗеше –
Язмышыңда эз булыр, тап рәвешле...

Чөнки ихлас шагыйрь җаныннан аһлар –
Тәңресенә, шиксез, ирешер хатлар!

Шундый дога Кандалый хәзрәт кылды:
Ярга ялварганы – чын каргыш булды.

Гыйбрәт өчен калдырды яманатын!
...Юк, шагыйрьләр, фаш итмәгез яр атын.

Бары сезне яклый-аклый гасырлар!
...Сөймәсәләр, гаепләмә матурлар?!

Сөйсә алар – чын «фәрештә валчыгы»,
«Гөнаһлы» ярның да сез дә бит гашыйгы...

Аһ, саклый күр күңелеңне шул каргыштан,
Мәңгелек үзе таш атар язмыштан!

Билгеле, Гаташ шигыре дидактика түгел инде. Аның лирик герое Кандалый кебек үз хисләрен мәҗбүриләп такмый. Бу газәлендә аның гашыйк кешегә психологик яктан якын килүе, мәкъшукны тирәнтен аңлавы күренә.

Кандалый иҗаты Гаташны робагый язарга да рухландыра. Әдәбиятны, аның тарихын, теориясен тирән белән шагыйрь мәхәббәткә дә фәлсәфи планда якын килә. Шул ук вакытта аның лирик герое җавапсыз мәхәббәттән курка да булса кирәк. Бер робагые шул турыда сөйли:

**Сәхипҗамал – Кандалый даны**

Сәхипҗамал абыстайның оныгы
Түгелме син? Пәрәү кызы туруны?
Рухи бабам, шиксез, Кандалый хәзрәт,
Илгә фаш булса да сөю – урынлы! – дип,

шагыйрь тантана итә. Р. Гаташ заман татар шагыйрьләре арасында Кандалый кебек мәхәббәт шигырь-хатларын иң күп язучы булып танылды. Аның хатлары төгәл классик формаларга утыртылган, газәл, робагый, иреклe шигырь, традицион формалылары да бар. Шагыйрь үзе үк аларның адресатын да билгеле.

Ялкын тулы бу хатлар кемгә, дисәң,
Мирас алар дөньяга безнең хистән, – ди.

Кандалыйның мәхәббәт хатлары зур шагыйрьләрдә һәрвакыт соклану уяткан. 1997 елда Илдар Юзеев шундый бер шигыренең исемен «Киләчәк кызына хат» дип исемли [Юзеев, 2002, 1 т.: 234]. Шигырьдәге төп мотив – Кандалый кебек тик бер хат язу. Шигырьдә лирик геройның шикләнүләре дә урын ала. XIX гасыр кызлары Кандалыйның хатта язылган хисләрен кабул итмәгәч, XXI гасыр кызлары хатның үзен укып та мәшәкатьләнмәс дигән фаразын үткәрә.

Килеп җитте Кандалыйның
Сөю хатлары.

Гашыйк кызлар шигырьләрен
Сөеп ятлады.
Күп кызларны сөю гөнаһ
Саналмый кебек.
Мин дә бик күп гашыйк булдым
Кандалый кебек.
«Җырың яшәр!» – диеп күңел
Алдалый кебек.
Хыялым – тик бер хат язу
Кандалый кебек.
Ышанам һәм өмет баглыйм
Шигырь-җырларга.
Хатым китсен сез яшәгән
Ерак елларга.
Сөю яшәр, хис тә яшәр,
Сизәм: алар нык!
Тик калырмы татар кызы
Мине аңларлык?
Җаныгызда бу хатыма
Табылса урын,
Сөенечтән сезне кочып
Еласын җырым...

Бүген хәтта сәясәт һәм икътисад та XIX гасыр мәгърифәтчеләре әйтеп калдырган фикерләргә әйләнеп кайта башлады кебек. Мисал өчен, 2019 нчы елда Казанда булачак эшче һөнәрләре профессиясе чемпионатын гына алу да җитәр. Мәшһүр Парижлар белән узышып, Казан бу ярышны үзендә үткәрү хокукын яулап алды.

Әле XX гасырның 90 нчы елларында гына урта мәктәпне тәмамлаган һәр яшь кешенең югары белемгә ия булуы хуплана иде. Мәктәпләр югары уку йортына керүнең 100% лы күрсәткече белән мактана килде. Йөз үк булмаса да моңа ирешелде. Нәтиҗәдә эш белән мәшгульлек үзәкләре югары белемле яшь белгечләр белән тулды. Шул ук вакытта эшче һөнәрләргә вакансияләр артты, дөресрәге, кул белән тотып эшли торган кеше калмады.

Әмма мәктәпләргә ЕГЭ формасын кертү, аның бары тик рус телендә генә булуы югары белем алуның массачыл тәртибен киметте. Бүгенге көндә төп мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең яртысы, хәтта күбрәге дә һөнәр бирә торган уку йортларына бара башлады. Киләчәктә бу күрсәткечнең тагын артуы көтелә.

Болар барысы бүгенге көн өчен мәгариф системасының яңалыгы буларак кабул ителсә дә, XIX гасыр әдәбиятында яңалык түгел. Бу чорның мәгърифәтче язучылары прозада заман героеннан, беренче чиратта, белемле һәм әхлаклы булу, белем-тәрбияле тигез гаиләдә үсү, камил сәламәтлеккә ирешеп, тормыш итәр өчен практик яктан файдасы тиярлек һөнәрле булу, халык һәм җәмәгать интересларын шәхси мәнфәгатьләрдән өстен кую кебек сыйфатларны таләп иткән.

XIX йөз белән соклану хисе Флера Тарханова шигырьләренә дә хас [Тарханова, 2005]. Аның бер шигыре «Унтугызынчы йөз кешесемен» дип атала. Шигырьдә бу чор идеаллаштырыла, итагатьле, матур сүзләр генә сөйләнгән чор итеп күрсәтелә, тел сәясәте XXI гасыр белән чагыштырыла, бүген «ана сөте белән керми калгангадыр, бик күпләрнең сөйләм, тел ватык» дигән факт китерелә. Шигырь лирик геройның XIX гасырга кайтырга теләвен әйтеп тәмамлана.

Унтугызынчы йөз кешесемен –
Яшәр идем тик шул гасырда.
Хөсетле һәм чирле яңа чорга
Куркам хәтта аяк басарга, –

дип белдерә шагыйрә.

XIX гасыр татар әдәбияты өчен игенче һөнәре аерым әһәмияткә ия. Татар крестьянының авыр хезмәте, төп геройның тормыш итү кәсебенә әверелеп, әдәби әсәрләрдә урын ала. Бу чор муллалык дәрәҗәсенең нәселдән нәселгә күчереп баруы белән аерылып тора. Мәгърифәтче әдипләр арасында атасы сәүдәгәр яки башка һөнәр иясе булганнар бик аз. Игенченең кешелекне туендыручы булганлыгы билгеле, әмма авылда яшәп гомер иткән Кандалыйның игенче һөнәренә, хезмәтенә кимсетеп каравы мәгълүм. 17–18 яшендә үк «Иген икмәк – михнәт чикмәк», дигәндә ул, бәхәссез, хаклы, тик шул игенченең хезмәтеннән бер генә дә позитив чаткы күрмәвен ничек аңлатырга да белмәссең. Аның өчен игенче – «надан бер кара мажик», Кандалый аны сурәтләгәндә кара буяуларны бер дә кызганмый, күз алдына хәтта кеше түгел, тупас, пычрак табигый инстинктлары белән ниндидер исемсез хайван килеп баса. Шунысы гаҗәп: ул «хайван» Кандалыйның өстәлендә тәгам булсын өчен тырыша.

Әлеге мәсьәләдә М. Госманов фикерләренә мөрәҗәгать итик. Ул «гадәти дөнья интересларына, хуҗалык эшләренә җирәнеп

карау – «фани дөнья»дан йөз чөерү – тәсауыф тәгълиматының төп идеяләренең берсе», дип язып чыга. Бу идеянең мулла Кандалыйда нәселдән нәселгә күчеп баруын гадәти күренеш дип саный. Гел акыл эше белән генә шөгыльләнү, китап уку эше генә хөрмәткә лаек, дигән тәрбиянең Кандалыйга ана сөте белән кергән булуын, аның башкача уйлый алмавын, икенче төрле әйткәндә, эгоистлыгын шуның белән аңлата. М. Госманов Кандалыйның сәер гадәтләрен табигый талантка бәйли, аның укыган вакытта ук калкып чыккан акыл өстенлеген гадәти хәл итеп карый. Бу мәсьәләдә Кандалыйның беренче булмавын искәртә, чын татар шагыйре булган (Көнчыгыш түгел дип аңларга!) Г. Утыз-Имәнинең дә берничә порнографик әсәре булуын әйтә [Кандалый, 1988: 17].

XX гасыр ахырында Кандалый кебек туган җире Ульяновск җирлеге булган шагыйрь Ренат Харис «Өч үбешү» исемле үзе үк эротик дип атаган поэма язды [Харисов, 2006: 184]. Поэманың Кандалый иҗаты белән тыгыз бәйләнеше бар. Өч бүлектән гыйбарәт булган поэмага «Сәхипҗамал»дан өч цитата куелган. Аларның эчтәлеген нәзакатьле дип атап булмас иде. Билгеле, халык шагыйре поэмада порнография дәрәҗәсенә төшми, физиология мәсьәләсен әдәби образлыкка күчерә белә, ислам дине кагыйдәләреннән чыкмый, гаилә иминлегенә кагылмыйча гына нәсел калдыруга килеп чыга, һәм шуның белән лирик персонажга карата соклану хисләре тудыруга ирешә.

Ренат Харисның Кандалый белән мавыгуын шагыйрь Роберт Миңнуллин «эләктереп ала» һәм үзенең «Ренат Харис шигырь укый» исемле пародиясен багышлый [Миңнуллин, 2007: 53]. Пародиядә Р. Харисның эротик поэманы каләмдәшләренә җиткерү вакыты турында сөйләнелә. Шагыйрь дәртләнеп укый, фикердәшләре бик теләп тыңлый. Гомумән, шигырьнең тыңлаучыга тәэсир итү көче турында җиткерелә.

Укыганда тамагын да
Кырып-кырып алгалый...
Ренат Харис шигырь укый.
Укыганы – Кандалый.
Иң татлы урыннарында
Юри туктап алгалый.
Бу – бөтенләй башка Харис,
Бу – өр-яңа Кандалый.

Соңыннан «Чыннан да бөек икән шул Габделҗаббар Кандалый!» дигән нәтиҗә ясала.

Туфан Миңнуллинның «Шагыйрьнең җанында, эчендә һәрвакыт яра булырга тиеш. Ул һәрвакыт авыртып торырга тиеш. Шул чагында гына ул әйбәт шагыйрь була ала», дигән сүзләре билгеле [Миңнуллин, 2015: 184]. Кандалыйны да Сәхипҗамалга булган җавапсыз мәхәббәт ярасы гомер буе бимазалап торган булса кирәк. М. Госманов фикеренчә, Сәхипҗамалга юнәлтелгән җырлары, еллар үткәч үзгәртелеп, Фәрхи исеменә юнәлтелә. Фәрхигә гашыйк булганнан соң аның иң матур шигырьләрен язганы билгеле. Бу юлы теләгенә дә ирешә ул, өйләнә. Тик ахырдан барыбер аерыла. Аннан соң Хәлимәгә өйләнеп карый, әмма инде дәртле шигырьләре язылмый башлый. Безгә нәкъ менә шул Хәлимәнең Кандалый мирасын таратканы билгеле була.

Кандалыйның безгә килеп җиткән мирасы да кызыксынып укыла, диссертацияләр языла, башка шагыйрьләрнең иҗатларында телгә алына, хәтта аңа ияреп язулар да очрый. Бу инде теманың дәвамлы, иҗатның кызыклы булуы турында сөйли. Сүзебезне заман шагыйре Р. Гаташ фикере белән тәмамлыйк:

Бар гаебең ихласлык булган, шагыйрь!
Аңлаган җирдә сине кайсы әмир?!..
Кыз урлаган ирне дә аклаган мир, –
Без дә шул заттан, хакимнәр, белегез!
Мәхәббәт шагыйрен таный белегез! –
Сәер җаннарны танып баш иегез.
Мәхәббәт шагыйрен яклый белегез!

ӘДӘБИЯТ


1. Афзал Гамил. Сайланма әсәрләр: 3 томда. 2 том: юмор һәм сатира, лирика, публицистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. –335 б.

2. Гаташ Г.К. Сайланма әсәрләр: 3 томда / Кереш сүз авт. Х. Миңнегулов, Р. Зәйдулла, Р. Ганиева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.

3. Кандалый Г. Шигырьләр / Төз. Х. Госман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 188 б.

4. Кандалый Габделҗаббар. Шигырьләр һәм поэмалар. Төз., текст һәм иск. хәз., кереш сүз авт. М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 558 б.

5. Миңнуллин Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. 2 том: шигырьләр, җырлар, эпиграммалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 591 б.

6. Миңнуллин Р.М. Яра // Казан утлары. – 2015. –№ 7.

7. Тарханова Ф.Г. Яшьлек эзем калган сукмаклар: шигырьләр, җырлар, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. –223 б.

8. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты / Төз. М. Гайнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.
9. Татар эпосы. Бәетләр / Ф. Әхмәтова-Урманче. – Казан: Раннур, 2001. – 512 б.
10. Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. 4 том: поэмалар / Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Ф. Хәсәнова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 367 б.
11. Һади Закир. Сайланма әсәрләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1957.
12. Юзеев И. Сайланма әсәрләр: 5 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 383 б.

# РЕЛИГИОЗНАЯ ФИЛОСОФИЯ ТВОРЧЕСТВА ГАБДЕЛЬДЖАББАРА КАНДАЛЫЙ

*А.Х. Садекова, Р.Ф. Сафиуллина*

Творчество татарского поэта Габдельджаббара Кандалый (1797–1860), жившего и творившего в XlX в., опирается на многовековые литературные традиции народа. Исторически сложилось так, что литературные традиции веками переплетались с устным народным творчеством. Взаимовлияние традиций литературы и фольклора особенно четко прослеживается в религиозных жанрах, таких как мунаджаты, баиты, риваяты, исторические песни. Это связано с тем, что после принятия ислама сознание, менталитет народа, его духовно-нравственные ориентиры были проникнуты идеями ислама.

При изучении творческого наследия Кандалый нетрудно убедиться в том, что поэт следовал народной традиции. Это проявилось в использовании жанрово-тематических, стилевых, идейно-сюжетных, образно-поэтических приемов. Если творчество Кандалый подразделять на начальный и зрелый этапы (Татар әдәбияты тарихы, т. ll, с. 194), то следование поэта традициям, исламская направленность его стихотворений заметны уже с шакирдской поры.

Ученики медресе с раннего возраста приобщались к литературному наследию народов мусульманского Востока. Во-первых, программная литература медресе состояла из таких произведений и шакирды изучали их в качестве религиозно-светских учебных дисциплин. (Это и «Кыйссаи Йосыф» Кул Гали, «Мухаммадия» Челеби и др.) Во-вторых, они переписывали

произведения известных и неизвестных авторов. В-третьих, подражая имеющимся образцам, ученики самостоятельно пробовали перо.

Существовала традиция шакирдских тетрадей, которые распространялись и в народе. Был специфический «фольклор медресе» – озорные и насмешливые частушки, баиты, часто – серьезные. Характерным для этого жанра является легкость стиля, употребление арабских слов, своеобразной фразеологии, например *шәкерт, талиб, хәлфә, мәдрәсә* и т.д. Г. Кандалый – питомец, воспитанник этой среды, как и многие сверстники, интересовался тюрки-фарси-арабскими языками, усиленно познавал мусульманскую поэзию.

Как отмечает академик М. Усманов: «Особенно сильным было влияние на поэта средневековой ираноязычной суфийской поэзии, с одной стороны, и устного творчества своего народа, с другой (Кандалый, с. 551). В поэме «Рисаләил-л-иршад» юный поэт проповедует человеческие добродетели и порицает пороки. Особая добродетель – стремление к знаниям, ученье. А невежество приводит ко многим бедам и грехам и поэтому является наихудшим пороком.

Җәһаләтлек – яманлыкдыр
Бере аның – наданлыкдыр,
Болардан һич яман юкдыр
Гизәрсең гәр зәмин-асман.
(Кандалый, с. 248)

(Невежество – зло из зол,
Одно из зол – безграмотность.
Хуже их нет ничего
На свете: ни на земле, ни в небе), –

отмечает юноша Габдельджаббар в поэме «Рисаләил-л-иршад». Стремление к знаниям, к просвещению в исламе, в хадисах пророка поощряется. Это один из фардов (обязательных к исполнению действий) по шариату. Данное положение нашло отражение как в литературе (произведения суфийских поэтов Ахмеда Ясави, Сулеймана Бакыргани, Кул Шарифа, Мауля Колый, Утыз Имяни, Габденнасыра Курсави. Истоки же следует искать у Шейха Фаридатдина, Мухаммеда Гаттара и др.), так и в фольклоре.

В образцах афористических жанров устной поэзии также явственно видно, что народ относился невежеству резко отрицательно:

Надан кеше – яман кеше.

(Невежественный человек – плохой человек).

Наданның аяк баскан җирендә үлән корыр.

(Где невежа ступает, там трава увядает).

Мотив ученья в произведениях Кандалый встречается повсеместно, на протяжении всего творчества. Будучи образованным человеком своего времени, Габдельджаббар хазрет содержал медресе, был потомственным имамом. Следовательно, в немалой степени способствовал просвещению сельчан. Очень тонко, образно сравнивает поэт просвещенного человека с птицей, парящей в небе:

Гүя очкан кош кебидер гыйлем кеше…
(Кандалый, с. 173)

Очевидно, Кандалый позаимствовал метафору у народа:

Галим булсаң, галәм синеке.

(Если ты ученый – Вселенная твоя)

или:

Өйрәнгән җирдә калмас.

(Выученное на земле не залежится).

Просвещенность, знания помогают одолеть такие греховные пороки, как гордыня (кәбир), испорченность, невоздержанность в желаниях (нәфес), алчность.

Һәуа сахибе зурланыр,
Кәсеб итәргә хурланыр,
Зәмимә берлә болганыр
Булыр нәфесе зурында.
(Кандалый, с. 71)

(Обладатель гордыни будет возвышать себя,
Брезговать честным трудом,
Погрязнет в пороках,
Станет рабом собственного вожделения.)

В религиозном фольклоре, в народных произведениях, а также в творчестве поэтов эти качества глубоко порицались. Знание канонов жизни, столпов имана (веры) помогает избегать их.

Поэтому, вполне естественно, поэт горько сожалеет о времени, проведенном без учения, в беспечности (гафләт):

Гыйлемлек булмады бездә, –
Йөрепмез гъәфләтә һәр ан.
(Кандалый, с. 74).

Пословица «Белем – нур, белмәү – хур (Ученье – свет, а неученье – позор)» восходит к учению пророка. Например, иман (вера), гыйлем (знание) сравниваются здесь с лучом. Особенно в народе пользовались уважением и ценились люди, умеющие читать Коран.

Үзең яхшы, китаб-Коръән укыган
(Кандалый, с. 150)

(Ты благонравна – читала книгу-Коран…)

Обилие арабских заимствований, в частности, лексики и выражений из текста священной книги мусульман, употребление имен Всевышнего – вот особенность народных мунаджатов и произведений татарских поэтов начиная с Кул Гали. Это отчетливо указывает на их принадлежность к конкретной, в данном случае к исламской, культуре. У Кандалый, особенно в его раннем творчестве, очень много арабизмов. В более зрелом возрасте поэт максимально приблизился к живому языку и стилистике поэзии современного ему народа. Однако традиционные мотивы остались, потому что поэтическое творчество народа на протяжении многих веков проникнуто идеями ислама.

Иляһи, барча галәмне
Яратдың кодрәтең берлән.
Нәҗат кыйл рәхмәтең берлән
Бәңа дөшкән җәфалардин.
(Кандалый, с. 88)

(Всевышний, весь мир
Создал ты мощью своей
Милость нам окажи,
Спаси от напастей.)
(пер. Садековой)

Строфы этого стихотворения созвучны с аятами из суры Корана «Фатиха»:

Хвала Аллаху, Господу миров,
милостивому, милосердному,
царю в день суда!
Тебе мы поклоняемся и просим помочь!
веди нас по дороге прямой,
по дороге тех, которых ты облагодетельствовал, –
не тех, которые находятся под гневом, и не заблудших.

Подтверждение этим мыслям можно найти и у самого Кандалый:

Буең күрдем, дидем: әлхәмделилла!
Йөзең күрдем – укыдым «Куль һу Алла»
(Кандалый, с. ).

(Увидел грацию, воскликнул: хвала Аллаху!
Увидел твой лик – прочитал суру «Куль һу Алла»).

«…У молодого Кандалый идеи суфизма были недостаточно сильны. Поэтому позже… суфийские идеи ломаются у самого основания», – считает М. Усманов (Кандалый, с. 61). Служитель исламского культа, мулла, который с самого рождения и даже на генетическом уровне «впитал» вышеозначенные идеи и в течение двух десятков лет (курс обучения в медресе включал все ступени образования – от начального до высшего) получал традиционное образование, не мог не проникнуться исламским мировоззрением. И если автор поэм «Рисаләи-л-иршад» и «Кыйсса-и-Ибраһим Әдһәм» впоследствии начал писать о переживаниях и чаяниях, страстях и слабостях обычного человека, это не значит, что на смену одним духовным ценностям пришли другие. Скорее, данные изменения следует связывать с взрывной, беспокойной натурой самого автора. Легенды о жизни Кандалый, дошедшие до нас, характеризуют поэта как человека порывистого, горячего. Ему немало пришлось страдать из-за своего нрава. Кроме того, творческая одаренность сама по себе большая ответственность и нравственно-психологическое бремя. Даже и простым смертным порой не хватает душевного спокойствия, о чем говорится в Коране (сура «Гаср»). Поэт очень часто обращался к мотиву терпеливости.

Одним из лучших свойств характера мусульманина являются выдержка и терпение. В Коране терпеливость упоминается во многих сурах. «Богоугодное свойство нашло отражение во многих мунаджатах. Татары-мусульмане считают, что терпение помогает пережить трудности, горе и печали, которые нет-нет да выпадают на долю живущих на земле» (Садекова, с. 243).

Иляһи, бу асыл кошны
Тубай агачына кундыр.
Иляһи, мин сабырсызны
Сабырлык юлына күндер.

(О Всевышний, эту птицу
Вознеси на дерево тубай.
О Всевышний, меня нетерпеливому
Выведи на путь терпения.)

Тоскует ли человек о родной земле, о дорогих сердцу родственниках, о возлюбленной; ниспослал ли Всевышний тяжкое испытание горестями и бедами – необходимо стойко и мужественно терпеть все невзгоды.

Бәнем эчемдәге нарым,
Дөньяга чыгарсам барын,
Эретеп су итәр карын, –
Сабырлык бирсәнә, Алла!

Достойна внимания мощная гипербола: огонь, пылающий в душе лирического героя, способен растопить все снега мира.

У Кандалый имеется множество таких образов, художественных средств. «Кандалый под ударами судьбы свои печальные мысли складывает в привычную форму мунаджатов, пытаясь избавиться от мучившей его тоски» (Садекова, с.244).

Мунаджаты Кандалый напоминают образцы народной поэзии:

Сабыр итим, сабыр итим,
Сабыр итми, нихәл итим.
(Садекова, с. 243).

И в народных мунаджатах, и в стихах Кандалый в терпении человек уповает на Всевышнего, потому что тәкъдир – всякая судьба – предначертана Им. Во всей любовной лирике Кандалый красной нитью проходит мысль о том, что Аллах этим чувством одаривает или, наоборот, наказывает людей.

Мәхәббәтне сәңа салды Ходаем,
Моны язмый ни халь түзәем
(Кандалый, с. 197)

Лирические произведения Кандалый проникнуты образностью и отличаются выразительностью. Кроме обычных словесных сравнений, здесь множество религиозно-мифологических образов. К примеру, поэт сравнивает возлюбленную с неземными существами: фәрештә (ангелами), хур кызлары (гурии в раю). Чувства лирического героя так же сильны и пламенны, как любовь коранических персонажей Йусуфа и Зулейхи, столь популярных среди татарского народа. Вполне укладывается в рамки шариата то, что с мольбой о возлюбленной поэт обращается к Аллаху.

Сәнең өчен күп егъладым җомгада,
Сәне сорап зарый кыйлам Ходага.

(По тебе много слез лил я в пятницу
Тебя прошу у Всевышнего, молю.)

Пятница – священный и праздничный день мусульман. Этот день правоверные должны проводить в молитвах җәмигъ (общественных), в зикр (упоминание Аллаха), подаянии милостыни и др. богоугодных делах.

В другом стихотворении герой Кандалый, обращаясь к девушке, восклицает:

Салауат ул Мөхәммәд Мостафага,
Каушдырсын Алла бәне (сән) тутайга.
(Кандалый, с. 240)

Салават – популярная у мусульман молитва, упоминание пророка Мухаммеда Мустафы (салляллаху аляйхи ва саллям). Считается, что салават необходимо читать прежде других молитв, поскольку он способствует их принятию Всевышним.

Раз лирический герой апеллирует к «высшей инстанции», выразителю абсолютной истины – Всевышнему – с тем, чтобы за влюбленного поручился сам пророк, то остается только изумляться, как возвышенно изображено чувство любви.

Нередко у Кандалый встречается мотив фиракъ (разлуки). Разлука не только с возлюбленной, но и с родным сыном. Любимого сына хазрета забрали на службу в царскую армию сроком на 25 лет. Для Кандалый это было ударом и трагедией. Поэт

тяжело переносит утрату, и его душевные переживания нашли отражение в стихах:

Чүн фиракъ кыйлды ходаем бу заман,
Бу фиракълыкдин юк җиһанда яман.
(Кандалый, с. 121)

или

Бәнем ошбу аһым-зарым
Җиде кат күкләргә ашды
Фиракъ уты бәни басды, –
Иляһи, бир сабырлыкны.
(Кандалый, с. 79)

(Эти мои стенания
Вознеслись на семь небес.
Пламя разлуки меня сжигает.
Аллах, дай терпения.)
(пер. Садековой)

Сила, глубина переживаний из-за разлуки с сыном во втором примере сравниваются с огнем. В библейско-коранических преданиях описан и огонь геены. Однако он предстоит грешникам в загробной жизни, а лирического героя огонь разлуки опаляет уже в жизни реальной. Тяжкие стенания человека доносятся до седьмого неба. «Седьмое небо» – выражение, активно используемое в фольклоре многих народов, также имеет библейско-кораническое происхождение. «Он – тот, который сотворил вам все, что на земле, потом обратился к небу и устроил его из семи небес» (Бакара, 29).

Как видим, в языке и стиле, системе образов и др. художественных средствах произведений Кандалый нашли отражение традиции религиозного фольклора. Коранические образы не случайное, не стихийное явление, а закономерный процесс в творчестве поэта.

В произведениях Г. Кандалый в числе прочих атрибутов религиозного фольклора часто встречаются и другие художественно-поэтические средства, например религиозный миф, ритуал дога (молитва) Творцу, обряды никах (бракосочетание – воображаемое или действительное – с любимой), талак (развод). В синкретическом единстве с авторской фантазией они дают новое наполнение традиционным, архаичным сюжетам.

К таковым можно отнести *җен* (джиннов), Иблиса, Газазила (Азазель) и др.

Исследователи трактовали строфы из стихотворения «Бу илләрдә торып калсам»:

Тарсынма бер дә, китәрмен.
Җен, Иблистән дә битәрмен,
Үз белгәнемне итәрмен, –
Ки әгъля-гъәрше ашкындым!
(Кандалый, с. 75)

(Не стесню тебя, уйду,
Джинна, Иблиса превзойду.
Своего я добьюсь,
К дереву Гарш вознесусь!)
(пер. Садековой)

как бунтарские и даже атеистические (Кандалый, 1960, с. 13). Такое отношение к творчеству талантливого поэта стало результатом не только советской антирелигиозной пропаганды, но и буквального понимания, механического восприятия текста. Потомственный служитель мусульманского культа, последователь идей суфизма богохульствовать и отрицать Всевышнего не мог в принципе. Однако он был реформатором стихосложения своего времени, человеком незаурядным, образно мыслящим поэтом. С традиционными формами, сюжетами и образами обращался достаточно вольно. Очевидно, приведенные выше возгласы неординарного Кандалый, изобилующие непременными атрибутами религиозно-мифологического фольклора, следует рассматривать как литературно-художественный прием, призванный усилить эмоциональную яркость стиха.

Богатство мыслей, стиля Корана, изречения мыслителей мусульманского Востока, предания народа – все наложило отпечаток на поэтические творения Г. Кандалый. Известные персонажи, образы, сюжеты у поэта зачастую несут не только основную мысль первоисточника, но и обогащаются дополнительными смыслами.

Хитрые, коварные женщины, современницы поэта, к примеру, сравнены с женами пророков Нуха (Ной) и Лута (Лот), которые не могли считаться образцами порядочности (Кандалый, с. 103). Точно так же, как в древние времена проклинали вероотступников, лирический герой проклинает неподступных,

бессердечных, жестоких красавиц. Гордыня простой деревенской девушки сравнивается с гордыней оступившегося ангела Азазила. В рузый кыямәт – кыямәт көне (судный день) – поджидает несчастье грешников. У Кандалый же талибу (студенту), который закрывал глаза на пороки ближних, не учел их печального опыта, уготована такая участь.

В философских стихотворениях, сочиненных в зрелом возрасте, присутствует символ *әҗәл* (смерть) – удел всех людей. И все-таки человек, ошибаясь, страдая, стремится жить с надеждой на лучшее. Поэт изображает свою родную сторону чудесным (по восточным преданиям – райским) садом:

Йәшел чирәм бу җәй чагы –
Безем илнең Ирәм багы.
(Кандалый, с. 80)

Образность, сочность метафоры, философская глубина ставит это стихотворение в ряд лучших произведений татарской поэзии.

По-народному эмоционально, трогательно четверостишие, которое содержит строфы:

Балакаем, сәңа һич юк бүләгем,
Кауышмакда хәер-дога теләгем.
(Кандалый, с. 93)

(Дитя мое, нет подарка для тебя,
Лишь о встрече с тобой молюсь я.
(пер. Садековой)

Мотив стихотворения является традиционным лейтмотивом многих мунаджатов. Кроме обычного, житейского понимания бескорыстной родительской любви здесь можно усмотреть и глубинный, сакральный смысл: историю пророков Ягъкуба и его сына Йусуфа; Ибрахима и Исмаила. Хәер-дога (добрая молитва) родителей, доброе родительское напутствие – понятие нематериальное, абстрактное, но традиционно у татар-мусульман оно превыше всех материальных благ. Для мусульман очень важно, чтобы родители поручились за своих детей перед Всевышним, молились за них.

Габдельджаббар Кандалый своей поэзией, следуя многовековым традициям и одновременно творчески видоизменяя их,

достиг больших высот в искусстве слова, внес большой вклад в татарскую литературу. Если стремление к знаниям, просвещенности ознаменовало переход литературы к эпохе просвещения, то обращение Кандалый к устной и письменной традициям, их обновление способствовали становлению реалистического метода творчества.

ЛИТЕРАТУРА

1. Исәнбәт Н. Отканга мәкаль, тапкырга табышмак. – Яр-Чаллы: Идел-йорт, 2000. – 92 б.
2. Кандалый Габделҗаббар. Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 558 б.
3. Кандалый Г. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 188 б.
4. Коран / пер. и коммент. И.Ю. Крачковского. – М.: Физкультура и спорт, 1990. – 728 с.
5. Садекова А.Х. Идеология ислама и татарское народное творчество. – Казань: Иман, 2000. – 261 с.
6. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 2 т.

## Г. КАНДАЛЫЙ ИҖАТЫНДА ТРАДИЦИЯ ҺӘМ ЯҢАЧАЛЫК

*Ә.М. Закирҗанов*

Шагыйрь юлы – кометалар юлы,
Ялтырый да көмеш юл ярып,
Йөз ел буе әллә кайда йөри
Галактикаларда югалып.

Шагыйрьләр дә форсат көтеп ята
Җыры, эзе калган бу җиргә
Онытылып беткәч тагын кайта,
Бер ялтырап, балкып йөрергә.

Татар халык шагыйре Гамил Афзалның «Габделҗаббар Кандалыйга» дигән шигыреннән алынган бу юллар татар әдәбияты тарихында җуелмас эз калдырган XIX йөз әдибе мирасының туган халкына кайту юлы никадәр катлаулы булуын ачык чагылдыра. Вафатыннан соң 100 ел үткәч кенә беренче шигъри җыентыгы дөнья күрсә дә, Г. Кандалый иҗаты күпгасырлык татар әдәбияты тарихында бер йолдыз булып балкый. Урта гасыр

әдәбиятыннан Яңа заман әдәбиятына күчү дәверен әлеге әдип иҗатыннан башка күз алдына китереп булмый. Аның шигырь-поэмалары, бер яктан, бай традицияләргә нигезләнсә, икенче яктан, Коръән тәгълиматына таянган хәлдә, яңачалыкка омтылышы, дөньяви-ренессанс яңгырашы белән үз чорында кабул ителгән карашларны күпкә узып китә. Җ. Вәлиди язганча, «Без тарихе әдәбиятымызда чын татарча нәзымнар язучыны эзләгәндә, иң элек, Габделҗаббар әл-Кандалыйга очрыймыз» [1: 93]. Шикләнмичә әйтергә мөмкин: үз чоры татар укучысының дөньяга каршын, үз-үзен танып белүен, дини-әхлакый сыйфатларын үстерүгә зур өлеш керткән әдип мирасы, вакыт сынавын уңышлы үтеп, бүген дә гаять заманча яңгырый, яңадан-яңа шигъ-рият сөючеләрнең күңелен яулый. Моңа ирешүдә Г. Кандалый иҗатын, тормыш юлын өйрәнүче белгечләрнең роле бик зур. Үз вакытында шагыйрь иҗатына С. Күкләшев, Х. Фәизханов, К. Насыйри кебек мәгърифәтчеләр иҗат иткән булса, XX гасыр дәвамында аның бай мирасы Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, К. Иртуган (Рахманкулов), И.Бәхтиев, Г. Сәгъди, Б. Яфаров, Х. Госман, Җ. Алмаз, М. Гайнуллин, М. Госманов, Р. Әхмәтов, А. Юсупова, С. Поварисов, Х. Миңнегулов, Ш. Садретдинов, Т. Галиуллин, Ә. Сибгатуллина, Р. Сафиуллина һ.б. тарафыннан шактый тулы өйрәнелә. Әдипнең шигырь-поэмаларын туплап, фәнни эшкәртеп киң катлау укучыларга китереп җиткерүдә М. Госмановның аеруча зур хезмәтен билгеләп үтү кирәк. Галим тарафыннан төзелеп, текст һәм искәрмәләрне әзерләп, кереш сүзе белән басылып чыккан «Шигырьләр һәм поэмалар» (1988) Г. Кандалыйның иң тулы җыентыгы булып тора.

Габделҗаббар Габделмәҗит улы 1797 елда Самар губернасы Иске Кандал авылында (хәзер Ульян өлкәсе Иске Майна районы Иртуган авылы) рухани гаиләсендә дөньяга килә. Ерак бабасының хәзерге Чүпрәле районы Каракитә авылыннан булып, әлеге нәселнең укымышлы булуы, әтисенең «Габделмәҗит Болгари» исеме белән китаплар язуы билгеле [2: 8]. Башлангыч белем күнекмәләрен әтисеннән алганнан соң, Габделҗаббарга Мораса, Кизләү, Күркәле, Кышкар, Шонталы, Оры мәдрәсәләрендә укырга туры килә. Истәлекләрдән күренгәнчә, яшьтән туры сүзле, хөр фикерле булып үскән егет бер мәдрәсәне үзе ташлап китсә, кайберсеннән аны китәргә мәҗбүр иткәннәр. Төрле мәдрәсәләрдә уку, татарлар яшәгән төбәкләрне иңләп үтү (Самара губернасы, Чистай өязе, Бөгелмә өязе, Казан арты һ.б.) Г. Кан-

далый өчен тормыш мәктәбе була. Шәкертлек елларында гарәп-фарсы телләрен үзләштерә, дини әдәбиятны, ярым дини характердагы хезмәтләрне, борынгы әүлияләр турындагы риваять-легендаларны өйрәнә. Бу чорда ул Шәрык һәм Урта гасыр татар әдәбияты үрнәкләре белән таныша, алардан әдәби осталыкка өйрәнә, тәҗрибә туплый. Г. Кандалый шул төбәктә яшәүче халыклардан рус, чуваш, мордва телләрен дә белгән. Бу да аның актив, кызыксынучан, тормыш яратучы кеше булуын күрсәтә. Мәдрәсәдә укуын тәмамлап, Диния нәзарәтеннән указ алганнан соң, туган авылында имам вазифаларын башкара.

Г. Кандалыйның тормышы шактый каршылыклы, борчулы була. Бу, беренче чиратта, аның шәхесе үзенчәлекләре белән аңлатыла. «Хисле һәм көчле темпераментлы, дөньяга тәнкыйть күзе белән карый алу зирәклегенә, фикерләрен турыдан ярып әйтә алу сәләтенә ия, үз-үзенә нык ышанган көчле шәхес» [2: 13] ул мохиттә теләкләрен тулысынча тормышка ашыра алмаган. Көче, энергиясе ташкын булып мәхәббәт хисендә урын алган һәм шигырь булып кәгазьгә төшкән. Үз шәхесенә хөрмәт белән караган имам табигый хис-кичерешләрен әйләнә-тирәдәгеләрдән бик яшереп тормаган. Аның ярату турындагы караш-фикерләре, сөю кебек «гөнаһлы» хисләрне ачыктан-ачык әйтүе, мәхәббәт хатларында сурәтләве ул чорның әхлакый кануннары белән ярашмый. Бу исә күпләрне шагыйрьгә каршы куя. Шуның өстенә улы Садретдинне 25 елга солдат хезмәтенә алалар. Г. Кандалый моны бик авыр кичерә. Бу елларда борчу-хәсрәт, ялгызлык, аерылу мотивлары урын алган шигырьләре язылa.

Г. Кандалый иҗаты XIX йөз әдәбиятында гаять мөһим урын алып тора. Ул, беренче чиратта, урта гасыр традицияләренә таянган хәлдә, яңа заман әдәбиятына күчештә шагыйрь мирасының күпер ролен үтәвендә күренә. Г. Кандалый, шул чор белем-тәрбиясен алган кеше буларак, билгеле инде, үзеннән алдарак әдәби иҗатта мәйдан тоткан Мәүла Колый, Г. Утыз Имәни кебек шагыйрьләр иҗатына хас традицияләрне дәвам итә. Беренче әсәрләренең шәкертлек елларында язылуы бәхәс уятмый. Әдипнең «Рисаләи-л-иршад» («Тугры юлга күндерүче китап») һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмалары – суфыйчыл, дини-әхлакый эчтәлектәге дидактик әсәрләр. Ул фани дөньяда яшәү мәгънәсенең мәңгелеккә баруга әзерләнү икәнлеген, моның өчен наданлык-җәһаләттән качып, гыйлемлеккә омтылу кирәклеген аңлата. Бары тик дини гыйлем, Алла тәгълиматын үзләштерү

генә кешегә үзен аңларга, Аллага мөнәсәбәтен дөрес билгеләргә ярдәм итә дип саный ул. Беренче поэмада «тугры юлга күндерүнең» асылын аңлатуны, ике дөнья күренешләре белән таныштыруны алга куйса, икенче поэмада борынгының атаклы аскеты Бәлех солтаны Ибраһим Әдһәмнең хакыйкать эзләү юлында күргәннәре тасвирлана. Әлеге поэмалар формасы, тел-стиле, идея юнәлеше ягыннан урта гасыр әдәбияты традицияләрен дәвам итә. Шуның белән бергә, аларда без әдип талантын күрсәткән уңышлы образлар, сәнгати алымнар белән дә очрашабыз. Гомумән, «яшь Кандалый поэмалары, әдәби тәҗрибәсез авторның өйрәнчек әсәрләре буларак, бер аерым иҗатның төрле чорларын билгеләү өчен генә түгел, бәлки бөтен татар әдәбияты тарихындагы охравилыктан дөньявилыкка күчә башлау кебек мөһим этапларны өйрәнү, аңлау өчен дә, зарур һәм кыйммәтле истәлекләр» [2: 17].

Әдип яшәгән чор иҗтимагый фикердә, шул нисбәттән әдәби-мәдәни үсештә уяну, тәрәккыяткә омтылу белән характерлана. Башка чордашлары кебек үк, Г. Кандалый да моңа ирешү өчен, беренче чиратта, халыкта әдәп-әхлак сыйфатлары, иман тәрбияләргә кирәк дип саный, шуңа да башлангыч чор әсәрләрендә үк наданлык, җәһаләт, комсызлык һ.б. күренешләрне кискен кире кагып, укучысын намуслы яшәешкә, гыйлем туплауга, изге гамәлләр кылуга чакыра. Әдипнең юмор-сатира белән язган «Бу илләрдә торып калсам...», «Тотынышып кулың кулга...» әсәрләре әлеге максатка хезмәт итә. Шагыйрь надан хәлфәләрне, әхлаксыз муллаларны көлү объекты итеп ала һәм үзенең андыйлар белән килешмәячәген ачыктан-ачык әйтә. Г. Кандалыйның Ору мәдрәсәсендә укыганда язылган «Тотынышып кулың кулга...» шигыре әдипнең тәҗрибәсе арта баруын, көлү алымнарын тирәнрәк үзләштерүен күрсәтә. Әлеге әсәр тормыштагы ямьсез күренешләрне, артталык-искелекне, әхлаксызлыкны фаш итеп язылган шигырьләрдән тормышчанлыгы, мулла образының реалистик вакыйга-күренешләрдә бирелүе белән аерылып тора. Шагыйрьнең үзе яшәгән чорны, әйләнә-тирәне, көнкүрешне тулырак аңларга ярдәм иткән, үткен ирония, җиңелчә юмор, шаяру белән язылган шигырьләре тулы бер катлам тәшкил итә. Мондый әсәрләрендә аның жор телле, үткен фикерле булуы, гадәти вакыйга-хәлдән дә юмор ясый алуы күренә. Г. Кандалыйның юмор-сатира белән язылган әсәрләрендә үгет-нәсихәт белән кешене тәрбияләү өстенлек итә. Дидактикага нигезләнгәнгә, алар-

да эзлеклелек җитми. Р.Ганиева билгеләп үткәнчә, тулы канлы әдәби сатира үз эченә өч этапны ала: берсе – һәртөр начарлыкны кире кагу; икенчесе – искелек-артталыкны фаш итү; өченчесе – начарлык белән көрәшү кирәклеген аңлатып, алга юл күрсәтү һәм шуның белән матурлыкны раслау [3: 10–14]. Г. Кандалый иҗатында без, нигездә, баштагы ике функция белән очрашабыз. Әдиптә әлегә социаль һәм публицистик үткенлек, кеше акылына, әдәбият көченә ышану җитеп бетми. әмма аның юмор-сатира өлкәсендәге шигъри табышлары үзеннән соң сүз сәнгатенә килгән әдипләргә җирлек булып тора. Аерым алганда, Г. Тукай, Ш. Бабич кебек шагыйрьләр Г. Кандалыйдан килгән традицияләрне үстереп, сатираны яңа баскычка күтәрәләр. Гомумән, Г. Кандалыйның юмор һәм сатира белән язылган әсәрләре кешегә ихласлык белән, аны аңлау һәм ярдәм итү теләге белән язылганнар. Әдип бу төр әсәрләрендә дә гуманистик традицияләргә турылыклы булып кала.

Шагыйрь иҗатында гыйлем-мәгърифәт мәсьәләләре шактый урын алып тора. Шәкертлек елларында ук язылган шигырьләрендә гыйлемлекне әдәп-әхлакның бер чагылышы, сыйфаты итеп карый, аны кыйммәтле ташка тиңли. Белемлелек җәүһәр таш нуры кебек кешенең эш-гамәленә, яшәешенә уңай йогынты ясый, еш кына аның асылын билгели. Г. Кандалый фикеренчә, гыйлем ике дөньяда да кирәк. Үз нуры белән синең җаныңны яктырткан мәгърифәт кебек, аның иясе дә фанида һәм бакыйда бәхеткә ирешәчәк, эше һәм исеме калачак:

Гыйлем сахибе (иясе) һичбер дә
Черемәс – үлсә дә – гүрдә.
(«Гыйлемлек нурани җәүһәр»)

Шагыйрь үзенең укучысын әхлаклы яшәешкә өнди, тормышта очрый торган әдәпсезлек, имансызлык күренешләреннән гыйбрәт алырга чакыра. Коръән кушканча яшәмәүчеләрне «мәхәббәтсез кешеләр» дип атый, һәм үзеңнең кол булып Алла каршына барасыңны, кыямәт көненә җитәсеңне онытмаска үгет-нәсихәт бирә:

Кил, и талиб (шәкерт), гыйбрәт илән күзең ач,
Мәхәббәтсез кешедән бик ерак кач!
(«Кил, и талиб...»)

Иҗатын Урта гасыр язма әдәбияты традицияләрен дәвам итеп, үгет-нәсихәт белән сугарылган суфыйчыл эчтәлекле

шигырь-поэмалар белән башлаган Г. Кандалый әкренләп тормыш чынбарлыгына, дөньяви күренешләргә, гадәти хис-кичерешләргә йөз белән борыла. Әдәби мирасының иң бай тармагы булып мәхәббәт шигырьләре һәм поэмалары тора. Шагыйрь әсәрләрендә төп сурәтләү объекты итеп гади, гадәти җир кызын ала һәм шуның белән үк татар шигъриятенә яңалык алып килә. Ул күзе төшкән кызның гаҗәеп матур образын тудыра, гүзәл портретын күз алдына бастыра:

Тулган айга охшар сәнең йөзләрең бар,
Бал-шикәрдин татлы сәнең сүзләрең бар.
Зөһрә йолдыз кеби сәнең күзләрең бар,–
Кыяфәтең фәрештәгә биңзәр имди.
(«Нәзъме Йосыф...»)

Өй-хуҗалык эшендә, болында печән чабып, җиләк җыеп, физик хезмәттә чыныгып һәм табигатьнең шифалы җил-һавасында үскән кыз әдипне матурлыгы белән генә түгел, акылы-зирәклеге, әхлагы-гыйлеме белән дә сокландыра. Г. Кандалый шәхес иреген, кешенең бәхеткә, мәхәббәткә хокукын таный һәм бу чор әдәбиятында беренче булып, ярату хисен табигый тойгы буларак сурәтли. Гашыйклыкны ул Алла тәкъдире дип саный («Хакъ тәгалә гашыйк кыйлды бәне сәңа...»), шуңа да әлеге хис лирик геройның бөтен җанын-тәнен биләп алган. Мәхәббәт утында янучы гыйшыкның хәлен бирүдә автор сурәт чараларының бөтен байлыгыннан файдалана:

Диванага әйләнәдер газиз башлар,
Күземдин агадыр канлы йәшләр.
(«Нәзъме Йосыф…»)

Гыйшык уты янар, һич сүрелмидер,
Дөнья-галәм күзләргә һич күренмидер.
(«Нисъф-ел-мөякъәт»)

Г. Кандалый, гашыйклык хәлен тасвирлау өчен, Урта гасыр язма әдәбияты традицияләренә дә мөрәҗәгать итә. Аның лирик герое сөйгәненә үрнәк, гыйбрәт итеп атаклы мәхәббәт каһарманнары булган Йосыф һәм Зөләйха, Сәйфелмөлек һәм Бәдигыльҗәмал, Мәҗнүн һәм Ләйлә, Фәрхад һәм Ширин исемнәрен телгә ала, үзен шуларга тиңли. Сөю хисе бөтен җанын-тәнен биләп алган лирик герой күңеленә мәгъшукасының мәхәббәте генә дәва була ала:

Бу язмакдин күңелнең туясы юк,
Сәне алмай күңелнең тынасы юк.
(«Мәхәббәтне сәңа салды ходаем»)

Г. Кандалый хатын-кыз шәхесенә хөрмәт белән карый, мәхәббәт, гаилә кору мәсьәләсендә аның тигез хокуклы булуын, активлыгын яклый, шуның белән ул әдәбиятта, иҗтимагый фикердә шәхес концепциясен аңлауда бер адым алга атлый. Шагыйрь фикеренчә, мәхәббәт, бәхет төшенчәләре байлык белән билгеләнми («Надан ир малына кызма, алар сари (таба) кулың сузма...»). Шуларга бәйле хатын-кыз язмышын социаль проблема дәрәҗәсенә күтәрә һәм, алдагы чорларда әдәбиятта үзәккә куелачак сорауларның берсе буларак, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

Кандалыйның мәхәббәт лирикасында поэмалар үзгә урын алып тора. Аларда, бер яктан, лиро-эпик жанрның нигез принципларын билгеләсә, икенче яктан, зур булмаган вакыйгалылык, чынбарлык күренеше аша сөю хисенә мәдхия укый, лирик герой күңелендәге хис-кичерешләрнең серлелеген, байлыгын, илаһилыгын тасвирлауның гаҗәеп матур үрнәкләрен бирә. «Шәфгый» поэмасында лирик геройның мәгъшукасына булган сөю хисен белдерү үзәктә тора. Ул кайларда гына булмаган («матурлык базарларын гиздем»), әмма Шәфгыйдән дә чибәрне, күңеленә якынны очратмаган. Лирик герой ялварып күзе төшкән кызга Алладан сәламәтлек сорый. Күңелендәге гашыйклык утына түзә алмыйча, хис-кичерешләрен хикәят рәвешендә кызга юллый. Ярату хисе шундый көчле, ул күңеленә тынычлык таба алмый, үзен атаклы мәхәббәт каһарманы Мәҗнүнгә тиңли, ә кызны төрки шагыйрь Мәҗлесинең «Сәйфелмөлек» кыйссасындагы Бәдигыльҗәмал белән чагыштыра. Кабул булмаган мәхәббәт газабыннан саргаеп, кибеп бетә, җаны сыкрана: кичтән йокы алмый, ә һәр төнне исә төш күрә. Ул Шәфгыйне Ирәм багында, ягъни җир өсте җәннәте буларак сурәтләнеп риваять-легендаларга кергән Ирәм бакчасында сайраучы кошка тиңли һәм төшендә аны эзләп бара. Әлеге образлы сурәттә дә Г. Кандалыйга Урта гасыр романтикасы йогынтысын күрәбез.

Әдипнең «Фәрхи» поэмасында матурлыкка, гашыйклыкка бәйле хис-кичерешләр, сурәтләр өстенлек итә. Борнай авылында яшәүче Фәрхи исемле кызның матурлыгын, инсафлыгын ишетеп, лирик герой күңелендә хисләр кузгала. Ниһаять, аны күрүгә

ирешә һәм гашыйк була. Сөю хисенә бәйле мәгъшукасының матурлыгын халык җырлары традициясендә тасвирлый:

Тулан (тулган) айдик йөзең матур икәндер,
Ике битең кояшдик нур икәндер.
Кашың кара сызылган күз өстендә,
Яңа айдик һавада – күк йөзендә.

Кызны ул таң йолдызы белән чагыштыра. Матурлыгы һәрдаим күз алдыннан китми, аңа табына, хәтта мәчеттәге михрабка, изге урынга тиңли. Мәхәббәт уты лирик герой җанын-тәнен биләп ала. Ул үзенә урын таба алмый, әлеге хистән акылын югалтыр хәлгә килә, күз яшьләрен агызып елый. Автор гыйшыклык хәлен аңлатуның яңадан-яңа алымнарын, сурәт-төсмерләрен эзли. Ярату хисенең дәрәҗәсен төрлечә арттыра. Ялкынлы сөю хисен белдерүнең Урта гасыр Шәрык әдәбиятыннан ук килә торган традицион чараларын тагы да баету, төрләндерү үрнәкләреннән файдалана:

Аллаһ әкбар дип әгәр каксам колак,
Сурәтең күңлемә уладыр кунак!

Поэманың соңгы бүлекләрендә тон үзгәрә, лирик геройның Фәрхигә булган ялвару-үтенүләре ачулану белән аралашып бара. Күп хатлар язуына бәйле аның мәхәббәте чит-ятларга да билгеле була. Кызның үзен кире кагуы сәбәпләре турында уйлана, аны гамьсезлектә гаепли, ата кешенең ризасызлыгын сәбәп итүе өчен ачулана. Ә ялыну-ялварулары һаман нәтиҗәсез. Шуңа ул кызны артык горур булуда, кеше хәлен аңламауда гаепли. Лирик геройның хис-кичерешләр ташкыны арттыру алымы аша бирелә:

Бу инәлгәнләрем таш да белерде,
Урыс кызы динен ташлап килерде.

«Мәгъшукнамә» поэмасында имам булып хезмәт итүче лирик геройга ярату килүе сурәтләнә. Шуңа бәйле ул мәхәббәтнең ни икәнен аңларга омтыла. Әлеге табигый хис шатлык-куаныч белән бергә кайгы-хәсрәт тә алып килергә мөмкин икән. Мәгъшука күңеленә юл таба алмаганда соңгысы өстенлек итә. Сөю дигән хис кешене күкләргә күтәрә, хыял дөньясында йөретә, вакыты белән телдән һәм эштән-аштан калдыра, гашыйкны диванага әверелдерә, «дөнья хәфасына» китерә. Аның хәле тоткын хәленә тиң, җавапсыз мәхәббәт, сөйгәнең белән кавыша алмау

үлем газапларына китерә («Бу мәгъшукның ахыры бер үлемдин...»). Максатына ирешүгә нигез итеп, лирик герой укымышлы мелла белән надан мужик каршылыгын ала. Наданлыкны кешедәге иң начар сыйфатларның берсе итеп карый һәм әдәпсезлек-әхлаксызлык белән тиңли, шуңа бәйле рәвештә кызларны кат-кат кисәтә, акылга килергә өнди, туры киңәшен бирә. Кызны сурәтләгәндә автор аерым детальләр, күренешләр белән эш итә, урыны белән натуралистик төсмерләр дә килеп керә. Әмма шагыйрь сурәтләрендә табигыйлек, гадәтилек өстенлек итә һәм ул чынбарлыкны үзенең күптөрлелегендә күз алдына бастыра.

«Сәхипҗамал» поэмасы билгеле бер дәрәҗәдә Г. Кандалый иҗатына ачкыч булып хезмәт итә, чөнки анда шагыйрьнең сәнгати фикерләү үзенчәлекләре, дөньяга карашы, заман чынбарлыгына мөнәсәбәте шактый тулы, нигезле чагылыш таба. Поэманың эчтәлеген, беренче чиратта, лирик геройның Сәхипҗамал исемле кызга мәхәббәт хисе алып тора. Яратуны автор кешегә генә хас булган табигый, әмма гаҗәеп көчле тойгы итеп тасвирлый. Мәхәббәт лирик герой өчен яшәү мәгънәсе, бәхет-шатлык чыганагы. Сөю хисе ул мәңгелек, кешене бөтен гомере буе озата бара. Лирик геройның мәхәббәт тарихы да гыйбрәт булып халык телендә калачагына автор шикләнми. Әнә шундый тирән хис-кичерешләрдә яшәгән лирик герой кызны уйлап ашау-эчүдән кала, еш кына «хыял дәрьясына» бата, әмма сөйгәне күңеленә юл таба алмый. Сәхипҗамал аның мәхәббәтенә шуның белән үк җавап бирми. Сөю хисе сагыш, сагыну булып ташып чыга:

> Сагышың берлә бер елым
> Бәңа тойла ки бең елдай.

Үзләрен ул халык иҗатында аерылуны, кайгы-хәсрәткә батуны аңлаткан Сак белән Сокка тиңли һәм алар язмышы белән мәгъшукасын кисәтә. Хатлар да, ялыну-ялварулар да ярдәм итми. Үзенә бармыйча, крестьян егетенә кияүгә чыкса, кызны ни көтә соң? Крестьян тормышы көн-төн хезмәттә үтә, шуңа күрә иман да, намаз да онытылып, күзгә күренми. Лирик геройның сөйгәнен дә, билгеле, түбәнлек-хурлык, ачлык-ялангачлык көтә. Тузанга-балчыкка батып йөргән ир белән җаныңа тынычлык бетәр, хәтта акылыңны җуяр хәлгә килерсең, дип кисәтә ул кызны. Автор чорның реаль картиналарын күз алдына бастыра. Сөйгәненә гыйбрәт өчен тасвирлаган вакыйгаларда социаль тигезсезлек ачыла, крестьянның тормышы авыр хезмәттә, мохтаҗлыкта үтә.

Рухани катлавы вәкиле булган лирик герой аңа кимсетеп карый, шактый тупас, ямьсез сүзләр белән төрлечә хурлый. Алдагы шигырьләреннән дә күренгәнчә, Г. Кандалый физик хезмәткә, кара хезмәткә каршылыклы мөнәсәбәттә. Бу, бер яктан, алган тәрбиясе, яшәү рәвеше белән аңлатылса, икенче яктан, күрәсең, реаль тормышта «мажик» катламының әдәпсез, имансыз сыйфатлары белән еш очрашып тору да йогынты ясаган. Шуны да истән чыгармаска кирәк: поэмада кызны үгетләү, кисәтү өчен меллаларны күпертеп сурәтләсә, киресенчә, крестьянны түбәнсетүдә кара буяуларны җәлләми. Г. Кандалый наданлык-гыйлемлек каршылыгын шактый җентекле ача, әмма бу мәсьәләләрдә әдип карашларының чикләнгәнлеге дә ачык күренә. Ул авыр тормыш сәбәпләрен ачуга күтәрелә алмый. Шулай ук «надан мажик»ны әдәпле, иманлы, укымышлы итү юллары турында да уйланмый. Болар барысы ул чор иҗтимагый фикеренең каршылыклы үсешен, катлаулы, бәхәсле юллар аша үтүен аңлата.

Г. Кандалыйның дөньяга карашын, шәхси позициясен аңларга поэмада хатын-кыз язмышы мәсьәләсе куелышы да ярдәм итә. Бу сорау үзмаксат итеп түгел, бәлки лирик геройның мәгъшукасын үгетләве, кисәтүе буларак куела. Кыз аның үгетнәсихәтләрен тыңламый, теләк-сорауларын кире кага. Кайгыхәсрәтеннән акылын җуяр дәрәҗәгә җиткән лирик герой сөйгәнен каргый, начар теләкләр тели, сүзен тыңламыйча крестьянга чыкса, гомере буе үкенечкә дучар булачагын искәртә. Болар да файда итмәгәч, гыйбрәт өчен Борнай авылы кызының язмышын сурәтли. Кайчандыр ул аның сүзен тыңламыйча мужикка барган һәм тормышы чын тәмугка әйләнгән. Шагыйрь тормыш чынбарлыгын объектив сурәтләүгә ирешә. Ул хатын-кызга хөрмәт белән карый, аның мәхәббәт, гаилә кору мәсьәләсендә ирләр белән тигез хокуклы булуын, бәхеткә хокукын таный, ә инде фаҗигале язмышларны тасвирлап, моның гайре табигый булуын күрсәтә.

Г. Кандалый иҗатында кайгы-хәсрәт мотивы шактый тотрыклы төсмер алып тора. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасында ук мәгъшукасы тарафыннан кире кагылган лирик геройның хискичерешләре олы бер фаҗига, җан борчуы, авыр хәл буларак сурәтләнә. Күпсанлы мисалларда мәхәббәт утында янучы лирик герой үзен бәхетсез саный, күзләреннән канлы яшьләр агызып, тилмереп сөйгәнен юксына. Кавыша алмау кайгысыннан ул үлем хәлендә яши:

Күземдин канлы йәш ага –
Хәсрәтеңдин, әйа җаным!
("Мөнәҗәтне яза-яза...")

Г. Кандалыйның соңрак язган шигырьләрендә кайгы-хәсрәт мотивы фәлсәфи төсмер алып, яшәү мәгънәсе, үлем, бәхет һәм бәхетсезлек турында уйланулар буларак тасвирлана. Шагыйрьнең тынгысыз, ашкынулы йөрәге яшәп килгән тәртипләр, җәмгыятьтә кабул ителгән йолалар белән килешми. Ул үзенең «гөнаһлы» әйберләр турында язганын аңлый, ләкин күңел кичерешләрен, тотрыксыз хисләрен тыя алмый. Алар, шагыйрьнең акылына буйсынмыйча, шигырь булып кәгазьгә төшә. Г. Кандалый шәхси тормышында бәхетле була алмаган. Берничә хатынга өйләнеп караса да, ул, күрәсең, җанына тынычлык тапмый. Аның гомерлек үкенече, кавыша алмаган мәхәббәте булып Сәхипҗамал кала. Хәер, үзенең шәхесен гаять югары куйган әдипне ул кыз да бәхетле итә алмас иде. Чорын узып яшәгән Г. Кандалый күңелендә үз-үзеннән, әйләнә-тирәсеннән канәгатьсезлек арта бара:

Бәнем эчемдәге нарым (утым, ялкыным),
Дөньяга чыгарсам барын.
Эретеп су итәр карын, –
Сабырлык бирсәнә, Алла!
(«Бәнем эчемдәге нарым...»)

Улы Садретдинне 25 елга солдат хезмәтенә алуны ата бик авыр кичерә. Тынгысыз гомер кичергән йөрәге аерылу сагышыннан өзгәләнә. Бала хәсрәте шундый көчле ки, шагыйрь лирик геройның хәлен, күңел кичерешләрен «янган йөрәк» эпитеты аша бирә:

Бу бала хәсрәте түкте
Кара сачләрем башымдин.
Инешләр ташды йәшемдин, –
Җитешмәсме әҗәлләргә?!
(«Бу бала хәсрәте түкде...»)

Гаять киеренке хис-кичерешләр «учагында» янган герой җанына тынычлык эзли һәм сабырлык сорап Аллага мөрәҗәгать итә. Коръәндә кешегә хас мөһим сыйфат буларак билгеләнгән сабырлык Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятында тотрыклы мотив буларак формалаша. Мисал өчен, Кол Галинең «Кыйссаи

Йосыф» дастанында сабырлык сыйфаты, Р. Ганиева фикеренчә, кеше матурлыгы буларак тәкъдим ителә [4: 24]. Г. Кандалый шигырьләрендә ул ихтыяр көче, кешенең рухи ныклыгы чагылышы буларак урын ала:

Иляһи, мин сабырсызны
Сабырлык юлына күндер!
(«Иляһи, мин сабырсызны...»)

Фәлсәфи лириканың матур үрнәге булган «Иляһи, барча галәмне...» шигырендә Г. Кандалыйның лирик герое тормыш тәҗрибәсе туплаган, башыннан кайгы-хәсрәтләрне күп кичергән кеше буларак күзаллана. Ул һаман да тирән борчу кичереп яши һәм үзен юату өчен җил, кош, агач кебек поэтик образларга мөрәҗәгать итә:

– Әйа йыгач, йәшең күпме?
Түгелгән йимешең күкме?
Бәнемдик сагышың күпме?–
Дәйүб сорам ки анлардин.

Риторик эндәш формасында бирелгән юлларда әдипнең сәнгати осталыгы, образлы фикерләве чагылыш таба. Әлеге шигырь ассоциатив рәвештә Х. Туфанның «Ак каен»(1933), «Агыла да болыт агыла» (1946) әсәрләрен хәтерләтә. XX йөз урталары татар поэзиясенең таҗы булган әдип иҗатында сагыш, сагыну-юксыну халәтенең һәркем кичерешләре рәвешендә кабул ителердәй сурәтләрдә бирелүендә XIX йөз шагыйре йогынтысы сизелә. Г. Кандалыйның гомер, вакыт агышы, яшәү мәгънәсе, рухи һәм матди кыйммәтләр турында уйланулары нәтиҗәсе буларак дөнья күргән афористик яңгырашлы, фәлсәфи эчтәлекле шигъри юллары бүген дә заманча яңгырый: «Йакутлар табыладыр вакыт берлән, / Вакытлар табылмыйдыр йакут берлән».

Шагыйрьнең әдәби мирасы тема-мотивларның төрлелеге, чынбарлыкка йөз тотып иҗат итүе, күтәрелгән мәсьәләләрнең заманчалыгы, актуальлеге белән генә түгел, поэтик эшләнеше, сәнгать чаралары муллыгы белән дә яңа заман әдәбиятының башлангычында тора [5: 232–235]. Югарыда искәртелгәнчә, әдипнең беренче иҗат тәҗрибәләрендә алдагы язма әдәбият традицияләре зур урын алып тора. Бу, бер яктан, дидактикага нигезләнгән үгет-нәсихәтнең, дини-суфыйчыл карашларның өстенлек алуында, икенче яктан, әсәрләренең теле авыр булуда күренә.

Шагыйрьнең соңрак язылган шигырь-поэмаларында иҗат тәҗрибәсе арта барып, ул халыкчан тел нормаларын үзләштерә. Шуңа да Г. Кандалый язма әдәби телне җанлы сөйләм теленә якынайтуны башлап җибәрүчеләрнең берсе булып санала.

Әдип татар әдәбиятының бай традицияләре нигезендә шагыйрь булып формалаша. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны геройлары аның әсәрләрендә еш чагылыш таба: «Сәлам яздым сәңа, җаным, хәкыйкъәт, / Йосыф–Зөләйхадин алган нәсыйхәт». Ә инде Кол Галидә поэтик сурәт буларак кулланылган сәба җиле – иртәнге җил образы Г. Кандалый иҗатын иңләп үтә һәм лирик геройның күңел тибрәлешләрен, мәхәббәтен сөйгәненә илтүче хәбәрче сурәтендә бирелә:

Сәба йиле исәр булсаң
Парау атлыгъ нәфис җайга.
Сәламемне тикерәйсән
Сәхипҗамал абыстайга.
(«Сәхипҗамал»)

Г. Кандалый халыкның авыз иҗаты байлыгына бөтен рухы белән береккән. Ул аннан әдәби осталыкка, сурәтләр муллыгына өйрәнә. Шагыйрь еш кына халык җырлары стиленнән, образлы тасвирлардан, мәкаль-әйтемнәрдә җирләшкән афористик яңгырашлы поэтик сурәтләрдән иркен файдалана:

Тулган айдик йөзең матур икәндер,
Ике битең кояшдик нур икәндер.
Кашың кара сызылган күз өстендә,
Яңа айдик һавада – күк йөзендә.
(«Фәрхи»)

Ә инде халык иҗатыннан килә торган Сак-Сок, Ак Идел камышы, былбыл тавышы, гъәндәлиб (сандугач) сайравы һ.б. образ-тасвирлар ярату хисен аңлатучы чаралар булып хезмәт итә: «Сәнең буең Ак Иделнең камышы, / Сүләгән сүзләрең былбыл тауышы». Г. Кандалыйның күп шигырьләре хат формасында язылган. Бу аңа диалог, эчке монолог, эндәш, өндәү, беренче заттан яисә өченче заттан сөйләү кебек алымнарга мөрәҗәгать итү мөмкинлеге бирә. Аерым шигырьләренә ул чорда яшьләр арасында таралган хат калыбы формасы да килеп керә. Г. Кандалый шигырь-поэмаларында махсус һәм синтаксик сурәтләү чараларыннан эпитет, метафора, гипербола, антитеза,

чагыштыру, анафора, эпифора, рәдифле рифма, рефрен һ.б. матур үрнәкләре белән очрашабыз: «чишмәдик йәш агадыр күземдин»; «янып бетде йөрәк-бәгырь»; «надан кеше көтү көтәр, / галим кеше Бохар китәр» һ.б.

Шулай итеп, Г. Кандалый халык авыз иҗаты һәм урта гасыр татар әдәбиятының бай, уңдырышлы туфрагында формалаша, әдәби иҗатның гаҗәеп матур сурәт-тасвирларын, алым-чараларын алдагы буын укучыларга китереп җиткерә. Татар дөньясындагы һәртөрле торгынлыкка беренчеләрдән булып каршы чыккан Г. Курсави, Г. Утыз Имәни кебек шәхесләрнең караш-фикерләрен дәвам итеп, шагыйрь кеше шәхесен, аның ирек-хокукын, бәхеткә омтылышын, гадәти хис-кичерешләрен яклап чыга. Үзенең иҗаты белән татар әдәбиятының дөньяви юнәлештә үсеп китүенә көчле йогынты ясый, замандашлары белән бергә, Яңа заман татар әдәбиятының нигез ташларын салыша.

ӘДӘБИЯТ


1. Вәлиди Җ. Татар әдәбиятының барышы. – Оренбург: Вакыт, 1912. – 122 б.

2. Госманов М. Габделҗаббар Кандалый: бер гомердә ике чор // Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. Төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, кереш сүз авторы М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 588 б.

3. Ганиева Р. Сатирическое творчество Тукая. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964. – 84 с.

4. Ганиева Р. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 173 с.

5. Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. Әдәбият: Урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9 нчы с-фы өчен дәрес. – Казан: Мәгариф, 2000. – 336 б.


## ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙ ИҖАТЫ – ТАТАР ӘДӘБИ ТАРИХЫНЫҢ САГЫШЛЫ БЕР ДӘВЕРЕ


*И.Б. Бәширова*


Г. Кандалый (1797–1860) иҗаты – татар язма әдәби теле тарихында, талантлы шәхеснең кайнар хис-кичерешләре сурәтләнә торган, сагынулы-сагышлы бер чоры ул. Татар әдәби тел тарихында аерым әдипләрнең әсәрләрендә дәвам итеп килә торган классик-абруйлы төрки һәм җирле сөйләмә кануннарга буйсынып бара торган халыкчан төрки тел бу шагыйрьнең иҗатында

бергә кушылып дәвам ителә. Әлеге катлаулы мәсьәләне гадиләштереп, кыскача болай дияргә була:

«Языки мира. Тюркские языки» энциклопедик басмасында, төрки гаиләдә 15 борынгы һәм хәзерге 39 телнең, язма тарихы V–VI, VIII–IX, X–XII йөзләрдә башланып, XII–XIII гасырдан язма истәлегенең язылу датасы билгеле булган иске язулы (старописьменные) телләр дигәндә, азәрбәйҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк телләре белән рәттән, татар теле дә истә тотыла (Языки, 1997: 160, 395, 413, 427, 438, 358). Димәк, тикшерү барышында этносның барлыкка килүен билгеле бер датага бәйләп караган кебек (Гумилев, 1993: 26), әдәби телнең языла башлавын белдерә торган чыганакны да конкрет бер датага бәйләп карарга кирәк булу игътибар үзәгенә куела. Датага бәйле рәвештә, истәлекнең язылу урыны, ягъни кайсы дәүләттә (шәһәрдә) иҗат ителүе төгәл күрсәтелә. Шулай ук графикасы нинди булу, алдагы чорлардагы язма традиция белән һәм төбәгендәге җанлы сөйләмә тел (диалекты) белән мөнәсәбәте мәсьәләсе дә истә тотыла. Татар язма әдәби телен, иске язулы телләр рәтендә санаганда, аның VI–VIII гасырлардан гомумтөрки нигездә килә торган язмачылыгы булуы, XI–XII гасырларда Идел буе Болгар дәүләтенең кабер ташларында текст-штамплар язылуы (Хакимзянов, 1997: 47–48), XIII гасырда (1212–1233 елларда) Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» дастан-поэмасы иҗат ителүе истә тотыла (Хисамов, 2008: 10). Димәк, төрки-татар язма әдәби теле тарихы менә шушы дәвердән башлана. Габделҗаббар Кандалый иҗат итә башлаганда, татар язма әдәби теленең тугыз гасырдан артыграк дәвам итә торган тарихы булуы аңлашыла.

Татар язма әдәби тел тарихының гасырлар буена эзлекле рәвештә дәвам итә торган үсеш-үзгәрешен күзәтә бару уңаенда, авторларның барысы да үз әсәрләрен төрки телдә языла дип искәртә барулары, әмма әлеге поэзия әсәрләре языла торган төрки телнең, берсе икенчесеннән билгеле бер дәрәҗәдә аерымлана торган параллель ике юнәлештә баруы мәгълүм була. XI–XII–XIII гасырларда, «Кодатку Белек», «Кыйссаи-Йосыф» поэмалары – гарәп һәм фарсы алынмалары һәм Орхон-Енисей язмаларыннан килә торган китаби-традицион сүз һәм сүзформалар белән баетылган, региональ чикләнгән дәрәҗәдәге, классик-аристрократ төркидә, Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани Хикмәтләре – «киң катлам төрки кавеменә аңлаешлы» халыкчан сөйләмә тел әдәбиләштерелгән, билгеле бер дәрәҗәдә «алынма

сүзләрдән арындырылып, җирле сөйләм закончалыкларына таянып барлыкка килгән» төркидә (Гайнетдинов, 2014: 253, 131–132, 144, 187, 253); XIV гасыр Алтын Урда чоры әдәбиятында, Рабгузиның «Кыйссас-ел-әнбия» әсәре һәм «Кодекс-Куманикус» сүзлегендә чагылган язма телне шундый ук полюсларга бүлеп карарга мөмкин булуы күренә (Нуриева, 2004: 343); XV–XVI гасыр Казан ханлыгында, Өмми Камал иҗаты, Максудиның «Могҗизнамә», Мөхәммәдъярның поэмалары – классик иске татар телендә, Хәсән Кайгы, Казтуган һ.б. җырау-шагыйрьләр иҗаты – халыкчан юнәлештәге иске татар телендә (Әхмәтҗанов, 2014: 20; XVI гасыр ахыры – XVII йөздә, Суфи Аллаһиярның «Сөбателгаҗизин»әсәре – классик иске татар телендә, Мәүлә Колыйның «Хикмәтләр»е – халыкчан юнәлештәге иске татар телендә, «Җәмигыт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» кебек тарихи истәлекләр, аңлы рәвештә фольклорлаштырып язылганга күрә, традицион төрки халыкның үз сөйләмә теленә якынайтыла; XVII гасыр ахыры – XVIII йөздә, Батыршаның «Гарызнамә»се, «Мәҗмугыл хикәят», «Рисаләи Газизә», Г. Утыз Имәнинең башлангыч чор иҗаты – гарәп вә фарсы алынмалары мул кулланыла торган төрки классик иске татар телендә – «Илаһи бәет»ләр халыкчан юнәлештәге иске татар телендә иҗат ителә. (Төрки телнең параллель ике юнәлештә кулланылуы мәсьәләсен, телнең фонетика, грамматика, лексика тармакларына мөнәсәбәттә, җентекләп тикшерергә кирәклек күренә.)

Төрки телне файдаланудагы әлеге ике юнәлеш, билгеле бер үзгәрешләр алып, үз чорына яраклаштырыла. Мәсәлән, авторлар үзләре, алдагы дәверләрдән килә торган традицияне дәвам итеп, Казан төркиендә дип искәртә баралар, әмма ханлыгы җимерелгәч, килеп туган төп проблеманы хәл итүгә, ягъни XVII һәм XVIII гасырларның буеннан-буена, халыкның үз дәүләте булган заманнардагы хәтерен саклау вазыйфасын үтәү юнәлешендә языла: классик иске татар теленең мөмкинлеге, төрле әсәрдә төрле дәрәҗәдә, сөйләмә телнең һәм авыз иҗатының халыкчан формалары белән бергә кушыла. XVIII гасыр ахыры – XIX йөзнең уртасына кадәр язылган поэзия әсәрләрендә, Болгар-Казан шивәсе дип атала торган төрки тел тагын да сизелерлек булып аерымлана, чөнки авторлар әсәрләрен кайсы укучыга багышлап, нинди максатны күздә тотып иҗат итүләренә карап, язма төркине аңлы рәвештә төрле вариантта файдаланалар, ягъни хәзер адресатның кем булуына иҗтимагый-

сәяси мотив дәрәҗәсендә игътибар итәргә кирәк була: йырак илләрдә ислам тәгълиматын, Көнчыгыш әдәбиятен-мәдәниятен тирән үзләштереп, зур укымышлы булып кайткан татар халкының Г. Утыз-Имәни, Ә. Каргалый һ.б. кебек талантлы шәхесләре, үзләренең эпик характерындагы тирән эчтәлекле тезмә әсәрләрен, авылыннан чыкмаган, зур белем күрмәгән, указлы муллалар аңламаслык дәрәҗәдә гарәп-фарсы алынмаларын, гомумтөрки язма традицияне мул кулланып иҗат итәләр. Авторның хис-кичерешләре, кайгы-хәсрәте, шатлык-куанычы чагыла торган һәм турыдан – туры әти-әнисе, туганнары, сөйгән ярлары, «сәвекле җефете» укысын дип язылган «Иляһи бәет»ләр, Баһави һәм Г. Кандалыйның әсәрләре, авторлар үзләре кабат-кабат ассызыклаганча, шул кешеләр сөйләшә торган Болгар-Казан төбәгендә яшәүче телгә якын итеп бирелә. Шулай итеп, XIX йөзнең урталарында да, язмачылыгыбыз тарихының буеннан-буена, традиция булып килә торган мөһим үзенчәлек дәвам итеlә, гарәп-фарсы алынмалары белән туендырылган классик-абруйлы төркидә языла торган әсәрләр белән бер үк вакытта, сөйләмә сүз һәм сүз формаларын әдәбиләштереп мул кулланыла торган халыкчан иске татар телендә язылган әсәрләрнең дә эзлекле рәвештә параллель баруы күзәтелә. Шуның белән бергә, Г. Кандалыйның, башлангыч чорында язган поэмаларын классик абруйлы төркидә, Сәхипҗамал абыстайларга багышлап, аларны сагынып, теләп язган поэма һәм шигырьләрен шул авылдашлары сөйләшә торган телне әдәбиләштереп язуы билгеле. Димәк, **төрле авторның** әсәрләрендә параллель килә торган ике төрле төрки телне **бер үк автор** үзенең төрле әсәрләрендә файдалана һәм гасырлар буена килә торган традицияне үзенчәлекле рәвештә яңартып җибәрә.

Г. Кандалый иҗаты турында фәнни хезмәт язучы авторлар бу мәсьәләгә игътибар итәләр, әлбәттә. Билгеле булганча, шагыйрьнең әсәрләре XX гасырның урталарында гына җыентык булып укучыларга җиткерелә (Кандалый, 1960), әмма аның аерым шигырьләре төрле басмаларда урнаштырылып дөнья күрә (Госманов, 1988: 6–8). Басылмаганнары – телдән-телгә, кулдан-кулга күчеп йөри. Бу хакта Г. Ибраһимовның «Татар әдәбияты тарихына материаллар» дигән мәкаләсендә ачык әйтелә: «...Бездә эзләнгән вакытта, беренче кул материалларның ерак түгеллеге мәгълүм. ...Борынгы заман шагыйрьләрендән Габделҗаббар Кандалый бар. Моның хакында элек тә матбугатта

игълан кыйлынган мәгълүматка башка бик бай, ләкин һичкем тарафыннан файдаланылмаган материал ята. Бу ел Казанга килеп киткән Тифлистәге татар мөгаллиме Сөбханкулов иптәш миңа сөйләвенә күрә, Казаннан ерак түгел авылда – Кандалда (шагыйрьнең авылы) мәрхүм шагыйрьнең әллә ничаклы шигырьләре телдән-телгә, кулдан-кулга күчеп, җырланып йөри. Үз кулъязмалары да бар, ди. ...Әдәбият тарихы өчен материал җыйган вакытта, матбугатка кайчан да булса чыккан нәрсәләргә караганда, әнә шундый мәнбәгъләрдән эзләргә кирәклеген әйтеп үтүдер» (Ибраһимов, 1923, 2007: 139).

Г. Кандалый иҗаты турында башлап фикер әйтүчеләр, беренче чиратта, аның шигырьләренең теле үзенчәлегенә игътибар юнәлтә. К. Насыйри «Фәвакиһ-ел-җөләсә фи-л-әдәбият» китабында шагыйрьнең «Сәхипҗамал», «Фәрхи» поэмаларынннан һәм тагын аерым шигырьләреннән өзекләр китереп: «Бу әбйатның имля вә иншасы байтак яхшы төзелгәндер. Шул җәһәтдән игътибар кылынды. Мәрхүм Габделҗаббар – шагыйрь адәм имеш», – дип, авторның шагыйрь булуын тәкъдир итә (Насыйри, 1884). Җ. Вәлиди «Татар әдәбиятының барышы»дигән хезмәтендә, шул ук «Сәхипҗамал» поэмасының аерым өзекләрен урнаштыра һәм болай дип ассызыклый: «Без тарихе әдәбиятымызда чын татарча нәзымнар язучыны эзләгәндә, иң элек, Габделҗаббар әл-Кандалыйга очрыймыз». Шагыйрьнең әлеге үзенчәлеген шактый тулы итеп аңлатып бирә: «Буның заманында вә буннан элек, белмим, буның өслүбе илә нәзым язучылар булдымы икән?. ...Кандалыйның нәзымләре мәүзүгъ (тема) җәһәтендән бик тар вә бер төрле рәвешдәдер, ул аларны үзенең мәгъшукаләренә яза. ... Габделҗаббар әфәнденең бу нәзымләре бездә, язсаң җилдләр (томнар) тәшкил итәчәк “Чыкдым басу капкасын, Җәйдем киндер басмасын” һәм дә “Озындай озын бүрәнә, Чанага салсаң сүрәлә” рәвешендәге сарыф гавами җырлардан әллә кая өстен тора вә шуның белән бергә ул халыкныкы булудан да чыкмый, күз күрмәгән вә колак ишетмәгән вә һичбер аңлашылмый торган вә аңлашылуы матлуб тотылган нәрсәләр илә чуалмый. Ул һичбер урында диб әйтүрлек татар телен бозмый, гавами фәкать һәр кемгә аңлашылурдай ачык вә урынлы тәгъбирләрдән качмый, чит сүзләргә вә тәкәлефле тәгъбирләргә бик аз урын бирә; татарча сүзләрне бик осталык вә табкырлык илән кулланадыр. Без анда яхшы гына кувәи шигърия булганын сизәмез...» (Вәлиди, 1912: 93). Галим Г. Тукай иҗатына мөнәсә-

бәтле рәвештә анализын дәвам итә: «...Әгәр дә Габделҗаббар әфәнде бу нәзымларыны мәгъшукасы Сәхипҗамал абызтайга хаттабә йазмаса иде, без аны хәкыйкатән хатуннар хокукын хәммаль итүче вә аларның хөрриятен теләүче диеб карар вә аның бу нәзымларына Тукаевның: “Кич булгачдин үзе тагын эчеб кайта / Ауызы борыны сасыб, өст башын тынчыб кайта / Йаткызмакчы булсаң кулыңдан ычкына / Тәмсез сүзләр сөйли, сүгенә, кычкыралары” илә бер рәтгә куйар идек. Фәкать Кандалый хәзрәтендән хәзерге шагыйрьләремездәге (гумманность) вә (феминизм)ны бер кем дә сорамас. Ул, теләсә ниндәй максад белән булса булсын татар мужигының хатыны илә мөгалләмәсен бик дөрест сурәтдә тасвир кыйладыр. Андан шундин артыгыны дәгъва кыйлыб булмый. Күб шагыйрьләрнең ауызлары гашыйк җырлары илә ачыладыр. Нечкә билләр, аху күзләр, ай йөзләр, кыйгач каш вә шикәрле иренләр – шагыйрләрнең иң элекке илһамчыларыдыр. Соңра ул торган саен даирәи бәсыйрән киңәйтә...» (1912: 95–96). Аннан соң автор «Габделҗаббар әфәнденең бунда тагын берничә гүзәл нәзымларен язмыйча китеб булмый», – дип, «Парау илендә төш күрдем» һәм «Бере сукда, бере сакда» булып башлана торган шигъри өзекләрдән соң, чын күңелдән соклануын белдерә: «...Габделҗаббар әфәнде үзенең шигырьләрендә халык мәкальләрене вә халыкның фантазиясендә мәүҗүд булган нәрсәләрне кертеб әсәренә никадәр гүзәллек бирә вә үзенең чынчын халык рухлы бер татар идекене күрсәтәдер», – дип (1912: 97), шигырьләрен дәвам итә. Җ. Вәлиди әлеге шигырьләрне К. Насыйриның «Фәвакиһ-ел-җөләса-фи-л-әдәбият» җыентыгыннан алып бастыруын әйтеп уза (Вәлиди, 1912: 93–102).

Г. Кандалый шигырьләренең саф татар телендә язылуы хакында Ш. Рамазанов та искәртеп үтә. Ул «Г. Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле» дигән мәкаләсендә, Г. Утыз-Имәни, Ш. Зәки, Г. Чокрый иҗатыннан аерым өзекләр китерә дә, нәтиҗә ясый: «...боларны татарча нәфис сүз сәнгате үрнәкләре дип әйтү кыен. Монда татарча художестволы сүз культурасы гына түгел, гомумән татар сүзе дә бик аз гына сиземләнә. Бу тел үзенең лексик һәм грамматик төзелеше белән борынгы кыпчак-болгар, уйгәр-чыгытай, гарәп-фарсы, госманлы төрек һәм бераз татар телләренең катнашмасыннан гыйбарәт. XX йөзнең соңгы чирегенә чаклы татар поэзиясе, поэзия теле генә түгел, гомумән язма әдәбияты һәм язма әдәби теле әнә шундый корама һәм хаотик хәлдә иде. Габделҗаббар Кандалыйның саф

татар телендә язган берничә шигыре генә өстенлек итеп килгән гомуми хәлне, әлбәттә, үзгәртә алмады...» (Рамазанов, 1954: 58–60).

Аңлашылганча, К. Насыйри, Җ. Вәлиди, Ш. Рамазанов кебек галимнәр шагыйрь әсәрләре теленең халыкчан – татарча җанлы сөйләмдәгечә саф булуына игътибар итәләр. Шуның белән бергә, Х.Р. Курбатов «Кандалый шигырьләрендә тел, стиль, метрика һәм строфика» дигән мәкаләсендә: «Татар поэзиясендә Г. Кандалый – традицион төрки әдәби тел чикләрен кыю атлап чыгып (ләкин аерым очракларда аннан да бөтенләй баш тартмыйча), халыкның җанлы сөйләм телен бик иркенләп шигърияттләштерүче олы шагыйрьләрнең берсе. ...XX йөз башы шагыйре Г. Тукайга һәм аның замандашларына халыкның сөйләшү телен шигырь теле итеп куллануга беренче булып юлны Кандалый ача. Әмма моннан бу шагыйрьнең барлык әсәрләре дә халык теле белән язылган икән дип уйламаска кирәк. Урыны белән ул я традициядән аерыла алмыйча, яисә югары уй-тойгылар турында тасвир итәргә кирәк булганда, борынгы төрки әдәби телгә әйләнеп кайта...», – дип белдерә (Курбатов, 1984: 113–114 һ.б.). М. Госманов әлеге фикерне тагын да тәфсилләбрәк аңлата: «...шагыйрь чын-чыннан әдәби әсәр язу эшенә традицион иске әдәбият – суфичылык әдәбияты позициясеннән чыгып тотына. Г. Кандалыйның беренче җитди әдәби тәҗрибәләре сыйфатында ике поэмасын – «Рисаләи-иршад» («Тугъры юлга күндерүче китап») һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» әсәрләрен исәпкә алабыз. ...Беренче әсәрләрен ясалма телдә язудан башлаган шагыйрь әдәби эшчәнлегенең соңгы чорында халык теленнән аерылмаслык дәрәҗәдә гади итеп язу югарылыгына күтәрелде» (Госманов, 1988, 18, 51). Аңлашылганча, «ясалма тел» дигән вакытта, гомумтөрки традицион язма әдәби телгә нигезләнгән Г. Утыз Имәни, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки кебек авторларның XVIII гасыр ахыры – XIX йөзнең беренче яртысында иҗат ителгән әсәрләренең теле истә тотыла. Дөрес, Г. Кандалыйның поэмасы, Г. Утыз Имәни трактатлары шикелле, сүзгә-сүз тәрҗемә ителмичә дә аңлашыла, әмма һәр битнең яртысында диярлек хәзерге татар теленә аңлату урын ала (Кандалый, 1988: 245–316, 317–340). М. Гайнетдинов белдергәнчә, Г. Кандалый «мәдрәсәдән мәдрәсәгә сөрелеп йөргән», ягъни иҗатының башлангыч чорында ук, «Сөбәтел-гаҗизин»ннән килә торган оппозициячел традицияләргә тугрылыклы кала. Бу әсәрләрен автор төрки телдә

язуымны үтенделәр дип белдерә: «Бәгъзе яран фәкыйри, бәгъзе әннас / Әйләделәр бу гарибдин илтимас / Бер китабәт кыйссалардан әйләгел / Һәр нә гаҗәибдин улса – сөйләгел / Төрки улсын ул китабәте шәриф...» (Гайнетдинов, 1985: 83–84).

Шуның белән бергә, Г. Кандалый, тирә-юнендәге кешеләргә, гаиләсенә, табигать күренешләренә, бигрәк тә, Сәхипҗамал чибәр абыстайларга, бетмәс-төкәнмәс мәхәббәтен, хис-кичерешләрен турыдан-туры белдереп, үз исеменнән мөрәҗәгать итеп яза. Бу очракта инде Суфи Аллаһиярның «Сөбәтел-гаҗизин»е, яисә Г. Утыз Имәни, Ә. Каргалый, Ш. Зәки һ.б. иҗатларыннан, ягъни классик-абруйлы төрки телдә язылган әсәрләрдән килә торган традиция, икенче төрле төркигә, ягъни җирле сөйләмә кануннарга нигезләнеп килә торган традиция белән алмаштырыла һәм шигъри телнең барлык тармакларын файдалануда үзенчәлекле чагылыш таба. «Бу күренеш исә Г. Кандалый иҗатының бер гомер дәвамында төгәл ике чорны иңләп алуын барлыкка китерде», – дип яза бу хакта М. Госманов (1988: 63). Әлеге мәсьәлә Х.Р. Курбатов мәкаләсендә, шигырьләренең стиле, әдәби алым һәм сурәтләү чаралары, теле (кыпчак формалары, угыз формалары), синтаксис һәм лексика дип бүлеп тикшерелә (Курбатов, 1984: 113–152). Шулай ук Г. Кандалый әсәрләренең тел үзенчәлеге турында аерым мәкаләләр (А.Х. Нуриева, 1969), кандидатлык диссертациясе язылып яклануы (Юсупова, 1985) мәгълүм.

Бу урында, темага бәйле рәвештә, Г. Кандалый иҗатында «хис һәм шәхси хөрлек сыйфатында гәүдәләнгән идеянең», ягъни сагыну-сагышлану юнәлешендәге тасвирларны барлыкка китерә торган сүз, сүзтезмә, сүзформаларының кулланылышына кыскача игътибар ителә. Автор, үзенең туганнарын, баласын, чибәр абыстайларны өзелеп күрәсе килүен белдерү өчен, сагыну, сагышлану сүзен эзлекле файдалана, аның белән бергә кулланыла торган башка сүзләр ярдәмендә, әлеге төшенчә кабатланган саен тәгаенләнә: Туганың сагына, дигел, / Сагынып саргая дигел. ...Бәнемдик сагышың күпме? / Дәйүб сорам ки анлардин (1988: 89). Сагынмакдин бәет яздым, Газиз балам, әйа, сезгә (90). Түгәрәк алмадай башың / Каләмдәй сызылган кашың, / Сагынып дивана башым, / Сабыр телим бер Алладин. / Сагынамын көндезләрдә, / Дога кыйламын кичләрдә, / Сабыр телим бер Алладин (118), И Фатыйма ла, җанашым, / Бер тоташ бу сагышым. Йыладым, дәхи сыктандым, / Сагынып бик, булып моштакъ

(омтылу) (140). Йәшләр түгел – кан йылаймын / Сәне сагынган чагымда (146). Йөзен күргәч, сагышындин дидем: «Ух» (150). Сагынып «ух» оран саен / Кулым язарга кушами?. Сагнып йыгъласы булсам гомергә, / Эчем янып, дүнәр кара күмергә (155). Сәнең берлә күп уйнадым дөшемдә / Сөйләп булмый – сагышым күп эчемдә (202). Сагынмакдин сары булды чыраем, / Аермасын, кауыштырсын Ходаем/. Сәлам улсын сәңа, ләйли бәһарем, / Сәне сагынамын ләйли нәһарем (236), Сагышыңдин тапмый йөргән юлларым (355), Искә төшеп, сагыныбдыр һәм сәни (356), Көн дә сагыш, төн дә сагышың тотып / Бинамазым, биниязым ут йотып (357), Йоклыймынмы йә сагышлап кичәме? / Каплап алды сагышың әүкатеми (358), Ни хисабда, нә сагышда /Тора микән бу хальләрдә (375), Әйа җаным, чибәрем лә / Әйа җаным, сөйәәмен лә / Ки белмәймен нидәрем лә, / Сагышымдин мөдам итдем (өзлексез) (376), Җанашым, белмисең сагынганымны / Сәнең өчен күз-йәш агызганымны (385). Сахибҗәмал, чибәрем лә / И матурым, сөйәрем лә / И белмәдем нидәрем лә / Сагышыңны мөдам итдем (388), Кылышып вәгъдәи мәхсукъ / Сагынышадыр илләрдә (391). Сагышың берлә бер йылым / Бәңа тойла ки бең йылдай (397), Сагышыңдин кибеп-корып / Бетеп китде лә айвай ла. Бүген дә, танда да сагыш/ Бизәге юк, дәгел нәгыш (401), Сагынгачдин йыламыйча / Калалмассән абыстай ла / Тәмами гомрең үткүнчә / Сагышлап юкны яткунча (404). Сагышың шул кадәр къәсдан (эзәрлекләхчән) (416), Сагышың берлә тотош тик / Барып күрер идем, коштик/очып, Сахибҗәмалемне (423) һ.б.

Аңлашылганча, сагыну-сагышлану төшенчәсенең сүз-сурәт булып катлаулануы, кабатланып кулланылуы белән бергә, башка тасвирый чаралар ярдәмендә барлыкка китерелә: шигырьләр, гадәттә, Илаһи, Раббем, Аллаһ, әйа йил, әйа кош, әйа йыгач, әйа балам, саба йиле, и баде саба, әйа гариф (акыл иясе)дип, яисә җаныем, җаныкаем, җанашым, җәмалым,күз алмам, багалмам, аппак, туганым, сеңлем, матурым, сәрвиҗәмалым, мәгъшукый җан, гүзәл йар, канатым, и гүзәлем, ике күзем, абыстаем, кызыл йөзем, тулан аем, кояшым, кызыл алмам, мәкъшук, табибәм, җаным-гүзәлем, бәгърем парәсый, каләм каш, сылукаем, абызтутыкай, алтыным, көмешем, сандугачым, карлыгачым, былбылым, ай гынам ла, көн генәм лә, гөл генәм, җан гынам ла, тән генәм лә, көл генәм, җәүһәрем лә, гәүһәрем лә, нур гынам, сәрвием лә, җәннәтем лә, хур гынам, назигым лә, үзәгем лә, гүзәлем кебек

нәфис эндәш сүзләр; Фатыйма, Бәдига, Рабига, Сәхипҗамалым, Бәдигъҗамалым, Фәрхи, Фәрхисөрур, Сәхипҗамал абыстай ла, Сәхиб, дип, аерым шәхесләрне исемнәрен атап эндәшүләр белән башлана; шуның белән бергә, кайгы-хәсрәт, йөрәк ташу, күздән канлы йәш ага, сәлам яздым, эч пошу, дөньяга таянмау, күтәрмә борның, күзем нуры, гакылымны йуйдың, сары сукды йөземә, дошманыңа язмасын, чулпандыр ике күзең, тәүбә кыйлгыл бу эшкә, гыйшыклык уды, сабрым йукдыр, гыйшыклык хале, моңаеп интизар улу, ак йакут ирен кебек, гыйшыклык чабы сәлам хаты һәм башка бик күп сандагы, сөйләмә һәм язма телебезнең иксез-чиксез байлыгын күрсәтә торган тотрыклы тезмәләр белән уратылып, кара-каршы фикер алышу формаларына салып бирелә.

Сагышның берөзлексез тоташ булуы, лексик сүз-сурәтләр белән бергә, грамматик категорияләр белән дә тасвир ителә. Сөйләүченең нинди дә булса эш-хәрәкәтне башкарырга теләге булуын белдерә торган теләк фигыле бу вазыйфаны үтәү өчен иң кулай чара булып файдаланыла. Билгеле булганча, хәзерге әдәби телдә теләк фигыленең үзәге – берлек һәм күплектәге -ыйм, -им, -ыйк, -ик һәм башка кушымчалары белән белдерелә торган 1 зат формасы (Татар, 2002: 154–157). Теләк мәгънәсенең беренче татар грамматикаларында башка күрсәткечләр белән белдерелүе һәм әдәби әсәрләрдә төрле мәгънәләрдә кулланылуы мәгълүм (Бәширова, 2008: 259–278). Теләк мәгънәсенең төсмерләре һәм күрсәткечләренең активлыгы җанлы сөйләмә телдә тагын да ачыграк күренә (Юсупов, 2004: 475–501).Менә шушы байлыкның барысы да диярлек, ягъни хәзерге әдәби һәм сөйләмә телдә файдаланыла һәм традиция булып килә торган формалар һәм аларның, күп төрле мәгънә төсмере аңлата алуы Г. Кандалый иҗатында эшкә җигелә. Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында, авторның үз исеменнән чибәр абыстайларга сагынып-сагышланып мәхәббәтен сиздерергә тырышканда, -айым/-әйем, -ыйм/-ем/-ам, -а, -айын/-әйен, -алым/-әлем күрсәткечләре белән белдерелә торган 1 зат берлек һәм -айык/-әйек,-ыйк/-ик кушымчалы күплек сандагы теләк фигыльләренең бик тә актив кулланылуы, тагын са+на, са+чы формаларының булуы күзәтелә, аларның өмет итү,үтенү, борчылу, шәфкатьлерәк булырга кирәклек, мөмкинлек кебек төсмерләре контексттан, ягъни башка сүзләр белән бәйләнешеннән аңлашыла, -гай, -гәй, -кай, -кәй кушымчалары, асылда, хәзерге-киләчәк заман хикәя

фигыльнең мәгънәсендә аңлашыла, һәм шулай ук -са иде (сайде), -ү кәрәк, -ырга кирәк аналитик кушымчалар белән дә теләк мәгънәсе белдерелә. Боларның кайберләренең ничек итеп файдаланылуына игътибар итик. Сан ягыннан караганда, -айым/-әйем, -ыйм/-ем/-ам, -а, -айын/-әйен, -алым/-әлем күрсәткечләре белән белдерелә торган 1 зат берлек һәм -айык/-әйек, -ыйк/-ик кушымчалы күплек сандагы теләк фигыльләренең бик тә актив кулланылуы күзәтелә, аларның мәгънә төсмерен контекст билгели: Бу илләрдә торып калсам, / Ярамас кызга күз салсам, Атамның каргышын алсам... Качыйм тизрәк бу илләрдин (Кандалый, 1988: 75). Качыйм дигән теләк фигыль шарт фигыльләрдән аңлашыла торган шартлы гоман итүнең реаль тормышка ашуыннан шикләнү-борчылу модальлеген белдерә. Шул ук -ыйм кушымчалы фигыль түбәндәге дүртъюллыкта зар, игътизар, интизар белән көчәйтелгән үтенү, ялварулы теләкне белдерә: Бу кадәр моңлы зар берлән, / Бу кадәр игътизар берлән, / Бу кадәр интизар берлән Сорыйм сези, әйа балам (91). Шушы ук тема -айым формалы теләк фигыль белән белдерелә: Тагын азрак бән язайым, йитәрме, Бу хәсрәтләр йөрәкемдән китәрме (93). Түбәндәге юлларда да шул ук зарлы теләк белдерелә: Сәнең өчен зар-интизар булайым, Гомерләрне сәнең берлә сорайым ...(207). Шул ук кушымча сабырсызлыклы, инәлүле теләкне белдерә: Мәхәббәтне сәңа салды Ходайым, Моны йазмай ни халь илә түзәйем... (197). Сәне күрми ни халь берлә чыдайым, Сәне бәңа бирер микән Ходаем? (238). Шул ук кушымча белән 2 зат теләгенең тормышка ашырга тиешлеген белдерелә: Ишет, тыңыла, кыз, ишет, / Ки бер үгетемне биш ит, Киңәшдән чыкмый бер эш ит, Күр улмайым дисәң, аппак (142). Күр улмайым – сукыр булмайым (булмыйм). -ыйм формасы белән сөйгән ярга эндәшеп, аның белән киңәшеп аңларга тырышуны, шөбһәләнүле теләкне белдерә: Языйм микән, йитәр микән, / Сәнең мәдхең бетәр микән (139). Ничек табыйм ла көй генәм, Сөйләп бир, җанеки генәм (141). Язайыммы, җаныкайым, йитәрме? Сәне алмай күңел гыйшкы бетәрме? (153). –әйем кушымчасы үтенүле, өмет итүле теләкне белдерә: Җаныкайым, ишегең ач – керәйем, / Гөл-мөбәрәк йөзеңне һәм күрәйем. / Мөбарәк йөзләреңне күргәндин соң/ Ауызыңдин бер суырып үбәйем (222). Рифмага туры китерелеп, теләкне белдерә торган кушымча кыскарып та кулланыла: Сәламләр әйләдем, җаным – гүзәлем, / Сәне күрмәй нә халь итеп түзәрем (223). Автор сөйгән кызга әйтәсе килгән теләгән аңа эндәшеп,

хикәяләү рәвешендә җиткереләчәген белдерә: Ки бән алдым каләмемне, Язайым дип сәламемне (107) / Колак салып ишет, җаным, Идәйем бер хикәйәти (158). / Сүзем язылды күп төрле, / Тагы да әйтәйем берне (182). Түбәндәге юлларда да ирештерелә торган көчле теләк шул ук хикәяләү ысулы белән белдерелә: Гыйшыклыкдин халем йитде үләргә, / Ки белмәдем халем кемгә сөйләргә./ Гыйшыклыкдин сөйләйем бер хикәят, / Бәнем гыйшкым сәңа дөште бигайәт.../ Язайым, җаныкай, бераз сәламләр, / Сәламдин соң йазайым мән кәлямләр (1988: 204–205). / Кабул итсәң сәламемне, җанашым, / Ки әйтәйем сүземне, кара кашым (224). Шигырьләрендәге кебек үк, чибәр кызларга багышланган поэмаларында да, автор аларга эндәшеп, көчле мәхәббәтен кабул итүләрен өметләнеп, инәлүле теләген үз исеменнән хикәяләү рәвешендә белдерүгә дәвам итәлә: Сәңа гашыйк улып, Шәфгый, / Идәйем бер хикәяти (1988: 343). / Сүзем язылды күп төрле, / Тагын да әйтәйем берне (345). / Колак салып ишет, Шәфгый, / Ки сөйләйем сәңа бер дөш... / Сүземне сөйләйем башдин, / Хәбәр виреп каләм кашдин... (346). / Йә сурәт кыйлгучыларга / Сәнең өчен варыйм микән? (348).

Бу поэмада сүз җаена туры китерелеп, ияртчен шарт җөмләнең баш җөмләсе итеп бирелә торган җөмләләрдә, теләк мәгънәсе -а кушымчалы фигыльләр белән дә күрсәтелә: Нәчә мәдх әйләмәс бетмәс, / Гакыл дәхи фәһем итмәс, / Кәгазьдә һәм кара йитмәс, / Язарга сурәтең, Шәфгый ...дип, тезелеп бирелә торган ияртчен җөмләләрнең баш җөмләләрендә, чибәр абыстайның йефәк сачләре, инҗү кеби дешләре, нәзек биле, талдай буйы, шикәр балдик делен ничек итеп мактарга теләве сурәтләнеп бирелә: Йефәк сачле башыңныму, / Яңа айдик кашыңныму/ Һәм унбишдә йәшеңнемү, – / Нә мәдх илә идәм рәфгый. ... /Ак алмадай ки түшеңне – / Кайу берин язам, Шәфгый... / Шикәр – балдик делеңнемү, / Дәхи нәзек билеңнемү, / Йә түшдәге генәңнемү – / Кайу берин дийәм, Шәфгый (349): Кайсын хәлиткеч дәва итим, кайсын языйм, кайсын дийим дип гаҗизләнүле теләк белдерелә, теләк фигыле -а/-ә/-и кушымчалары белән бирелә. Әлеге кушымчалы фигыль белән теләк мәгънәсенең белдерелүе башка строфаларда да дәвам итәлә: Төсең-буеңны, и җаный, / Кайу берин язам, җаный... / Дил алырдай кочакларың, / Кайу берсен язам, җаный... (350).

«Фәрхи» поэмасында абызтутыйга җиткерелергә тиешле хис-кичерешләр авторның саба йиле белән фикер алышуы

алымында бара. Бу әсәрдә әлегә кадәр бер-ике мәртәбә генә файдаланган: Бән сезләрә бер сүземне, / Йад итәлем, ки аңлагыл... (173) -әлем кушымчалы теләк фигыле эшкә җигелә:/ Назигем лә, үзәгем лә, гүзәлем, – / Фәрхи, айгыл, ничек итеп түзәлем?! (356).

Персонажның сүзләре итеп бирелә торган юлда -асы иде формасы белән көчле теләк белдерелә: «Кияүгә барасы иде!» – Дәйүб үткәрде әүкъадән... (363). -ыйм кушымчалы теләк фигыле 2 затка мөнәсәбәтле итеп бирелсә дә, гомуми затка каратылганы аңлашыла: Агач башындагы кошны Минеке дип әйтеп булмас, / Очып китсә япан җирдән – / Тотыйм дисәң, тотып булмас (364).

«Мәгъшукнамә» поэмасында гашыйк булган кешенең хәлләре, тәгаенләнгән аерым шәхескә түгел, бәлки гомум укучыга каратыла, авторның 3 заттан бара торган хикәяләве 1 зат белән чиратлаша, бу уңайдан укучыга эндәшеп, аңа җиткерелергә тиеш зарлы-моңлы теләген хикәяләү рәвешендә белдерүе дәвам ителә: Әйа гариф, ачып кара күзеңне, / Бән әйтәйем, ки тыңлагыл сүземне (373). / Әйа гариф, язайым бер хикәйәт, / Хәлаикъ кыйлмасын безне шикяйәт. ... / Сүземне сүзләйем башдин, / Хәбәр бирәм каләм кашдин (374). Теләк төшенчәсе үзенең лексик атамасы белән дә кулланыла: Ләбем кибде теләк теләб Иляһым, / Грефтар булганым – күпдер гөнаһым (372).

Бу поэмада да 1 зат берлек сандагы теләк мәгънәсе -алем кушымчасы белән белдерелә: Сабырлык берлән әйтәлем сүземдин, / Бу гыйшыклык бәнем үтде үземдин (372). -айым кушымчасы белән чиратлашып бирелә: Җанашым, әйтәйем аңла! / Моны фәһем итсәнә, җаный (380). Түбәндәге юлларда -гәй кушымчалы фигыль кулланыла: Ки кяшки дөньяга килмәгәй идең, / Бу гыйшык җәфасын күрмәгәй идем (385).

Сүз җаеннан, ягъни идең, идем ярдәмлекләреннән аңлашылганча, беренче җөмләдә 2 затка караган реаль булмаган шарт белдерелә: дөньяга килмәсәң иде, икенче җөмләдә 1 затка караган юклыктагы хәзерге-киләчәк замандагы: гыйшык җәфасын күрмәс идем дип, үкенү белдерелә. «Сәхипҗамал» поэмасында -гай кушымчалы фигыль, -са күрсәткечле реаль шартны белдерә торган иярчен җөмләнең баш җөмләсендә, 2 затка мөнәсәбәтле каратылган хәзерге-киләчәк хикәя фигыльнең мәгънәсе белән кулланыла: Мажик ир булса юлдашың, / Күңелдин китмәгәй яшең (1988: 392).

Саба йиленә эндәшеп үтенү белдерелгәндә, -са күрсәткечле реаль шартны белдерә торган иярчен җөмләнең баш җөмләсендәге -гәй күрсәткечле фигыль, 2 затка мөрәҗәгать ителеп, өмет итүле теләк-үтенү мәгънәсе белән кулланыла: Сәба йиле, исәр булсаң / Парау атлыгъ җайга, / Сәламемне тикергәйсән / Сахибҗәмал абыстайга... (401). Шундый ук төзелештәге җөмләдә, -гай күрсәткечле фигыль 2 затка каратылган хәзерге-киләчәк хикәя фигыльнең мәгънәсе белән кулланыла: Өзелеп калса бер галим, / Йар итсәң бер надан залим, / Иманың калмагай салим, – / Ишет, бик бел, абыстай ла... Түбәндәге җөмләләрдә -гай күрсәткечле фигыль 2 нче һәм 3 затларга каратылган хәзерге-киләчәк хикәя фигыльнең мәгънәсендә файдаланыла: Надан ирнең күзе төтен, Дине һәм булмагай бөтен... (405). Катып-калҗып йөрер үзе, Чүгеп бөгелмәгәй тезе... (407). Эшең һич китмәгәй хутка, Гомергә буласән мәфтүн... (408).

Теләү мәгънәсе үзенең атамасы белән дә бирелә: Ирең сәүмәккә теләсәң... (393). Авторның әлеге поэмасына кадәр үк, аерым шигырьләрендә, -гәй кушымчалы фигыльләренең төрле затка каратылып кулланылуы күренә иде: Ки кяшки дөньяга килмәгәй идем, / Бу хәсрәтләрне бән күрмәгәй идем (77) дип башланган шигырендә беренче юлдагы -гәй кушымчалы фигыльнең 1 затка караган реаль булмаган шарт фигыль мәгънәсендә файдаланылауы аңлашыла. Бу хатымны йибәрдем бән пичәтләп, / Укыгайсән, җаный, боны хисаблап (130) һәм шул ук типтагы: Моны яздым сезгә, җаный, кисәкләп, / Укыгайсән, җаный, моны исәпләп (241) дигән юлда, -гай сән 2 затка каратылып, киләчәк заманга юнәлдерелгән мәгънәне аңлата.

«Сәхипҗамал» поэмасында башка әсәрләрендә сирәк кенә күренеп китә торган -гай формалы фигыльләрне еш кабатлый, нәтиҗәдә, аерым бер кызга белдерелә торган теләк гомумиләштерелеп кабул ителә, шәхси мәхәббәт кенә түгел, гыйлемлелеккә каршы куелган наданлык, наданлыкның үтә чыккан ярамаганлыгына ышандырырга теләү тасвир ителә. Сурәтләү лексик чаралар белән көчәйтелә. -гай кушымчалы фигыльләрнең әлеге мәгънәсе белән авторның Бән сезләрә бер сүземне, / Йад идәлем, ки аңлагыл, / Колак дотып бу сүземне, / Ихлас берлә ки дыңлагыл дип, башлана торган шигырендә дә надан кешегә карасаң, Аллаһы да разый имәс дип, наданлыкның ни дәрәҗәдә начар булуы сурәтләнгәндә тезелеп файдалануы күренгән иде: Наданның хале бу улгай, / Чабатасына туфрак тулгай, / Оекы һәм

кара булгай, – / Чыкуб хатун кагар аный. … / Бу мескин чыкубән какгай, / Ки әле туфракга баткай, / Керүбән катында яткай, / Торып да ул үбәр аный. ... / Киеп лапталары тузгай, / Кадерсез гомре, бел, узгай, / Ишетеңез моны сез, һай, – Ахирәт эстәмәк къәный. / Аякы, тубыкы бәйләнгәй, / Йите кат киндерә әйләнгәй, / Кәзеб сүзләргә бәйләнгәй, / Басубән гъәфләти аный (175–176). Автор үзенең «...кешеләрне изге нияткә, яхшы гамәлгә, димәк, чын мөселманлыкка чакырган «нәсаих»тан, ягъни үгет-нәсихәтләрдән гыйбарәт» (Госманов, 1988: 18) «Рисаләи-л-иршад» («Тугъры юлга күндерүче китап») исемле дини-дидактик «вәгазьләр бабедин» булган беренче поэмасында да шул ук -гәй кушымчалы фигыльләрне бер-бер артлы тезеп файдаланганы күренә: Йегетлек йил кеби үткәй, / Къарилык фи-з-зәман йиткәй, / Бакып күр халеңи: ниткәй, / Фәсадәтдә үтеп рузгяр (Кандалый, 1988: 252).

Сүз сөрешеннән, -кәй күрсәткечле фигыльләрнең 3 затка каратылып, яшьлек җил кебек үтә (үтәр), картлык тиз заман җитә (җитәр), халең ничек була (булыр) дип әйтергә мөмкин булуы, хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла. Бозыклардан, мәкерлек эшләүчеләрдән, хыянәтче, икейөзле, үҗәт, ахмаклардан ерак торырга кирәклек фикере түбәндәге юлларда бирелә: Шәйатин, бел, гъөдур улгай, Хакында гөфтегү кыйлгай. / Мәкерләр җөстежү кыйлгай, / Заляләтдә бә-иҗтиһад, ягъни бел, шәйтаннар оятсыз була (булыр), чынлыкта әңгәмә кыла (кылыр), мәкерләр казыну кыла (кылыр), бозыклыкта тырышлык белән. Димәк, хәзерге-киләчәк заманны белдерә торган хикәя фигыль мәгънәсендә файдаланыла торган -гай күрсәткечле фигыльләрне автор гомум мәгълүм хакыйкатьне дини-дидактик һәм көнкүреш-тормышчан нигездә үгетләү, нәсихәт бирү өчен уңайлы булган чара буларак, эзлекле рәвештә тезелеп бара торган боеру мәгънәсен белдерә торган фигыльләр белән бергә яратып файдалана.

Шуның белән бергә, и бән алдым каләмемне, /Язайым дип кәлямемне, / Яза белмим кәлямемне, – Кем илткәй бу сәламемне? (107) дип башлана торган шигыренең һәр дүртъюллыгы ахырында алты мәртәбә кабатланып бирелә торган хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәсендәге -кәй кушымчалы фигыльнең бер үк вакыта өмет итү һәм шикләнүен белдереп кулланылу да мәгълүм. Шулай итеп, Г. Кандалый иҗатына нигезләнеп, -гай һәм -ай (ым, ык) формалы теләк фигыльләренең охшашлыгы истә

тотылганы хәлдә, -гай формасының функциясе ягыннан үзенчәлекле булуын танырга туры килә (Щербак, 1976: 184–186).

«Сәхипҗамал» поэмасында да җаныкайга турыдан-туры эндәшеп, инәлүне теләк -ыйм кушымчасы белән белдерелә: Ничек табыйм ла көй генәм? / Сөйләп бир, җанеки генәм! Матурым, җанеки генәм, Язып йибәр дәхи хатлар (416). / Кемне генә табыйм икән, Күреб Сахибҗәмалымны, / Гыйшыкымны бәйан итеп, Сөйләп бирердәй халемне (422). / И матурым, гүзәлем лә, Ничек кенә түзәлем лә (423). / Билең нечкә – кысыйм дисәм, / Буең зифа – кочыйм дисәм, / Сәңа таба очыйм дисәм, Кирәк баде Сөләймани! (424). Димәк, шәхси теләк белдерелгәндә, авторның барлык әсәрләрендә дә, тыңлаучыга эндәшеп төрле төсмерле теләкне белдерү өчен -айым, -ыйм, -ем кушымчалы фигыльләр яратып кулланылуы күренә.

Теләк фигыльнең 1 зат күплек саны -айык/-әйек кушымчасы белән белдерелә: Болай торганча икәү ары-бире, / Кушылайык икәүләп, китмә кире (151). / Әгәр чәнди мәне мәхрүм итәрсәң, / Күрәйек нинди йегеткә китәрсән (161) / Хисабың, сагышың кайда? / Болай торуда ни файда, / Каушыйк без шушы айда. / Каушыйк инде бу айда, / Вакыт җиткән ки, җаный ла! / Ирадәң әллә байларда? – / Фида җаным сәңа, җаный (183). / Кушылайык икәүлән, ахирәт дус! (360). / Каушыйк инде бу айда, / Вакыт йиткән, и җанкәй лә! (421). Мәгънәсе ягыннан караганда, бу фигыльләр белән үтенү, көчле теләк белдерелә.

-әйен кушымчалы теләк фигыле дә сүз сөрешеннән бергәлекне белдерә кебек: Бән әгәр күрешәйен дисәм, / Шәйәд әллә ояласаң (138). / Күрешәйек дип тә әйтергә мөмкин кебек. Әмма автор бер шигырендә: Дийәен бән ишет моный – дигән юлны икенчеләп Дийәйем бән, сән ишеткел дип кабатлый, ягъни берлек санда белдерелүе аңлашыла (177–178).

Шулай итеп, Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында, авторның үз исеменнән чибәр абыстайларга мәхәббәт белдерелгәндә, -айым/-әйем, -ыйм/-ем/-ам, -а, -айын/-әйен, -алым/-әлем күрсәткечләре белән белдерелә торган 1 зат берлек һәм -айык/-әйек, -ыйк/-ик кушымчалы күплек сандагы теләк фигыльләренең бик тә актив кулланылуы күзәтелә, аларның өмет итү, үтенү, борчылу, шәфкатьлерәк булырга кирәклек, мөмкинлек кебек төсмерләре контексттан, ягъни башка сүзләр белән бәйләнешеннән аңлашыла. Аерым формалар, төрле шигырьләрдә дә билгеле бер сүзләр белән кабатланып файдаланыла. Мәсәлән, шактый сирәк

күренә торган -алем кушымчасы: Бән сезләрә бер сүземне, Йад итәлем, ки аңлагыл... (173), Фәрхи, айгыл, ничек итеп түзәлем?! (356), Сабырлык берлән әйтәлем сүземдин... (372), И матурым, гүзәлем лә, Ничек кенә түзәлем лә (423) дигән юллардан күренгәнчә, -алем формасы, нигездә, чибәр кызга мөрәҗәгать итеп, сүз әйтү дигән бәйләнештә бирелә. Кандалыйныкы булуы ихтимал әсәрләр дип бирелә торган шигырьдә дә шундый ук өзек барлыгы күренә: Ибтида кыйлам, Сәңа кәлямем, / Җаныкәем, сезгә Әйтәм сәламем. / Нәзымлар берлән Әйтәлем кәлям... / Бер сүзем вардыр, Әйтәлем сәңа, / Әүвәлдин, җаный, Әйтәлем боный... (Кандалый, 1988: 439–440).

-гай/-гәй/, -кай/-кәй күрсәткечле фигыль, асылда, иярчен шарт җөмләнең баш җөмләсе итеп бирелә торган җөмләләрдә, реаль булган, яисә реаль булмаган шартларга бәйле булачак хәзерге-киләчәк заман мәгънәсендә, гомум мәгълүм дини-дидактик һәм гыйлемлекне мактап, наданлыкны хурлап языла торган өзекләрдә кулланыла. Димәк, Г. Кандалый иҗатында традицион рәвештә теләк фигыль кушымчасы дип санала торган күрсәткечнең функциясе башкачарак вазыйфа үти була.

Теләк мәгънәсе аналитик формалар белән дә белдерелә. Персонажның сүзләре итеп бирелә торган юлда -асы иде формасы белән көчле теләк белдерелә: «Кияүгә барасы иде!» – Дәйүб үткәрде әүкъадән... (363) һ.б.

2 зат берлек сандагы боерык фигыле имди ярдәмлеге белән Ходайга ялварулы, өмет итүле көчле теләкне белдерә: Сәнең өчен эреп сарка йөрәк маем, / Фазле берлән сәне бәңа бирсен имди... / Кичә-көндез телләремдә сәндер сүзем, / Бер Ходаем сәни бәңа бирсен имди... (109). -са иде формасы белән каргаулы теләк белдерелә: Барган ирең торсайде чыбыркы тагып, / Көнетөне торса иде алып-чагып, / Сукъган йирең чыкса иде кара янып, / Шул вакытда бән исеңә төшәрем имди... (114).

Шул ук форма белән үтенүле теләк белдерелә: Хода нөсърәт бу көн вирсәйе безгә, / Каләм тотып сәлам язсайы сезгә .../ Ходаем язса иде, күрсәм иде, / Сәнең гөлтик йөзеңдин үпсәм иде (385–386). -са+на, -са+чы формасы белән үтенүле теләк белдерелә: Сагынып, и Фатыйма ла, / Килсәнә бер катыйма ла... (133). / Бисмилла дип ки башладым ки кәлямем, / Хуш улсачы бәнем язган сәламем... (384). / Әйа гариф, ки белсәңче халемне, / Бирер идең үзең газиз җаныңны... (387).

-ү кәрәк, -ырга кирәк имди формасы теләк белдерү мәгънәсе белән кулланыла: Сән дә бәне яманласаң, үзең ятлап, / Бу дөньяны ташлап китү кирәк имди... / Күрмәймүсән: сары тулды нурлы йөзгә? / Бу сүзләргә ышанырга кирәк имди... (111) һ.б.

Шулай итеп, Г. Кандалыйның шигырь һәм поэмаларында, авторның үз исеменнән чибәр абыстайларга мәхәббәт белдерелгәндә, айым/-әйем, -ыйм/-ем/-ам, -а, -айын/-әйен, -алым/-әлем күрсәткечләре белән белдерелә торган 1 зат берлек һәм -айык/-әйек, -ыйк/-ик кушымчалы күплек сандагы теләк фигыльләренең бик тә актив кулланылуы, тагын са+на, са+чы формаларының булуы күзәтелә, аларның өмет итү,үтенү, борчылу, шәфкатьлерәк булырга кирәклек, мөмкинлек кебек төсмерләре контексттан, ягъни башка сүзләр белән бәйләнешеннән, аңлашыла; -гай, -гәй, -кай, -кәй кушымчалары, асылда, хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәсендә аңлашыла, һәм шулай ук -са иде (сайде), -ү кәрәк, -ырга кирәк аналитик кушымчалар белән дә теләк мәгънәсе белдерелә. Шулай итеп, Г. Кандалый лексик чаралар һәм теләк мәгънәсенең формалары белән бергә сагыну-сагышлануын тасвир итә алган.

## ЧЫГАНАК

Кандалый Г. Сахибҗәмал. Мелла Габделҗаббар әл-Кандалый иншасы / Габделкаюм Насыйри «Фәвакиһ-ел җөләса фи-л-әдәбият». – Казан: Ун-т тип., 1884. – Б. 559–579.

Кандалый Г. Фәрхи / Габделкаюм Насыйри «Фәвакиһ-ел җөләса фи-л -әдәбият». – Казан: Ун-т тип., 1884. – Б. 581–583.

Кандалый Г. Сахибҗәмал. Өзекләр // Җамаледдин Вәлидов. Татар әдәбиятының барышы. – Оренбург: Вакыт, 1912. – Б. 93–98.

Кандалый Г. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар / төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, кереш сүз авторы М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 558 б.

## ФӘННИ-ТЕОРЕТИК ӘДӘБИЯТ

Әхмәтҗанов М. Казан ханлыгы чоры (XV–XVI гасырлар) татар әдәбияты // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т. XV–XVШ гасырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 471 б.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: жанр-стильләре, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык. – Казан, 2008. – 340 б.

Гайнетдинов М. Әдәбият үсешенең төп тенденцияләре // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 2 т. XIX йөз татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 83–84.

Гумилев Л.Н. Древние тюрки. – М., 1993. – 526 с.

Ибраһимов Г. Татар әдәбияты тарихына материаллар // Милләт. Тел. Әдәбият. Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 137–140.

Курбатов Х.Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Б. 113–152.

Нуриева А.Х. Кандалый әсәрләренең тел үзенчәлеге // Совет мәктәбе. –1969. – № 8. – Б. 42–43.

Нуриева Ф.Ш. Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. – Казань, 2004. – 376 с.

Рамазанов Ш. Г. Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле // Татар теле буенча очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – Б. 58–92.

Татар грамматикасы. Өч томда. Морфология. – Т. II. – М.: Инсан; Казань: Фикер, 2002.

Хакимзянов Ф.С. Булгарский язык // Языки мира. Тюркские языки. – Бишкек: Издательский Дом «Кыргызстан», 1997. – С. 47–48.

Хисамов Н. Халкыбызның шигъри юлдашы // Кол Гали. Кыйссаи Йосыф: Хәзерге әдәби телгә шигъри тәрҗемә. – Казан: Дом печати, 2008. – Б. 5–19.

Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка: категории глагола. – Казань: Фэн, 2004. – 592 с.

Юсупова А.М. Роль Г. Кандалый в развитии татарского литературного языка XIX века (Лексика и фразеология). – Уфа, 1985. – 181 с.

Языки мира. Тюркские языки. – Бишкек: Издательский Дом «Кыргызстан», 1997. – 543 с.

## ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙНЫҢ МӘХӘББӘТ ЛИРИКАСЫНДА ФОЛЬКЛОРИЗМНАР

*Р.Ф. Сафиуллина*

Дин әһеле, гыйлем иясе, шагыйрь Габделҗаббар ибне Габделмәҗит Кандалый (1797–1860) үзеннән соң бай иҗади мирас калдырган. Аның иҗаты, киштәләрдә тузан җыеп ятмыйча, халыкка таралган. Ул халкыбызның гүзәл әсәрләре белән беррәттән, милли хәзинәләребезне баетты. Шулай ук Габделҗаббар хәзрәт үзе дә әлеге тиңсез хәзинә – фольклор үрнәкләреннән оста файдаланган.

Г. Кандалый иҗатында саны, сыйфаты, камил эшләнеше ягыннан иң мөһим урынны мәхәббәт лирикасы алып тора. Дөнья классикасы һәм милли әдәбиятыбыз белән таныш хәзерге заман кешесенә, мөгаен, мәхәббәт турында Кандалыйдан да шәбрәк әйтүчеләр булган һәм бар, дигән фикер дә килергә мөмкиндер. Чөнки хәзер инде

Кашың кара сызылмыштыр,
Тешең энҗе тезелмештер,
Йөрәк-бәгърем өзелмештер
Гыйшык тотып сиңа каты…
(Кандалый, 377 б.)[1]

кебек әдәби алымнар белән берәүне дә шаккатырып булмый. Безнең заман кешесенә алар гадәти тоела. Әмма Кандалый яшәгән заманнар өчен болар яңалык һәм революцион караш булган. Халык өч гасырга якын физик һәм рухи колониаль басым астында яши. Тулаем илдә, декабристлар һәм Пугачев күтәрелешләре булып алса да, – крепостнойлык чоры. Артта калган, надан илгә буйсынып яшәгәндә яңа, хөр фикерләр тумый диярлек. Шагыйрьләр каләме язмышка сабыр итү, суфичылык идеяләрен алга сөрә. Шәкерт чагында Кандалый үзе дә үгет-нәсихәткә, вәгазьгә корылган шундый әсәрләр язгалый.

Җиһанга салмагыл мәйли[2],
Ки булгыл пакь, лөтыф зәйли[3]… (252 б.)

Мәхәббәт тематикасына шагыйрь соңрак күчә. Әдәбиятта мәхәббәт темасы моңарчы булса да, сүз Аллаһыны ярату турында бара. Чөнки татар әдәбиятына да килеп кергән суфичылык тәгълиматы[4] кешенең үзе кебек үк гади кешене сөюен түбәнлеккә төшү дип санаган.

«Габделҗаббар Кандалый татар әдәбиятына үзенең мәхәббәт тематикасы белән анда… бушлык, традиция өзелүдән туган тәҗрибәсезлек хөкем сөргән заманда килеп керде һәм бер гомер эчендә сирәк очрый торган зур казанышларга иреште», – ди академик Миркасыйм Госманов шагыйрьнең әсәрләре җыентыгына кереш сүзендә (Кандалый, 17 б.). «Кандал мулласы» гади җир кешесенә хас гадәти хис-кичерешләр хакында дөньяви, халыкчан, образлы, оригиналь итеп яза.

Кандал авылында мулла хезмәтен башкарган шагыйрь динилеге, иҗаты җитлеккән чорда, мөгаен, дини йола, гореф-гадәтләрне дә үтәргә тиеш булган. Әмма ул – шигъри, хисчән күңелле

---

[1] Барлык шигъри өзекләр «Шигырьләр һәм поэмалар»дан алынды (Кандалый Габделҗаббар. Казан, 1988).

[2] Теләгеңне.

[3] Әдәпле.

[4] Ясәви, Бакыргани, соңрак – Кол Шәриф, Мәүлә Колый һ.б. иҗаты.

җир кешесе, ир кеше. Хатын-кызның матурлыгына, күркәмлегенә мәдхия җырлый:

Нәчә мәдех әйләсәм[1] бетмәс,
Гакыл дәхи фәһем итмәс,
Кәгазьдә һәм кара йитмәс,
Язарга сурәтең, Шәфгый…
Йә оҗмах хуры идеңмү,
Булып (хур) йиргә иңдеңмү?
Вә йаки монда килдеңмү
Ирәм багындин[2], и җаный? (349–350 бб.)

«Г. Кандалый тормыштагы ямьсезлеккә каршы матурлык эталонын куйды: табигать кочагында үскән зирәк, эшчән, сәламәт җир кызын һәм лирик геройның аңа булган саф сөю хисен ачты», – диелә бу җәһәттән шагыйрь хакында (Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1985. 2 т., 198 б.).

Гади игенче кызын җәннәттәге хур кызына тиңләү – моңарчы күрелмәгән нәрсә. Зур кыюлык белән бергә бу – гуманизм, ягъни кешегә дан җырлауның югары үрнәге. Үзләренең наданлыгын, томаналыгын, рухи чикләнгәнлеген бик оста рәвештә ислам дине кануннарына буйсыну дип күрсәткән кайбер руханилар һәм клерикаль-дини кануннарга ияргән татар җәмгыяте өчен Кандалый язган нәрсәләр, әлбәттә, күк күкрәвенә тиң булгандыр. Хәер, ислам дине үзе гыйшык-мәхәббәткә гайре табигый нәрсә итеп карамый. Гаилә кору, хәләл җефеткә карата сөю хисләре, гыйшык – Аллаһы кушкан эшләр. Лирик геройны да (Кандалыйда ул һәрвакыт диярлек авторның үзе белән тәңгәл килә) мәхәббәткә илаһи көч этәрә, сөю хисен аңа ул бүләк итә:

Хак Тәгалә гашыйк кылды бәне сәңа,
Фазле берлән[3] үзе бирсен сәне бәңа… (109 б.)

Ләкин китерелгән мисаллар – Кандалый каләме өчен артык гади. Аның иҗади потенциалы, бай фантазиясе, руханилеге белән бергә кушылып, шагыйранә табышка әверелә:

Ишет хотбә гыйшыклык мөнбәрендән:
Бәйан итәм мәхәббәт гъәнбәрендән[4]. (172 б.)

---

[1] Ничә мактасам да.
[2] Ирәм бакчасы. Җирдә тиңе булмаган матур бакча.
[3] Рәхмәте белән, мәрхәмәте белән.
[4] Мәхәббәт ароматыннан.

Дин әһеле, имам икәнлеген дә онытып, Кандалый мәхәббәтенең объектына мәҗүсиләрчә табына, ягъни, диннең тар кысаларыннан бәяләгәндә, зур гөнаһ эшли.

Аллаһ әкбәр дип әгәр каксам колак,
Сурәтең күңелемә буладыр кунак!.. (358 б.)

Фәрхисорурга багышланган шул ук поэмасында:

Күз-кашыңны мәсҗедә михраб итәм,
Сурәтеңне көзгедик мәхәбб[1] итәм! – (354 б.)

ди.

Шулай да, әлеге юллар аркасында шагыйрьне денсезлектә, Аллаһыдан ваз кичүдә гаепләп булмый. Кандалый бары тик кешенең шәхси бәхеткә, мәхәббәт хисенә хакы барлыгына ишарә ясый. Хис-тойгыларны калку, эмоциональ итеп гәүдәләндерү сәләтенә өстәмә дәлил дә бу.

Габделҗаббар Кандалыйның мәхәббәт лирикасын язуда реформаторлыгы, оригинальлеге тагын бик күп нәрсәләрдә чагыла. Мәсәлән, ул хатын-кызның серле зат икәнлеген:

Күреп ирдең сәнең гөлдик йөзләреңне,
Ишетдем бал-шикәрдик сүзләреңне.
Дәхи күрдем мөбарәк буйларыңны,
Белалмадым вәләкин уйларыңны!.. (118 б.) –

дип бәян итә. Әмма бу серлелек үзенә ныграк тарта, җәлеп итә. Өнендә генә түгел, шагыйрь төнендә дә сөйгән яры турында хыяллана:

Сурәтең дөшемгә керер,
Дөшем эчрә күзем күрер:
Күз алдымда биеп йөрер,
Терәп күксен[2], идеп рәкъкас[3]. (148 б.)

Мондый чагыштырулар, шагыйранә тиңләүләр Кандалый әсәрләрендә хәтсез. Аның шигырьләрендәге «алма битле», «алтын иякле», «каләм кашлы», «энҗедәй тешле», «нәргистәй күзле», «гөл кебек йөзле», «Ак Идел камышыдай зифа буйлы» һ.б. сыйфатка ия кызларга хур кызлары да сокланулы көнләшү белән

---

[1] Күренмәс, яшерен җир.
[2] Күкрәген терәп.
[3] Биюче кебек.

карый. Бу чагыштырулар халык иҗатыннан, татар җырларыннан алынган. Алиһәгә тиң сөйгән ярга милли әдәбиятыбызда һәм фольклорда традицион булган сәба җиле (иртәнге җил) сәлам хатларын тапшыра:

Сәба илле, исәр булсаң
Парау атлыгъ нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән,
Сәхипҗамал абыстайга! (401 б.)

Иртәнге җил образы шагыйрь иҗатында аерым игътибарга лаек. Җилнең килеп исүе аңа сөйгәненең кагылуын хәтерләтә:

Ирәм багындамы үсдең?
Йөрәгем бәгърене кисдең?
Сәба йиле кебек исдең
Ки сәхраларда, чүлләрдә!.. (405 б.)

Бөтен галәмне гизгән, күпләрне очраткан җил – җансыз түгел, ул гыйшык утында янучы бәндәнең үтенеч-ялваруларын ишетергә, аңа кеше телендә җавап бирергә, гашыйкларга ярдәм итәргә дә сәләтле:

Соңра: Сәндин, дидем, баде сәба,
Тагын барсаң иде кире ул Борнай таба,
Илтимасым[1] ошбу сәба йиленә:
Бер хатым бар, илтсә Борнай иленә!.. (355 б.)

Һәм мондый образлылык, халыкчан фикер йөртү, җанлы сөйләм теленең барлык нечкәлекләрен сиземләү, шулай итеп, гап-гади сүзләр белән дә күңелнең эчке халәтен төрле яклап чагылдырыра.

Атаклы көнчыгыш әдәбиятының да, үзебезнең борынгы әдәбиятыбыз традицияләрен дә яшьтән үк укып-сеңдереп килгән шагыйрьнең асылы – чын үзебезчә, милли итеп язуда. Ләйлә – Мәҗнүн, Ширин – Фәрхад һ.б. мәхәббәт тарихларын укып, аларны үз иҗатында файдаланса да, гыйшык турында ул саф татар телендә, теләсә кайсы татар кешесенә аңлаешлы итеп яза.

И матурым, гүзәлем лә,
Ничек кенә түзәлем лә?

---

[1] Үтенеч.

Өзeлəдер үзəгем лə, –
Ишеткел бу мəкалемне[1]! (390 б.)

Гашыйк булучан хəзрəткə шактый сынаулар кичəргə туры килүе аның шигырьлəрендə ачык күренə. Шуңа да шагыйрьнең, урыны-урыны белəн, эчке хис-кичерешлəрен ачып бирүдə натурализм, эротик мотивлар кулланылуы, мавыгып, чаманы арттырып җибəрүе ризасызлык уятмый. Хəзерге заман өчен дə кыю яңгыраган шигъри юллары, əсəрнең тулы контекстында каралгач, аңлаешлы һəм бичара мəҗнүнгə карата кызгану-телəктəшлек уятырга сəлəтле:

Сагышың шул кадəр къəсдан[2],
Басып өстəн һəм астан,
Көчəйде дəрт белəн хəстəм,
Нəчə кəррə[3], нəчə катлар! (416 б.)

Кандалый иҗатында күренə: мəхəббəт адəм баласын бəхетле дə, бəхетсез дə итə, сəгадəт мизгеллəренə дə, озын-газаплы сызлануларга да сала:

Отыйм дигəндə – отылдым,
Тотыйм дигəндə – тотылдым.
Соңындин көчкə котылдым –
Ки биш елдан соң, и җанкай лə! (422 б.)

Шуны искəртеп үтик, Габделҗаббар хəзрəт катлаулы гомер юлын үтə. Рəхəтен дə, михнəтен дə мул кичергəн мулла абзый үз гомерендə берничə тапкыр өйлəнə, аерылыша да. Гөлстан, Фəрхисорур, Хəлимə, Шəфгыйҗамал, Сəхипҗамал… – шагыйрьнең күзе төшкəн һəм күңелен җилкендергəн чибəрлəр исемлеген тагын дəвам итəргə булыр иде. Гашыйк булу – хисчəн кешенең, шагыйрьнең табигый халəте, дип уйларга нигез туа. Һəм моны тормышка гашыйк булу дип тə аңларга кирəктер. Чөнки, шигырьлəрендə күренгəнчə, мəхəббəт Кандалый өчен яшəү ысулы да, иҗат дəрте дə булган. Əмма мəхəббəтне төрле яклап тасвирласа да, шагыйрь аның чишелмəс бөек сер икəнен таный, гашыйклык, сөю халəтенең табигатен аңлата алмый. Əлеге халəтне

[1] Сүземне, əйткəнемне.
[2] Эзəрлеклəүчəн.
[3] Ничə тапкыр.

гомере буена кичергән Кандалый, олыгайган көннәрендә, үзенең мәшһүр «Сәхипҗамал» поэмасында:

И белсәң ирде хикмәтне:
Гыйшыклык дәрдме, рәхмәтме?
Вә йа къәһәрме, зәхмәтме –
Салыпдырмы залял Алла[1]?!! (428 б.) –

дип язып калдырган.

Габделҗаббар Кандалыйны борчыган сорауга анык җавап бүгенгә кадәр табылганы юк әле. Бу сорау һәр заман өчен актуаль. Ләкин сәнгатьнең, иҗатның асылы, кыйммәте һәр сорауга җавап табуда түгел, ә күпчелек кешеләрне борчыган мәсьәләне күреп, тотып алуда. «Кандалыйның әдәбиятыбызда тоткан бер мөһим урыны… аның Мәхәббәт дигән гаҗәп хикмәтле, серле һәм олы күренешне әдәби фикер урталыгына төп әдәби герой сыйфатында куя һәм сoклангыч итеп гәүдәләндерә алуыннан гыйбарәт», – дип яза бу хакта Миркасыйм Госманов. (Кандалый, 48 б.) Галимнең фикере дөрес икәнлеген Кандалый әсәрләренең популярлыгы, халыкта киң таралганлыгы да исбатлый. Халык үзенең рухи дөньясына якын шагыйрьне онытмаган. Кандалыйның «бәйатлары» авылдан авылга, шәһәрләргә, өлкәләргә күчеп йөргән. Аның әсәрләрен халык үзенеке дип яттан сөйләгән, кат-кат күчереп язган, алар әле хәзер дә бәет, мөнәҗәт, җыр булып халыкта яшәп килә.

**Якутларны халкына тапшырган әдип.** Һәрбер халыкның гасырлар буе күңелләрдә саклана торган әдипләре була. Кешеләр аларның биографияләрен, кайсы гасырда яшәгәнлеген, хәтта исемнәрен онытырга, әсәрләрен хәтерләмәскә мөмкин. Әмма бу олуг әдипләр тудырган образлар, персонажлар – халык хәтерендә, биографиядәге «ак таплар» исә халык телендә, риваятьләрдә саклана, сөйләнә. Вакыт-вакыт автор биографиясеннән кайбер фактлар аның әдәби каһарманнары тормышы белән дә үрелеп китә. Мөгаен, бөек шагыйребез Габделҗаббар ибн Габделмәҗид әл Болгарины (Габделҗаббар Кандалый) (1797–1860) да шундый шәхесләр исәбенә кертергә буладыр. Чөнки «Кандалый» дигәндә күбебез мәктәп программасыннан ук таныш «Сәхипҗамал» поэмасын, шагыйрь шәхесе белән бәйле кайсыдыр такмакларны

[1] Алла бәла-каза салганмы икән?

искә төшерә. Кайберәүләр, авторы кем икәнне әйтеп бирә алмаса да, аның

Йакутлар табыладыр вакыт берлән,
Вакытлар табылмыйдыр йакут берлән[1],

дигән юлларын хәтерли. Әсәрләре халык сөйләменә якын булу сәбәпле, Габделҗаббар Кандалыйның киң әйләнешкә кереп киткән, фольклорлашкан канатлы гыйбарәләре байтак. Шагыйрьнең шигырь-поэмаларында халык иҗаты үрнәгендәге нинди генә сюжетлар, мотивлар, символлар, бизәкләү чаралары күренми! Һәм аларда татар фольклорына хас булган жанрларның (кыска мәкаль-әйтемнәр дә, «саллырак» җыр, мөнәҗәт, бәет, дастаннар) һәм хәтта сирәк кенә традицион булмаган контекстта каргыш йогынтысы да сизелә. Шунысы кызыклы, Кандалый үз әсәрләрен яшьтән үк канатлы сүзләр, әйтем-мәкальләр, афоризмнар белән бизи-дәлилли башлый. Әйтик, аның

Һәуа сахибе зурланыр,
Кәсеб итәргә хурланыр,

дигән юллары иҗатының башлангыч чорына караган «Кыйссаи-рисаләи-л-иршад» («Хак юл турында кыйсса») поэмасыннан алынды. Ислам динендә һавалану, тәкәбберләнү гөнаһ икәне барыбызга мәгълүм, һәм дини кануннарны яшьтән үк белеп, кулланып үскән 16–17 яшьлек Габделҗаббарның аларны әсәрләрендә дә гәүдәләндерүе гадәти нәрсә, шулай да аның образлылыгы, тел-бизәкләү чараларыннан мул һәм урынлы файдалануы сокландырырлык. Яшь шагыйрь талант иясе булса да, чын осталык тәҗрибә белән килә икән. Аның игенче хезмәте турында әйтелгән

Иген икмәк – михән чикмәк,

дигән сүзләрен, гадел һәм дөреслеккә туры килерлек булса да, халык күтәреп алган һәм үзенчә «төзәткән»:

Иген икмәк бирер икмәк,
Белеп иксәң, бирер күпләп.

Нәтиҗәдә, шагыйрь сүзләренә аваздаш мәкаль барлыкка килгән. Әйе, үз халкың, аның күңел дөньясы, иҗаты, әхлагын якын

[1] Шагыйрь әсәреннән китерелгән цитаталар, орфографиясе үзгәртелмичә, түбәндәге басмадагыча бирелә: Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан, 1988.

итсәң, аны үстерүгә өлеш кертсәң, бу эшең җавапсыз-рәхмәтсез калмый, халкың да сине ишетә-белә, үстерә икән. Моны Габделҗаббар Кандалыйныкы гына түгел, ә халкы белән бер тында сулап, бер төрле уйлап, бер төрле иҗат иткән барлык әдипләрнең иҗаты раслый. Башлангыч чорында ук халкы белән уртак бер фикри, хисси дулкында тирбәлгән шагыйрь иҗади гомере дәвамында үзенең татарына тагын да якыная. Аның каләме «кагылганнан» соң, халык җәүһәрләре тагын да тирәнәеп, камилләшеп, матураеп балкый башлый.

Агач башындагы кошны
Минеке дип әйтеп булмас,
Очып китсә япан җирдән –
Тотыйм дисәң, тотып булмас.

Шагыйрь каләменнән тамган юлларда китаби гомумиләштерү, фәлсәфә дә, авыл кешесенең зирәклеген чагылдырган гади, тормышчан гыйбарәләр дә күпләп очрый.

Туганлык кадрене белсә – туган ул,
Әгәр белмәсә – бер ачы суган ул! –

дигән күзәтүе белән уртаклаша Габделҗаббар хәзрәт. Хәзерге вакытта шуңа аваздаш «Туган туганга – ачы суган» әйтеме әдәби телдә еш кулланылмый, әмма Себер татарлары сөйләмендә ул әле дә актив әйләнештә. Халык мәкальләре шагыйрь әсәрләре исәбенә баегандырмы, әллә киресенчә, шагыйрь үз шигырь-поэмаларына афористик бизәкләрне фольклордан алганмы – моны ачыклавы хәзер инде кыен. Шулай да, Габделҗаббар Кандалый иҗатын өйрәнүгә гомеренең чиреген багышлаган галимебез Миркасыйм Госманов әйткәнчә, шагыйрь әсәрләренең кульязмалары хәтта Урал арты татар авылларында табылган. Баегандыр, сибелеп яшәгән халкыбыз да һичшиксез баеган, илһамланган Кандалый иҗатыннан.

Шагыйрьнең әсәрләрендә чәчелгән энҗеләрдәй һәрдаим ялтырап яткан *«Тавык төштә тары күрә»; «Сәнеңтик сайлаган сазга тарый ла»; «Оялган кемсәнең ризкы тар булыр»; «Салкын сүз – җангадыр агу»* (варианты – *«Надан ир җангадыр агу»*); *«Ки тәкъдир булмагай тәдбил» («Тәкъдирне үзгәртеп булмый»)* һ.б. ише канатлы сүзләр, әйтем-мәкальләрнең фольклорда мәгълүм, киң таралган аналоглары, чыганаклары бар. Кандалый гыйбарәләренең бүтәннәре, «танып булмый торганнары», бе-

ренче карашка, афористик жанрның билгеле үрнәкләренә бәйле түгел, әмма әсәрдә алар аргумент, берәр фикернең матур да, кыска һәм оста дәлиле буларак хезмәт итә. Мәсәлән: *«Агач шартласа, аны сынды дип бел, // Хилаф сүз булса, адәм үлде дип бел»; «Җәмаль дәхи китә торган буяутик, // Китәр тиздән кояш төшкәч кыраутик»; «Кеше үзенә гәр салса бәла, // Җиһан халкы җыелса, белмәс ала».*

Шагыйрьнең тормышчан зирәклеге, сүз көченә карата үзенчәлекле хисси сизгерлеге кайдан килә? Татарлар өчен бик гадәти булган борынгы шәрекъ-мөселман әдәбияты да, буыннан буынга күчкән укымышлылык та (Габделҗаббарның атасы да, берничә буын бабалары да муллалык, имамлык иткән), крәстиян тормышының авырлыгына бирешмәгән, хөр күңелле мишәр-авылдашлары белән аралашу да, көндәлек хезмәт тә (кайбер шигырь һәм поэмаларында «кара мажик»тан көлебрәк язса да, чынлыкта хәзрәт үзе дә гади эштән йөз чөермәгән) тәэсир иткәндер. Табигый күзәтүчәнлек, халык сүзенең аһәңен ишетә белү сәләте, осталыгы – җыеп әйткәндә, сәләт, Аллаһ тарафыннан бирелгән сәләт исә – беренче чиратта.

Кандалыйның белем, мәгърифәт, гыйлемлелек турындагы афоризм-гыйбарәләре гаять күп. Мисал өчен берничәсен генә күрсәтеп китик: *«Галим булса, булыр дәүләт»; «Тутый белән ки карганы // Килтереп бер ивгә япма»; «Ки козгындин туар козгын, // Ки каргадан туар карга»; «Надан сүзләр сүзен тапмас, // Ки яхшыга сүзен тапмас»; «Надан аякыны йөртер, // Ки баскан йирләрен кортыр»* һ.б. Алар авторны җитлеккән фикерле, яшәеш фәлсәфәсен аңлауга ирешкән, олы тормыш тәҗрибәсенә шагыйрь буларак күрсәтә. Шагыйрь традицион Ислам кыйммәтләрен кадерләп гомер иткән газиз халкыннан аерым яшәмәгән, ә шул халыкның бер өлеше, баласы булган. Димәк ки, аның афоризмнар иҗат итүдәге үзенчәлеге, индивидуализмы бер дә очраклы хәл түгел, бу – талантлы шагыйрь үз әсәрләрендә халкыбызның күңел байлыгын, рухи идеалларын чагылдыра, дигәнне аңлата.

Габделҗаббар хәзрәт мирасының безгә, балкыган якутларына тиң афористик жанр үрнәкләре арасында тагын бер категория очрый. Бусы – кыскарак, ләкин тыгыз, тирән мәгънәле гыйбарәләр – канатлы сүзләр, әйтемнәр. Әлбәттә, боларын да «мәкаль һәм әйтем» дип гомумиләштереп карарга була, шулай да Кандалый афоризмнарының бик күп санда һәм бик күп төрдә булуы аларны жанрлар буенча төгәл, конкрет бүлеп карарга

мөмкинлек бирә. Дөресрәге, сүз монда Кандалый тарафыннан иҗади эшкәртелгән халык әйтемнәрен бер төркемгә берләштерү турында бара. Төрле вариацияләрдә, төрле очракларда аларның күбесе әле хәзер дә сөйләм телендә дә, язмада да очрый. Шагыйрь каләменә хас кайбер мисалларны китерү урынлы булыр:

Гомер – сәгатьтик.
Гыйшыкка дәва юк диләр зирәкләр.
Сүзе ялган кешене диләр угры.
Каралык къәлбене баскан.
Ачылыр сер берлә мәгънә,
Булыр язган кеби ташка һ.б.

Кандалый иҗатына берничек тә берьяклы гына килерлек түгел, ләкин шунысы бәхәссез: бу шагыйрь иҗатын һич кенә дә стандартларга туры китереп, кабул ителгән кысаларга сыйдырып булмый, өстәвенә, шигърияткә керткән яңалыгы да күпкырлы. Мисал өчен, үсеш алган әдәбиятта сирәк очрый торган бер жанр бар: каргыш. Габделҗаббар шагыйрь иҗатында бу жанр шактый урын били. Кайвакыт шаярып, кайчакта җитдилек саклап та, артык хискә яисә төшенкелеккә бирелеп, лирик герой үзен тыңламаган, гыйшкын кабул итмәгән кызга каргышын яудыра.

Әгәр сән чәнди мәне мәхрүм итәрсән,
Күрәек, нинди егеткә китәрсән!
Мәхәббәт булмасын барган йиреңдә,
Сафалар сөрмә һич барган йиреңдә.

Шагыйрь әсәрләрендә очрый торган каргышларны афористик жанр үрнәкләре белән бер рәттән карауның сәбәбе бар. Таныргa мәҗбүрбез: субъектив, негатив мәгънәгә ия, кирәгеннән артык хисле булсалар да, бу үзенчәлекле гыйбарәләр оста, җор, шул ук вакытта аларда үгет-нәсыйхәт тулып ята. Кандалый шигырьләрендәге каргыш – психологик һәм бик тә шәхси, эчке хисләргә корылган күренеш. Аның буенча без авторның эмоциональ-психологик халәте, шәхси драмасының тирәнлеге хакында фикер йөртә алабыз. Өстән-өстән караганда гына каргыш лирик геройның сөйгәненә юнәлтелә. Мөселман халыклары гомумән традицион рәвештә саксыз әйтелгән тискәре мәгънәле сүзләр белән сак эш итәргә гадәтләнгән: каргыш каргалган кешегә дә, каргаучыга да төшә. Моны белгәнгә күрә, лирик герой да әйткәненә шундук үкенә:

Бәдига, рәнҗемә: каргадым уйнап,
Хатереӊ калмасын фикри уйлап.

Шулай да чынбарлык тормышта кеше хаталардан хали түгел, ул ялгыша. Әдәбият исә (фольклор – аеруча) тормышны идеальләштереп, ә кешене гөнаһсыз зат итеп күрсәтергә бурычлы түгел. Исемнәре татар әдәбиятында үзеннән алда уелып калган шәхесләрнеӊ күбесеннән аермалы буларак, Кандалый кешене ничек бар, шулай итеп, аныӊ барлык җитешсез якларын ачып тасвирлый. Шагыйрь иҗатында очрый торган каргыш мисаллары – укучыга гыйбрәт булырлык. Фольклордан бер мисал:

Җаныкаем куйган ак самовар,
Кайнап чыгар микән күмерсез?
Мине ташлап ятны сөйсәӊ,
Сөйгән ярыӊ булсын гомерсез[1].

Фольклор әсәрләре яисә Кандалый шигырьләре геройларын тар күӊелле, явыз ниятле булуда гаепли алабызмы икән? Мөгаен, юктыр. Тарихтан, дөнья әдәбияты һәм фольклордан мәгълүм: бәхетсез гашыйклар, чарасызлыктан һәм хисләр ташкынына буйсынып, аффект халәтендә теләсә нинди эш-гамәлләр, хәтта акылсызлык кылырга да сәләтле. Дөнья фольклорында һәм әдәбиятында моӊа мисалларны күпләп табарга мөмкин: Зөләйханыӊ Йосыфка яла ягуы, сөйгәнен көнләүдән шашар дәрәҗәгә җиткән Отелло һ.б. Гашыйкларныӊ аянычлы хәлләре турындагы әсәрләр шулай ук татар фольклорында, бигрәк тә бәетләрдә шактый.

Каргышлар мисалында шунысын төгәл әйтә алабыз: шагыйрь Кандалый дөньяны үзе күргән-белгәнчә сурәтли – каргыш жанры аныӊ иҗатында берничек тә очраклы рәвештә, тиктомалдан гына барлыкка килмәгән. Татар халык иҗатында да, көнкүрешендә дә каргышлар, һич хупланмаса да (моны мәшһүр «Сак-Сок» бәете гаҗәеп образлы, үтемле итеп раслый), бу фактны танырга кирәк. Иҗатчы, сүз рәссамы буларак, Г. Кандалый халык яшәеше, аныӊ көнкүреше традицияләреннән, әлбәттә, ваз кичми, киресенчә, күпгасырлык тел байлыгыннан файдалана, шул ук вакытта чын реалистларча үз мохитен, тирәлеген әсәрләрендә чагылдыра.

---

[1] Кемдә моӊ бар, кемдә хис бар // Татар халык җырлары. Казан, 2001. Б. 106.

Габделҗаббар Кандалый, җор телле халкы кебек үк, сүзнең барлык төсмерләрен, нечкәлекләрен белгән, шулар ярдәмендә үз туган телендә дан җырларга да, хурларга да хәленнән килгән аның. Шигъриятенең барлык жанр, тематик, стиль үзенчәлекләре халык иҗатының күп гасырлык традицияләренә нигезләнгән. Шагыйрь, туган халкы сыман ук, әлеге традицияләрне, тел бизәкләрен – афоризмнарны, мәкаль-әйтемнәрне ана сөте белән үзләштергән һәм, тагын да мул, җете төсләргә манып, газиз халкына кайтарган.

**Интервью. Мәхәббәтне салды миңа ходаем… (Мәҗнүн мулла белән сохбәт).** Мәхәббәт санында без бик үк гадәти булмаган, гаять кызыклы шәхес, олуг шагыйрь, дин әһеле һәм гыйлем иясе белән гадәти булмаган әңгәмә оештырырга булдык.

Әңгәмәдәшебез – исеме – Габделҗаббар ибн Габделмәҗид ибн Ибнейәмин, ягъни Габделҗаббар Кандалый. Ул 1797 елда хәзерге Ульян өлкәсенең Иске Майна районы Иртуган авылында Габделмәҗит мулла гаиләсендә туган.

– Габделҗаббар хәзрәт!..

– Әйа гөнаһе шомлыклары! Каюсы нәгяһ бәне кубарып, ләзиз ойкыдин уятып, газиз рух-шәрифләремне борчырга җөрьәт итә?

– Габделҗаббар әфәнде, бимазалавым өчен гафу үтенәм. Сезнең белән бик сөйләшәсе килгән иде. Тик, зинһар өчен, хәзерге заман татар әдәби телендә сөйләшикче! Сезнең замандагы сүзләр кулланылмый бүген, һәм сез сөйләгәннәрне сүзлекләр белән тәрҗемә итеп утыру кыен булачак… Ярый ла Сез үзебезнең телдән башка тагын гарәп, фарсы, борынгы төрки язма телләрен белгәнсез, урысча, чуашча, мукшыча аңлашкансыз. Безнең галимнәр буенча – полиглот! Ә безнең күбебезнең бөтен чит тел хәзинәбез шул бер урыс теле инде.

– Әйа җаный, үтенүеңә күнәмен. Вәләкин «…глот» дәюеңә разый түгелмен. Бән – мәхдүм, гыйлемлелек, күп тел белү безләргә ата-бабайдан калган мирас. Вә дәхи минем кебек авыл агаен «әфәнде» дип тә «сез» дип тә хурламасән – Солтан илендәгеләргә ияру безгә төс түгел лә. Сән буны әйткел, дөхтәр, җәсәде дә калмаган шагыйрьнең рухын кузгату нигә кирәк булды?

– Мәхәббәт хакында күп нәрсәләр әйтә алыр идең төсле, Габделҗаббар абзый. Дөрес, гыйшыклык турында сиңа кадәр дә, синнән соң да язганнар. Хәзер дә иҗат итәләр. Ләкин шигырьдә – шигъри образлар, әдәби алымнар ярдәмендә лирик герой-

ның хис-кичерешләре генә. Ә шагыйрь шәхесе, аның үз фикерләре, минемчә, күпкә кызыклырак.

Шагыйрь хәзрәтнең тавышы ничектер уйчанрак яңгырады.

– Шагыйрь шәхесе – аның шигырьләрендә. Кяшки (әгәр дә) мин гыйшык утында янмасам, ошбу шигырьләрне яза алган булыр идемме?! Мәхәббәттән зиһенемне югалтмасам, мәгъшук атын күтәрер идемме?! Укысаң, хәтерлисеңдер:

Бу гыйшыклык чабы китде
Уфа, Казан да Сенбергә,
Бу гыйшыклык яманатын
Күтәрдең сән дәхи бергә.

Бу гыйшыклык чабы алды
Әгәр ике Чирмешән буен;
«Сәхипҗамал»ны укырлар, –
Йөзен, күркәм төсен, буен.

– Әйе, хәзрәт, укыйбыз. Кайбер шигырьләрең безнең заман өчен дә бик кыю яңгырый. Ул вакытта бит әле татар феодализм чорын кичергән… Ә син, авыл мулласы, имам башың белән шундый итеп язгансың:

Көн дә сагыш, төн дә сагышың тотып,
Бинамазым, бинийазым[1] ут йотып,
Аллаһ әкбәр дип әгәр каксам колак,
Сурәтең күңлемә уладыр кунак!..

Сөю шәрабен эчеп диненнән язган, Аллаһыга ширек кылган кешенеке дип аңларгамы бу юлларны?

– Әйа җаным, кем, туташым, бәндәләр генә беркемгә дә бернинди ат ябыштыра алмас. Кеше күңелен беркем дә белмәс, фәкать Раббымыз гына белер. Вә гыйшык хәлләренә дә инсанны Аллаһы сөбханә вә тәгалә сала:

Мәхәббәтне сәңа салды Ходаем.
Моны язмай ни халь түзәем?

Аның язмышыннан узмак булмас. Вә дәхи иҗад дәрден дә ул сала бәндәгә. Безнеңдәй гади җир бәндәләренә болар – гаять зур йөк, җаваплылык. Гыйшык вә иҗад дәрден күтәргән бәгъзеләрне Ходай икеләтә сыный. Вәләкин барлык адәмнәр дә

[1] Намазсыз, догасыз.

ошбу сынауларга түзә алмас, шайтан коткысына бирелер, адашыр. Бәндәчелек белән кыйлган хата вә кимчелекләр Раббыма мәгълүмдер. Әмма үземне җиһанга кеше итеп яралткан, сәгадәт мизгелләрен насыйб әйләгән илаһыма берәүне дә тиңләштермәдем. Мәгәр хатын-кызның гүзәллегенә, бәхет-сәгадәткә мәдхия җырладым. Надан, фәсыйк ирсәләр үрнәгенә иярмәдем: гүзәл затларны «ирләрне аздыручы» итеп тә, «чәче озын, акылы кыска» итеп тә кимсетмәдем. Йә, әйт, мин яшәгән заманда кайсы мелла хатын-кыз турында:

Сагынамын көндезләрдә,
Дога кыйламын кичләрдә,
Оныта алмыйм һичләр дә, –
Сабыр телим бер Алладан –

дияргә җөрьәт иткән?! Яки:

Гыйшкың миндә булмаз ирсә, и никяр,
Бу хатымны кайтарырсың би-зарар, –

дип, сайлау мөмкинлеген сөйгәненең үз иркенә калдырган?

– Ай-һай, мулла абзый!

Әгәр барсаң бәне ташлап сән ятларга,
Башың төшсен сәнең яманатларга… –

дип билгеләгән «ирек»кә кем генә шатланыр икән? Бусы бер хәл. Мин кызык өчен генә әсәрләреңдә күренгән исемнәр: Гөлстан, Фатыйма, Әминә, Фәрхиҗамал, Бәгыйдә, Бәдиганы… саный башлаган идем дә, билләһи, очына чыга алмадым!

– Әйа җаный, фикер тарлыгы замана балаларын бер дә бизәми! Әлхамделиллаһи шөкер, безләр күңел күзеннән дә, маңгай күзеннән дә мәхрүм калмаганбыз. Гүзәл табигатьле, күркәм җәмальле вә буй-сынлы, акыллы вә уңган, булдыклы татар кызларына күз вә күңел төшмәсен өчен анфалит, ягъни, сезнеңчә, инвалид булу кирәк лә! Хыял дәрьясына чумып, дөньядагы хур кызлары турында фәһем кылуның ни ояты бар?

Ә зәүҗәләрем турында сорама сән, туташым. Әллә ничә кәррә никахлап өйләндем, шуннан артыгын сөйләү – сәңа кирәкмәс, ә миңа – рәхәт булмас.

Гыйшыклык хәле адәмнәрнең бәхете дә, бәхетсезлеге дә. Бәхет исә – бер мизгел… Мәхәббәт хисе ләззәттер, ләкин көнләшү – уттан яман. Йә, әйткел: илле дүрт яшьлек картлачның күңе-

ле талчыбыктай сылу, фәрештәдәй гөнаһсыз кыз балага төшсә, ни була? Минекедәй аяныч хәлләр була, җаным! Сәхипҗамал бәгырькәйне яучылаган егетләр генә түгел, ә үтеп барганда Сәхибләр ызбасына таба ялгыш кына күз төшергәннәр дә «чабаталы, нәҗес мажик» була…Бигрәк тә, ул «надан», «бирән», «хәсис» – яшь һәм гайрәте ташып торган чибәр, егет солтаны булса, әлифне таяк дип тә белсә…

Артыгын төпченүем өчен уңайсызланып та куйдым, билгеле. Кем уйлаган бит аны... Шулай да, форсаттан файдаланып күптәннән телемне кычыттырып йөргән сорауны бирергә батырчылык иттем:

– Хәзрәт, лирик әсәрләреңдә мөселман – көнчыгыш әдәбияты эзләре дә, Кол Гали һәм Утыз-Имәниләр һ.б. тәэсире дә шәйләнә…

– Кол Гали кебек әдипләрнең иҗады – маяк инде ул, күктәге кояш. Аңа иярә алганмын икән – бу олуг бәхетемдер. Нәзымнәренең имля вә иншасы гаҗәеп дәрәҗәдә камил, шагыйранә төзелгән мондый борынгы шагыйребез – Аллаһының бүләге. Аныкы тик әбйатлар язып, беренчедән, игътибарны борынгы шагыйрьгә юнәлтсәм, икенчедән, үзем дә аңардан өйрәнмәкне эстәдем. Белеп торыгыз, замана балалары, әдәбиятыбыз җилдән тумаган, остазларыбыз – олуг затлар!

– Килешәм, классиклар шәп безнең. Алар арасында синең үз урының бар. Ә хәзерге заман шигърияте хакында ни уйлыйсың? Киштәләрдәге калын-калын томнарны әйтмим әле, мәсәлән, вакытлы матбугатта да көн саен дистәләгән шигырьләр чыга бит…

– Сезнең «вакытлы» дигән матбугатыгыз монда килеп җитми шул, йөрәккенәем. Гәрчә килгән хәлдә дә урыс хәрефе белән язылган татар шигырен укып булмас ла.

– Һи, алайга китсә, ул матбугатны мондагылар да, тиражга караганда, укып йөдәмидер, ахры. Әмма сүзебез бит бүтән нәрсә турында. Мин рух белән рухның аралашуы, җан белән җан бәйләнешен күз алдымда тоткан идем. Чөнки шигърият ул – рухи дөнья, җаннар бәйләнешы, реаль түгел, идеаль нәрсә.

– Минем рухыма Габдулла мелла, Габденнасыйр, Габдерәхим, Габделкаюм хәзрәтләренең рухлары якын. Ошбу бөек затлар, күңелләренә Җәнабел хак иңдергән шагыйранә нурны, сәләт оеткысын үстереп, түкми-чәчми әлеге нигъмәтне халкына да тараткан. Алар, әлбиттә, барысы да мулла малайлары (бән фәкыйреңез

кебек үк), әмма кайсысы, хәзерге шикелле, «югары» белем алган? Безләргә дарелфөнүннәр бетерү насыйб булмады! Мәсәлән, Габдулла мелла ялангач, ач, чирле ятим булса да, тук, күзләрен май баскан кемсәләрдән мәгърифәтлерәк улмыш! Әсәрләренә өстәп, кирәк, халык иҗады, кирәк, милли моңнарыбыз, кирәк, әдәбият бәяныннан сәгатьләп вәгазь (сезнеңчә, лекция була инде) укыды. Габделкаюм хәзрәтләренә дә хөрмәтем иксез-чиксез. Шигъриятне, назик вә нәзъме хисләрне дә аңлады, дистәләгән төрле фәннәрдән гыйльми хезмәтләр дә язып калдырды. Әйа җаный, сезнең хәзер «әдип», «шагыйрь» дип атаганнарыгыз мажиклыктан чыкмаган. Ходай биргән сәләтләрен, үз акыллары белән ирешкән нәрсәдәй күреп, кирәкмәгәнгә исраф итеп бетерәләр. Мескеннәр алар: дөньяга карашлары тар, күңел күзләре сукыр. Бар гыйлемнәре ритм-рифмадан артмаган шыр надан башлары белән үзләрен даһига санлап йөриләр. Хәмергә, хәрәмгә табыналар! Ә үзләре, халыкка әдәбият, ягъни әдәплелекне таратучылар чабын күтәргән. Вә дәхи шул, җимешем, бигайбә! Сән сорадың – бән әйттем.

Хәзрәтне болай ук ут чәчәр дип фаразламаган идем. Әмма сөхбәтебезне дәвам иттерәсе иде.

– Габделҗаббар хәзрәт, кайберәүләрнең синең шигырьләреңдә бозыклык, порнография эзләүләренә ничек карыйсың? Бигрәк тә

Чү абзый, чүсәнә,
Кысыбрак яхшы сөйсәнә,
Сөйгәчтин күңелем үсә лә, –
Дәйүб уйный күшки кызлар –

ише юлларны мисал итеп күрсәтергә ярата андыйлар.

– Әйа акыллым, андыйларга исем китәр вакытлар күптән узган, куркыр ыштаннарым тузган! Мәет түгел, тере чагымда да хыялсыз, фикерсез, наданнар вә тар кысаларга берегеп ятучыларга исем китмәде. Син шуны уйла: «авыр холыклы», «туры сүзле», «төртке сүзле» дигән даным таралса да, «акылга җиңел мулла», «бозык имам» дигән сүз чыкканы юк минем турыда. Димәк ки, болай язуым замандашларыма гайре табигый булып күренмәгәндер? Әгәр бән язып калдырмаган булсам, ике йөз еллар элек татар авылларындагы кешеләрнең уйларын, күзаллауларын, шаянлыгын сезләр ничек төшенер идегез? Бәндәләр табигатенә салынган күркәм һәм бик үк күркәм булмаган сыйфат-

ларны көзгедәгедәй ачык итеп кайда күрер идегез? Хатын-кыз, кәкре сөякнең, безнең заманнарда да чытлык, юха була алуына кинаяне кайдан алыр идегез?

Шунысын да колагыңа киртлә: үзе бозык кеше генә һәр тарафта бозыклык күрәдер. Вәләкин, бакчама теләсә нинди таш атсалар да, бәне ихлассызлыкта, ялган язуда, монафикълыкта гаепли алмаслар.

– Аңладым, Габделҗаббар хәзрәт. Ә кайсы әсәреңне иҗатыңның иң югары ноктасы дип бәяләр идең икән?

– Иллә дә хәйләкәр итеп куйдың соравыңны! Мин бит бәяләүче түгел, язгучы гына. Әбйатларым халкыма таралды, сезләргә дә барып ирешкән икән. Шигырьләремне күчереп яздылар, мөнәҗәт итеп көйләделәр, китап итеп чыгардылар – мин, бер гашыйк мәҗнүн бу турыда хыяллана да алмаган идем. Шигырь язу җаныма шифа бирде, дисәм дә һич ялган булмас. Гәрчә бәгырь итемне телеп, йөрәгемне тураклап торган дәрдемә, бәргәләнгән җаныма урын таба алмаганлыктан иҗад иткәнем, әлбиттә, «Сәхипҗамал» дигәне булды. Әрнү, авырту, гыйшкым хисенең ташкыны андагысыннан көчле бүтән берәвендә дә түгелдер лә.

– Эчкерсез әңгәмәбез өчен рәхмәт, Габделҗаббар хәзрәт. Рухың шат, җаның тыныч булсын. Халкыбыз күңелендә мәңге яшә!

– Әйа дөхтәр, теләкләреңә бик тә күңелем булды! Җисемсез әрвахларны да, тере инсаннарны да Раббымыз мәрхәмәтшәфкатеннән ташламасын. Дөньялыкта белеп вә белмичә кыйлган хаталарыбызны кичерсен иде.

Шагыйрь хәзрәтнең тавышы әкренәйгәннән-әкренәя барып, бөтенләй ишетелмәс булды…

* * *

Борынгы татар шагыйре белән әңгәмә кору, билгеле, хыялда гына мөмкин. Кешеләргә хыял байлыгын биргән затка мең-мең шөкер!

Габделҗаббар Кандалый шигырьләрен укыгач, шагыйрь шәхесе турында да беләсе килә, бик килә. Әмма аның турында, дөреслеккә караганда, уйдырма һәм легендалар күбрәк сакланып калган бугай. Шагыйрьнең шәхесен – үзеңә, фәкать әсәрләрен укып кына ачарга кала. Һәм аны һәркем үзенчә күреп, үзенчә ача. Кандалый да, башка бөекләр дә, халкыбызныкы булу белән бергә, һәркемнең үзенеке генә…

# ЯКТАШ ЯЗУЧЫ ИҖАТЫН МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ

*Ч. Шиһапова*

Туган җир. Туган туфрак. Туган төбәк. Ул һәркем йөрәгендә яши һәм вакытлар үтү белән әлеге төшенчә тагын да зур мәгънәгә ия була. Туган якның бай тарихы һәм мәдәнияте, табигате – болар барысы да кече яшьтән үк тормышыбызның бер кисәгенә әверелә, шуңа күрә туган як әдипләре әсәрләрен өйрәнү – мәктәптә укыту һәм тәрбия эшен камилләштерүдә әһәмиятле чара. Ул укучыларның әдәбият белән кызыксынуын үстерә, әдәби карашын киңәйтә, китап белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен баета, балаларны фәнни-тикшеренү, эзләнү эшенә тарта.

Безнең данлы туган ягыбызда дөньяга килгән, үскән, яшәгән якташыбыз Габделҗаббар Кандалый иҗатын өйрәнү аерым бер урын алып тора. Шагыйрь Габделҗаббар Кандалый иҗатының бер өлеше киң җәмәгатьчелеккә күптәннән мәгълүм инде. Шул мәгълүм өлештән генә чыгып та, шагыйрьнең язу осталыгына сокланып, аның әдәбият үсешенә керткән бәхәссез яңалыгын ихлас күңелдән тәкъдир итә килделәр. Габделҗаббар Кандалый мирасының дөньяга чыгу һәм галимнәр игътибарын җәлеп итә башлау факты XIX йөзнең урталарына туры килә. Галимнәрнең, әдәбиятчыларның күмәк тырышлыклары нәтиҗәсендә, иң мөһиме – Кандалыйның үз мирасы киң таралуы аркасында, шагыйрь хакындагы бүгенге белемебез элгәреге белән чагыштырганда күпкә төгәлләнә, байый төшә. Язучыбызны сокландырган туган табигать, аның кешеләре, тормыш-көнкүреш йолалары әсәрләренә күчәләр, тылсымлы сүз остасының каләм көче белән гади тормыш картиналарына әвереләләр.

Дәресләребездә якташ язучыбыз – Г. Кандалыйның әдәбиятын өйрәнгәндә җирле чыганакларга нигезләнеп хәзерләнгән күрсәтмә әсбаплар киң һәм урынлы файдаланыла, бу исә дәресләрдә өйрәнелә торган материалны укучыларга җиңелрәк үзләштерер өчен уңайрак шартлар тудыра. Түбәндә саналганнарны күрсәтмә әсбап итеп файдалану материалны истә калдыру өчен яхшы җирлек булып тора: Г. Кандалыйның портреты, аның шәҗәрәсе; тормыш-көнкүреш, тарихи һәм әдәби яктан истәлекле урыннар; китап нөсхәләре һәм тышлыкларының фотокопияләре; язучыларның туган як буйлап кылган сәяхәт схемалары, әдәби

туган якны өйрәнү карталары һ.б. Туган якны өйрәнүнең үзенә генә хас үзенчәлекләре дә бар. Алар барлык укучылар өчен дә мәҗбүри була алмыйлар.

Г. Кандалый әсәрләрен укып, без аның киң карашлы, туры сүзле, кыю булганын, тормышны, әдәбиятны яхшы белгәнен күрәбез. Ул шигырьләр һәм поэмалар иҗат иткән. Әсәрләре телдән-телгә, кулдан кулга күчкән. Шагыйрьнең шигырь һәм поэмаларын укып, без ул яшәгән чорны, мохитне күз алдына китерәбез. Бу әсәрләрнең түрендә кешеләрнең уйланулары, тирән кичерешләре ята. Кешелек дөньясының төп юлдашы, асыл сыйфатлары булып мәхәббәт санала, шуңа да ул элек-электән бик күп әсәрләрдә, шигырьләрдә урын алган, бик күп җырларда җырланган. Г. Кандалыйның бик күп шигырьләре һәм поэмалары мәхәббәт хакында – гашыйкларның рухи халәтен, сөйгән ярларының гүзәллеген, тирән мәхәббәт хисләрен тасвирлый.

Бу очракта укучыларның кызыксынуы һәм мавыгуы исәпкә алына. Мәсәлән, дәрестә үтелә торган язучының туган як белән ничек бәйләнгәнен өйрәнү һәр укучыдан таләп ителми. Күбрәк әдәби туган якны өйрәнергә теләүчеләр белән эш ителә. Без бу эшне яратып башкарабыз һәм укытучы ярдәмендә кызыклы чыгышлар хәзерлибез. Дәрестә генә җитешмәсәк, әдәби туган якны өйрәнү буенча уздырылган класстан тыш эшләр дә ярдәмгә килә. Гадәттә бездә ул болай оештырыла: әдәбият дәресләрендә Г. Кандалый иҗаты турында кыскача өйрәнәбез, ә түгәрәк утырышлары, китап укучылар конференцияләре һәм әңгәмәләр вакытында без язучы турындагы мәгълүматларны тирәнәйтәбез, укылган әсәрләре турында үз фикерләребезне әйтергә өйрәнәбез.

Дәресләр һәм класстан тыш эшләр уздырганда файдалану өчен идея-художество ягыннан тирән эчтәлекле, яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә әһәмиятле булган җирле әдәби фактлар гына сайлап алына. Укыту-тәрбия процессында фәнни яктан рәсми рәвештә расланган материаллар кулланыла. Җирле материаллардан файдаланганда: язучы яшәгән һәм иҗат иткән чорны, мохитны, тормыш-көнкүреш шартларын өйрәнәләр; укучылар әдәби геройларның прототиплары, сюжетның тормыш нигезләре белән таныштырыла. Г. Кандалый иҗаты буенча чаралар оештырганда, тарих, география укытучылары белән хезмәттәшлек эше алып барыла. Якташ язучыларыбыз иҗатын өйрәнү шуны күрсәтә: укучылар туган як тормышын чагылдырган әсәрләрне

бик теләп, яратып укыйлар. Алар, беренче чиратта, язучының сайланма әсәрләренә мөрәҗәгать итәләр, язган әсәрләрен кызыксыну белән укыйлар.

Якташ язучыбыз Г. Кандалыйның иҗаты яшь буынны тәрбияләүдә роле зур. Матур әдәбият үрнәкләре аша туган җиребезне тагы да яратырга, аның башка төбәкләрдән аермалы булган үзенчәлекле якларын ачарга ярдәм итә, туып-үскән җир турында, аның мәдәнияте, тарихы буенча күп мәгълүматлар бирә.

## МӘГЪРИФӘТЧЕ ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙ МИРАСЫН МӘКТӘПТӘ ҮЗЛӘШТЕРҮ

*М.Г. Мозаффарова*

Матур әдәбият яшь буынның кеше һәм милләт вәкиле буларак формалашуында хәлиткеч рольләрнең берсен башкаручы кодрәтле көч.

Балада әдәбиятны, милли гореф-гадәтләрне өйрәнүгә ихтыяҗ уяту гына түгел, ә әдәбиятыбызны, мәдәниятебезне белүче һәм киләчәктә аның үсешенә үз өлешен кертергә сәләтле укучылар үстерү зарур. Бу – милләтебез заказы.

Тел, гореф-гадәтләр, әдәбият, мәдәният һәм милләтеңнең затлы шәхесләре кебек кыйммәтләрне белү, шәхесне абруйлы иткән һәм исемен мәңгеләштергән гамәлләрнең асылын ачыклау, танып-белү ысулы белән коралландыру – заман таләбе, педагогик олы бурыч.

Татар халкының затлы улларының берсе Габделҗаббар Кандалыйның тормышы һәм иҗаты гомуми белем бирү оешмаларында ничек өйрәнелә ала соң?

Әлеге мәкаләнең максаты: әдәбият галиме, укыту-методик комплектлар авторы Альберт Яхин программасында Габделҗаббар Кандалый иҗатын өйрәнү үзенчәлеген ассызыклау.

Габделҗаббар Кандалый – Каюм Насыйри, Муса Акъегет, Гали Чокрый, Акмулла янәшәсендә XIX гасыр татар әдәби мирасын тәшкил итүче мәгърифәтче әдибебез. Габделҗаббар Кандалыйның мәгърифәтчелек идеясе, иҗатының үзенчәлеге «Мулла белән абыстай» шигыре һәм «Сәхипҗамалга» поэмасы нигезендә үзләштерелә. Әлеге әсәрләрне укып чыгу белән

мөһим үзенчәлек ачыклана: әдип халыкның сөйләм телендә иҗат иткән. Сер түгел, ул чорда әдипләр, нигездә, гарәп, фарсы сүзләрен катнаштырып язганнар. Бу укымышлылык күрсәткече булып исәпләнгән. Гарәп-фарсыны Г. Кандалый да яхшы белгән, әмма беренче чиратта укучысы турында кайгырткан, күрәсең. Гади кеше аңларлык телдә язган.

«Мулла белән абыстай» шигырендә әдип ирония алымын уңышлы куллана (*ирония – начарлыкның әһәмиятсез генә бер уңай ягын табып, шуның аша бөтен начарлыкны яхшы дип мактау*). Әлбәттә, әсәрдә ирония күзгә бәрелеп тормый. Баштагы өч строфада автор мулланың кимчелекләрен турыдан туры әйтеп тәнкыйтьли: түргә утырып ашыйсың... хуҗа соңгы тавыгын суйган... син (мулла!!!) әйткәч сатулашып та тормыйча әйберләрен арзан бәягә сатарга мәҗбүр булган, ди. Турыдан-туры тәнкыйтьләү – кыюлык, ләкин әсәрне әсәр итә торган кыйммәт (сәнгать алымы – ирония) була алмый. Ә менә дүртенче, бишенче строфаларда ирония алымы урын ала – автор муллага киңәш иткән булып (*форсаты туры килгәндә ашап кал; садака алгач төне буе чәй эчеп утырма, ди*), мулланың төп эше өзлексез ашау һәм төне буе кунакта булуны ассызыклый.

Габделҗаббар Кандалый үзе дә – мулла. Димәк, шагыйрь мулла булган кешенең кунактан кунакка гына йөрүен тәнкыйть итә. Ул заманда мулла мөгаллим дә, казый да, дәвалаучы да, хәзерге җирле үзидарәләр вазифасын башкаручы да булган. Милләтнең алга китүендә муллалар әһәмиятле эшләр эшләгән. Габделҗаббар Кандалый үзенең «Мулла белән абыстай» шигырендә үзләрен генә кайгырта торган булдыксыз, надан муллаларга каршы чыга.

Бүгенге көн таләпләреннән чыгып бәя биргәндә, Габделҗаббар Кандалыйның «Сәхипҗамалга» әсәренең поэмаларга хас сюжеты юк (*Поэма – сюжет сызыклары, лирик чигенешләр, хис-кичереш һәм мөнәсәбәт белдерү белән үрелеп бара, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә торган лиро-эпик жанр* [10]). Кандалый сюжетны әсәрнең традицион төзелешен кабатлау белән алыштыра. Ул әсәренә лирик шигырь эчтәлеген һәм төзелешен сала. Әсәрдә ике хис янәшәлеге: мәхәббәт шатлыгы һәм хәсрәте. Беренчесенең сәбәбе – кызның тышкы матурлыгы һәм эчке матурлыгын күрсәткән яхшылыклары; икенчесенең сәбәбе – кызның кияүгә чыгудан баш тартуы. Әсәрдә Сәхипҗамалның җавабы да, кичерешләре дә, эчке дөньясы да юк. Шуңа күрә әсәр

өлешләрен лирик геройның үз кичерешләре, хыялы гына дип әйтә алабыз. Габделҗаббар Кандалыйның «Сәхипҗамалга» әсәрен яман эшкә – җәза, яхшы эшкә – яхшылык өлешләрен каршы куеп яза. Сәхипҗамалның муллага кияүгә чыгарга ризалык бирүен яхшы эше дип бәяли. Муллага кияүгә чыгуның ахыры матур нәтиҗәләр генә китерәчәген кат-кат дәлилли. Мулладан баш тартуын, киресенчә, яман эш дип бәяли һәм нәтиҗәсенең бик ямьсез булачагын кайта-кайта яза. Яман эшкә – җәза, яхшы эшкә – яхшылык төзелешен өченче тапкыр кабатлаганда, җәзаның Аллаһыдан булын ассызыклый (кызны теңкәмне корытканың өчен тәмуг утында янарсың дип куркыта). Кыскасы, әсәрдә мәхәббәт һәм мәгърифәт темалары үрелеп бара. Автор фикеренчә, бары мәгърифәт кенә хатын-кызларны бәхетле итә ала (*укымышлы кешегә кияүгә чыгу – бәхет, ә надан кешегә кешегә кияүгә чыгу – бәхетсезлек*). Автор укымышлы кешене надан кешегә каршы куя.

Поэма-хатларында Кандалый үзенең укучысы белән диалог төзи. Укучысын истә тотып, лирик героена да, лирик герой яраткан кызларга да бәя бирә. Автор буларак, лирик героена соклана да, аңардан көлә дә.

Габделҗаббар Кандалыйның «Сәхипҗамалга» поэмасының яңалыгы да, гүзәллеге дә – лирик герой хисләрен сәнгать алымнары белән сурәтләп бирүдә. Мәхәббәт хисенең сәбәбе – яраткан кешеңнең күркәмлеге. Кандалый Сәхипҗамалның фәкать тышкы матурлыгы турында гына яза. Ул гади авыл кызының чибәрлеген тасвирлый. Сурәт ясый. Сурәт ясауда таң җиле дә, сахралар да, асылташлар да ярдәмгә килә. Табигать күренешләре чагыштыру вазифасын гына үтәми, метафора булып та килә.

«Кандалыйга кадәр бер татар язучысы да мәхәббәт хисен аның кебек дулкынланып, гасабиланып, түзеп тормаслык дәрәҗәдәге хәсрәт итеп яза алмады. Мәхәббәт хисен ул дөньядагы иң зур матурлык дәрәҗәсенә күтәрде.

...Мәхәббәт хисләрен мәгърифәтчелек идеяләре белән бәйләсә дә, Кандалый мәхәббәт матурлыгын үзкыйммәткә ия булган матурлык итә алган. Бу – аның зур казанышы», – дип язды әдәбият галиме Альберт Яхин үзенең IX сыйныфлар өчен дәреслегендә [7].

Нәтиҗә ясыйк: Альберт Яхин укыту-методик комплектлары ярдәмендә XIX гасыр татар әдибе Габделҗаббар Кандалый яшь буын хәтеренә түбәндәгечә кереп кала:

Габделҗаббар Кандалый –

– бик укымышлы, муллалык эшенә зур вазифа итеп караучы, туры сүзле, кыю шәхес;

– рухи-әхлакый яктан бай, гыйлемле мулла;

– мәхәббәт һәм мәгърифәт темалары үрелеп барган, халыкның сөйләм телендә иҗат ителгән әсәрләр калдырган; ирония һәм метафора алымнарын куллanышка куйган затлы шагыйрь;

– Мәүлә Колый, Каюм Насыйри, Муса Акъегет, Гали Чокрый, Акмуллалар чордашы, мәгърифәтче.

ӘДӘБИЯТ

1. «Россия Федерациясе мәгарифе турында»гы федераль закон – Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации»от 29 декабря 2012 № 273-ФЗ.

2. Гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары концепциясе – Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования / под ред. А.М. Кондакова, А.М. Кузнецова – М.: Просвещение, 2009.

3. Гомуми белем бирү эчтәлегенең фундаменталь төше концепциясе – Фундаментальное ядро содержания общего образования: / под ред. В.В. Козлова, А.М. Кондакова. – М.: Просвещение, 2009.

4. Россия Федерациясе гражданины шәхесенең рухи-әхлакый үсешен тәэмин итү концепциясе – Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина Российской Федерации: / под ред. А.Я. Данилюк, А.М. Кондакова. – М.: Просвещение, 2009.

5. Примерные программы основного общего образования – Гомуми төп белем бирүдә өлге программа эчтәлеге. Әдәбият – Литература. – М.: Просвещение, 2010, 2011.

6. Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: (1–11 нче сыйныфлар) / төзүче-авторы А.Г. Яхин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 217–218.

7. Яхин А.Г. Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Тулыландырылган өченче басма. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 149–157.

8. Яхин А.Г. Әдәбият дәресләре. – Казан: Мәгариф, 2008. Б. 120–122.

9. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 123–126.

10. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 143.

11. «Хәзинә» сериясе. Карурманны чыккан чакта...: XIX гасыр татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2001. – Б. 237–238, 263–278.

# ТВОРЧЕСТВО ГАБДЕЛЬДЖАББАРА КАНДАЛЫЙ И ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ СОВРЕМЕННОГО ПЕДАГОГИЧЕСКОГО ВУЗА

*А.М. Шарипов, Д.Ш. Гильманов*

Габдельджаббар Кандалый является видным татарским поэтом XIX века. Он родился в 1797 году в семье муллы в деревне Малый Кандал Ульяновской области. Псевдоним «Кандалый» связан с названием его родной деревни. В течение 17 лет он обучался в татарских медресе, а в 1824 году, вернувшись в родную деревню, стал муллой. До последних дней жизни он оставался в своей деревне, где скончался в 1860 году.

Кандалый отличался наблюдательностью и критическим отношением к действительности. Особенно недоволен он был порядками в учебных заведениях, и в поисках лучшего медресе часто переходил из одного в другое. В период учебы он сформировался личностью с широким кругозором и глубокими знаниями. Скоро он начинает свое поэтическое творчество. В начальном периоде своего творчества он создает поэмы «Кыссаи Ибрагим Адгам» («Сказание об Ибрагиме Адгаме») и «Рисалаи ал-иршад» («Книга об убеждении на праведный путь»). В первой из них поэт создает образ легендарного царя Балха VIII века Ибрагима Адгама в качестве идеального человека, а во второй – призывает провести свою жизнь в молитвах. Однако не эти произведения характеризуют его творчество, так как его идейно-эстетические взгляды в течение своего творческого пути переживают эволюцию.

Скоро Кандалый становится поэтом активным, гневным и страстным. Он приносит в татарскую литературу неукротимую жажду самоутверждения. Кандалый сумел осознать право человека на личное счастье, на свой внутренний мир и настойчиво требовал, чтобы общество уважало эти права. Этот мотив отражается прежде всего в его произведениях о любви: это поэмы «Сахибджамал», «Фархи», «Шафгый», «Магшукнамэ», стихотворения «Фатима», «Багида» и др. Открытое воспевание чувственной любви, что было в те времена чем-то кощунственным, становится главной темой его лирики; в ней, в противоположность мусульманским заповедям, учившим людей уповать на лучшую жизнь на том свете, поэт призывал любить жизнь и на-

слаждаться ею на земле. Его произведения отличаются яркостью художественных образов, простым, понятным и живым языком.

В поэтическом творчестве Кандалый имеются и сатирические произведения. Например, стихотворение «Мулла белән абыстай» («Мулла и его жена»). Поэт сатирическими красками нарисовал образ муллы – тунеядца, который способен лишь ходить по меджлисам, сытно есть, спать и видеть в этом смысл жизни. В то же время поэт предупреждает муллу, что в ближайшем будущем мужикам надоесть приглашать его в гости и они выступят против него.

Таким образом, Г. Кандалый был видным представителем периода демократизации татарской литературы и литературного языка. Именно с его именем связаны те прогрессивные процессы в сфере эволюции концепции личности, которые происходили в поэзии XIX века, с его именем связано развитие идей просветительства и демократических устремлений в татарской литературе. Его творчество оказало большое влияние на поэтов более позднего времени. Его произведения и в наше время сохраняют большое познавательное значение.

Изучение творческого наследия Г. Кандалый начинается с трудов Каюма Насыри. Однако первый сборник его произведений был выпущен лишь в 1960 году видным ученым Хатибом Усмановым – «Г. Кандалый. Шигырьләр».

Значительную лепту в изучение творчества поэта внес М.Х. Гайнуллин: в своем учебнике для студентов вузов «Татарская литература. XIX век» он поместил пространственную статью о его творчестве и издал тексты некоторых его поэм и стихотворений. А самым полным его собранием сочинений является книга «Габделҗаббар Кандалый. Шигырьләр һәм поэмалар» (Казан, 1988), подготовленный и изданной академиком Миркасымом Усмановым.

Ученые Прикамского региона, в частности преподаватели вузов гг. Набережные Челны и Елабуга, вносят свои значительные лепты в изучение творчества Г. Кандалый. Так, Альфина Сибгатуллина в своей кандидатской диссертации «Концепция личности в татарской поэзии XIX века» две главы посвятила исследованию концепции личности в поэзии Г. Кандалый.

Большое значение изучению и пропаганде творчества Г. Кандалый придается в Набережночелнинском институте социально-педагогических технологий и ресурсов. Его творчество преподается студентам первого курса отделения татарского языка и

литературы филологического факультета в рамках дисциплины «Древняя татарская литература. Литература XIX века»: изучению его творчества отведено 4 часа (2 часа лекции и 2 часа практического занятия). Кроме этого, в нашем институте творческое наследие Г. Кандалый исследуется в следующих аспектах:

– влияние творчества Г. Кандалый на творчество других тюркоязычных поэтов;

– влияние творчества Г. Кандалый на творчество татарских поэтов;

– влияние творчества Г. Кандалый на творчество татарских поэтов Прикамья;

– влияние на творчество Г. Кандалый татарских народных песен;

– проблемы методики преподавания творчества Г. Кандалый в общеобразовательных школах и вузах;

– Г. Кандалый и творчество Мифтахетдина Акмуллы;

– Г. Кандалый и творчество Газизы Самитовой;

– Г. Кандалый и творчество Габдуллы Тукая.

По этой тематике у нас пишутся курсовые и дипломные работы, организуются выступления студентов на ежегодных итоговых студенческих научных конференциях. При прохождении педагогической практики в общеобразовательных школах студенты четвертого и пятого курсов еще глубже изучают творчество Г. Кандалый, готовят презентации по его творчеству. А также на организуемых в рамках нашего института курсах повышения квалификации преподавателей татарского языка и литературы на изучение творчества Г. Кандалый придается особое значение.

Через каждые пять лет в нашем институте отмечаются годы рождения и смерти этого выдающегося представителя татарской литературы XIX века: организуются литературно-музыкальные вечера в институтском масштабе. Каждый год одно заседание студенческого литературно-творческого кружка «Тамчылар» посвящается изучению художественного мастерства Г. Кандалый.

Таким образом, творческое наследие одного из крупных представителей татарского просветительства Габдельджаббара Кандалый и в наши дни шагает с нами рядом. Его произведения и в наши дни – в дни 155-летия со дня его смерти – бережно хранятся в памяти татарского народа; они призывают наших читателей ценить свое время, уважать и придерживаться исконных народных традиций и обычаев.

# Икенче бүлек
# Г. КАНДАЛЫЙ:
# ХАЛЫК ХӘТЕРЕНДӘ ҺӘМ ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ

## ЕРАК БАБАМ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ ЭЗЕННӘН...

*Н.С. Нурмөхәммәтова*

Миңа әби, бабай һәм апаларның күңелләрендә саклanган хатирәләрен ишетеп үсәргә туры килде. Сүз ара сүз киткәндә, кызыклы эпизодларны тулыландыру, җанландыру өчен генә әйтелгән сүзләр, китерелгән мисаллары да күп иде. Ул вакытта бәяләп бетерелмәгән, киләчәктә алтынга да алыштырып булмый торган мизгелләр булган икән бабаларыбыз белән аралашу вакытлары.

Бервакыт, үзем дә бөтенләй үк аңлап бетермәстән, кечкенә генә телефон номерлары язылган китапчыкка «Вакытларны кире борып булмый» – дигән җырны язып куйганмын. Бу җыр мине үзенең тылсымы белән яулап алды. Аның сүзләрен еш исемә төшерәм:

Әй, гомернең кайбер минутлары
Сагыш җиле булып ник кайта?
Кире кайтулары бер хәл әле,
Җанны кабат-кабат айката.

Вакытында ник кадере булмый
Азак сагынылган мизгелнең
Туктатырга телим, туктата алмый
Йөгереп үткән вакыт мизгелен.

Кире кайтарырдай вакытларны
Нинди бизмән белән үлчәргә?
Вакытларны кире борып булмый,
Бизмәне дә юктыр үлсәң дә!

Автор үзе дә үкенү хисләре кичергәнгә ошый, чөнки җыр эчендә бер генә дә артык, урынсыз сүз юк. Мизгел үткән, үкенү –

һичнинди файдасыз. Сабырлык белән генә истә калган күңел хәзинәсен актарырга кирәк.

Бабамның сүзләре миңа инша язганда берәр фикерне яки вакыйганы дәлилләү өчен кулланыла торган цитата кебек. Я булмаса гаиләбездә аерым шкатулкага салып куелган, бәяләп бетереп булмый торган «күңел ядкарьләре»дәй тоела. Ул сүзләрне, фикерләрне һичкайсы энциклопедиядән, башка язма чыганаклардан таба алмыйсың. Үзбәк халкында «Олылар сүзе – акылның күзе» дигән телетапшыру бар иде. Мондый нәрсәләр зур тәрбияви мәгънәгә ия, ләкин адәм баласы һәрвакыт ашыга, аның вакыты юк, игътибар бирми. Вакыт үтү белән, күп нәрсәләр күңел түрендә уяна: искә төшерәсең, эзләнә башлыйсың, үкенәсең, ваемсызлыгың аркасында нинди югалтуларга дучар булуыңны аңлыйсың.

Менә хәзер минем үзем белән дә шундый ук хәл. Әтиемнең әтисе Нурулла бабайдан бик күп нәрсәләрне өйрәнеп-белеп калырга кирәк булган икән. Адәм баласы мәңгелек түгел. Ишеткәнеңне, тирән мәгънәле вакыйгаларны гаилә дәфтәренә терки барырга кирәк.

Шәфкиҗамал әби белән Нурмөхәммәт бабайның 3 кызы – Галия, Галимә, Гөлмия, Нурулла исемле уллары була. Шәфкиҗамал әби исә – Габделҗаббарның Фәхриҗамал исемле хатыныннан туган кызы.

Ул укуга бик тырыш була, шуңа күрә аны Уфага укырга җибәрәләр. Шәфкиҗамал, укуын тәмамлап, зур планнар корып, туган авылына кайта. Ул яшь киленнәрне, кызларны гыйлемгә өйрәтмәкче. Кызның уй-фикерләре тиз генә тормышка ашмый. Аны бер байның малаена кияүгә бирәләр. Холкы белән кызы да әтисенә охшаган булса кирәк. Яңа гаиләдә кулыннан килгән хезмәтне кылып, үзе теләгән, яраткан эшеннән башка яшәүнең мәгънәсен тапмагач, гаиләдәгеләргә белдереп тә тормастан, мәхәллә мулласына барып иреннән аерылырга рөхсәт (талак) сорый. Мулладан туры атасының йортына кайта. Киленнең әйберләрен туганнары барып ала. Бу авыл тарихында булган хәл түгел. Шул елда Ильяс бабай улы Нурмөхәммәт Бохарадан укуын тәмамлап авылга кайтып төшә. Бохарада күп еллар буе, чит мәмләкәтләрдә укып йөргән Ильяс мулланың улы Нурмөхәммәтне Ильяс бабай укымышлы Шәфкиҗамал белән никахландыра һәм, яшьләргә бүләк итеп, авылның килен-кызларын укыту өчен зур гына мәдрәсә салдырып бирә.

Шәфкиҗамал озак еллар, 4 бала анасы булуга да карамастан, кызларны укыта. Ертуган авылында туып, сугыш алдыннан Мәскәү якларында яшәп туган якларына кайткан, бер гасырдан артык гомер кичергән Мифтахетдинова Факия Закир кызы үзенең укытучысы-абыстае турында исе китеп сөйли иде. Ул башкалардан һәрьягы белән аерылып тора иде. Сабагыңны аңлап бетермәсәң, янына килеп утыра да берәр кызыклы хәл сөйләп көлдереп ала, йомшак кына аркаңнан сыйпап, җиңел генә сабагыңны миеңә салып куярлык итәр иде, дигән сүзләре генә калды инде мәрхүм Факия апаның да. Укытучысы да, укучысы да белемле булганнар. Ул апа бик дөрес итеп, матур көй белән китапка карамастан яттан укый иде. Мәҗлестә ясин-догаларны укулары, вәгазьләре кешеләрне акландырып-пакьландырып җибәрә иде.

Остазы да, әти-әниләре дә үзләренең кызларын Уфага җибәрмәкче була, ләкин әтиләре үлеп китү сәбәпле, гаилә хыялы тормышка ашмый. Нурулла бабабызның әнисе турында болай сөйләгәне хәтердә: «Әни күп вакыт җил кубызына әверелеп тә ала иде. Үзе матур, кара тутлы, калын толымлы, матур киенеп йөри иде».

Ә Габделҗаббар бабайга килгәндә, аның көязлеге, итекләре майланган булуы, шук теллелеге, кызып китеп, тавышын күтәрә төшеп бәхәсләшүләре, хәтта табындагылар арасында аңа үпкәләүчеләре дә булгалаган. Бервакыт, Габделҗаббар бабай кызы белән киявенә кунакка килгән. Иртәнге чәйгә утыргач киявенә: «Кияү, бу бүлмәңә дошманың килсә генә яткыр», – дигән. Яңа бүлмәдә кунакны кандала ашаган икән, төне буе кандала белән сугышып чыккан.

Безнең Нурулла бабабыз Габделҗаббар бабайның башка хатыннары һәм балалары турында безгә сөйләмәгәндер инде, бер дә искә килми. Шәфкиҗамал әбидән туган балалар барысы да яхшы, матур, мул тормыш белән авылда яшәгән. Җирләре, ташпулатлары һәм башка кәсепләре дә булып, хезмәтчеләр белән яшәгәннәр. Тормышлары нык булган. Репрессияләр аларны да читләтеп үтмәгән.

Мулла нәселеннән булып та, указсыз килеш үзенең өендә намаз укытканы өчен безнең бабайга бик күп кимсетелүләр кичерергә туры килде. Минем әни әти йортына килен булып төшкәч, чормада бер сандыкка юлыга. Аны карый башласа, гарәпчә язылган шигырьләр икән. Аларның өстен чүпрәкләр, иске итекләр, көл, мунча себеркеләре белән кеше күрмәслек итеп ябып, каплап

куйганнар. Ул сандык бик озак ятты безнең чормада. Әни сандык янына якын барырга да рөхсәт итми иде. Анда догалар язылган, тияргә ярамый, кулыгыз корыр, ди иде. Без барыбер, бисмилла әйтеп кенә, беркем дә күрмәгәндә, догалар дип алып карый идек. Ә әни битләп-битләп алып укый иде.

Нәрсә өчен бу язмаларга кагылырга ярамаганлыкны тулысынча Кояш Тимбикова белән Госманов абый килгәч кенә аңладык. Бабайның бу хәзинәне юк итәргә һичкайчан да кулы бармас иде. Әле шундый шартлар куйды Казан кунакларына: «Кемнән? Кайдан? Бернинди исем, фамилия, минем оныкларыма зарары тимәслек булса гына бирәм», чөнки, (хәзер инде мәрхүм) бабайны өебездә намаз укытканы өчен, бигрәк тә Рамазан аенда элек колхоз идарәсенә, аннан соң «Пожаркага» берәр атна ябып торалар иде. Әни бабайга төнлә генә ашарга алып китә торган иде. Ай яктысында, абый белән тәрәзәдән урамга карап тора идек. Алладан бабайны тизрәк коткаруын сорап, әнинең кайтуын көтә идек. Кем уйлаган ул вакытта, дин тоту өчен бүгенгедәй иркенлек килер дип.

Безнең Нурулла бабабыз бик еш кына Габделҗаббар бабасының да эзәрлекләүләргә очрап торуын, шуңа күрә усалланып-усалланып китүләрен дә урынлы дип таба иде. Ул төрле җирләрдә укып, төрле җирләрдә булып «үз кендеген үзе кисәргә өйрәнгән». Ул – куркусыз мишәр. Әйткән сүзе уктай булса да, угының зарары үзенә дә тигән.

Безнең Ертуган авылыннан Бохарага укырга дип икәү киткәннәр: берсе – бу якларда даны таралган Миннәхмәт мулланың этисе. Аның исемен мин белмим. Туган якларында, авылдашлары арасында шәкертләр җәдит гыйлеменә чыкканнар дигән сүз таралган. Шуннан соң этиләре улларын алып кайталар, ләкин безнең бабайны нәрсә дә туктатып кала алмаган, ул кире китеп барган.

Бабабызны мәхәббәттән башка нәрсә кызыктырмаган булса кирәк. Кызлар күзе төшәрлек киенә: өс-башы зәвыклы, матур, шәһәрчә булган. Шагыйрьнең оныгының сүзләре белән әйтсәк: ул җир кешесе дә, күк кешесе дә булмаган. Әллә инде гаиләсен, балаларын тулысынча матди яктан тәэмин итеп торучылар булганга, дөнья тормышына шулай җиңел караганмы?

Артист Габдулла Шамуковка туган тиешле мәрхүмә Хисаметдинова Нажия апа – Гыйльмия әбинең укытучы кызы, шулай сөйли иде: «Габделҗаббар дүрт яшендә инде Коръән укый алган» дип. Димәк, кечкенәдән талантлы һәм тирән белемле булуы бәхәссез.

Нурулла бабай үзенең намаз киемнәрен бик саклап, пөхтә итеп тота. Аны намаз укыганда гына кия торган иде. Хушбуйларын безнең кул җитми торган урында тота иде. Бездә дә шуклык җитәрлек булган. Кулыбыз, буебыз җитмәсә, озын таяк белән югары җирләргә сузылып, морадыбызга ирешер идек. Нинди генә зыян китерсәк тә, балаларга ачулану гадәте юк иде. Бу зыян зур зыян түгел. Чын бәлалар килмәсен, куллары киселмәсен, аяклары белән пыялага басмасыннар дип, үз эшенә тотыныр иде.

Бабай үзенең беренче хатыны Зөһрә әби турында бик кызганып сөйләгәндә, бабай, әтиләр турында да сөйлә әле, дип сәкегә менеп утырып тыңлар идек. Әбиебез, өч баласын ятим калдырып дүртенче баласыннан үлеп китә. Ул вакытта бабабызга кырык тугыз яшь була. Өч баласы булуга карамастан, байлыгына сокланыпмы, таза гына тормышлы Имам исемле кеше унҗиде яшьлек кызын бабайга бирә. Аңа: «Имам абзый, нигә дүрт бала өстенә, олы кешегә чәчәк кебек балаңны бирәсең?» – дигәч, «Ул әле малайларыннан да яшь, арты тулы кибәннәре, кемдә дә юк андый ташпулатлар», – дип җавап биргән.

Галия әби белән ничә ел яшәгәннәрдер, белмим. Сөйләгәндә Зөһрә әбиегез, Галия карчыгым дигәндә, ачуым килгәндәй була иде. Берсен – әбиегез, икенчесен – карчыгым диюләре көнләштереп ачуымны китерә, тыңлыйсы килми башлый. Ул беркайчан да зарланмас, берәр кайгы килсә: «Сабырлык, бәла-каза кычкырып килми, нindидер гөнаһларыбыз өчен бирелгән бу безгә Алла тарафыннан, Алла кушмаган эш булмый. Авырлыклардан чыгу өчен, үзең хәрәкәт кылырга, кәсебенә керешергә кирәк. Ходайга ачу сакларга, сүз куып йөрергә ярамый, мондый нәрсәләр кешене авыруга дучар итә, аның үзе алдында да, башкалар алдында да хөрмәтен, абруен төшерә», – ди торган иде.

Минем әле бүгенгедәй исемдә: базыбыздан бер бәрәңге дә калдырмыйча алып киткәннәр. Әни елый, кара инде, чәчәргә калдырмаганнар, ни эшләргә булыр дип өзгәләнә, ә бабай: «Елама, ел буена рәхәтләнеп ашадык, алган кеше ирекледән кеше базына төшмәгәндер, чәчәргә түгел, ашарына да юктыр. Каргама, әҗереннән мәхрүм буласың, зур садакалардан китсен, бәрәңгең кире кайтмый, Алла бер юлын курсәтер, уйламаган-көтмәгән җирдән бирер, ярдәменнән ташламас. Үз сүзләре бар: “Бирим дисәм колыма, китереп бирермен кулына”», – ди.

Безнең әтинең үлгән хәбәре килгәч, әниләр бабайның сүзләреннән көләргә дә, еларга да белмәгәннәр: «Үлгәннәргә җәннәт,

ә безгә хәерле гомер, иман байлыгы, сабырлык, яшәү көче бир, хәерле булсын». Юкса, кеше үлгән – ул үзе үк хәерле түгел бит инде. Алланың биргәненә шөкер кылмасаң, разый булмасаң, «Җирем белән күгем арасыннан чыгып кит», дигән.

Еллар үткән саен, Нурулла бабама, дөньядан бакыйлыкка күчүенә күп еллар үтүенә карамастан, хөрмәтем арта баруын, ә аның кыен вакытларда юл күрсәтүен, киңәшләрен сизәм. Бабайның хуҗалыгы зур булган. Хезмәтчесен ул үзе белән бер табынга утыртып ашаткан, тамагыннан аермаган. Үзеннән ерак түгел, шул ук урамда хезмәтчесенә йорт салып, сыер-сарыгын алып биргән. Аның сүзләрен мин хәзер үземнең балаларыма еш кабатлыйм: «Хезмәтчеңнең тире кипкәнче, хакын түлә». «Башка милләт кешесенең хакына калма, кыямәт көнне иманың белән түләрсең».

Ул башка милләт кешеләре белән иркен аралашкан. Безнең авылга «Олы Кандал» дигән авылдан тимерчедә эшләү өчен бер урыс гаиләсе килеп урнаша. Озак яшиләр алар татар авылында. Хатыны үлгәч, әти кеше өч кызы белән яши, беркая да китми. Үзе дә авырый башлый. Шул вакытта бабайны чакыртып васыятен әйтә: кызларын бабай карамагына калдыра. Тимерче абыйны татар авылында, каберлекнең эченә түгел, тышкы ягына яхшы такталар белән әйләндереп җирлиләр.

Кызларның үсеп җиткән бере тормышка чыга бара: икесе татар кешесенә, берсе рус егетенә. Без бер мәртәбә аларның балалары һәм оныклары белән очраштык. Алар татар авылының мулласы Нурулла турында бик күп җылы сүзләр әйттеләр.

Бабайның Кече Кандалдан бер умартачы дусты бар иде. Ул безнең өчен Кылпикоф бабай иде. Клепиков булгандыр инде ул. Без аны көтеп ала идек, таш савытта балаларга бал салып бирә иде, ипи кисәкләре белән бер минутта эзен дә калдырмый идек.

Чиркәү-мәчетләрне туздырганчы, умартачы бабабыз чиркәүдә хезмәт иткән, рухани булган. Ике бабай – ике милләт кешесе үзара русча сөйләшә иде, китаплардан бер-берсенә нәрсәләрдер укып күрсәтәләр иде. Безнең өебез, гомумән, кунакханә ролен үтәгәндәй тоела миңа хәзер. Ул үзәк урамда, кырыйдан икенче, зур өй. Юлаучылар өчен өебез уңайлы җирдә урнашкан. Өйдә ир-ат, җылы, кунып чыккан өчен акча алу юк. Безнең авыл аша Казаннан Рәҗәп ягына чаналар тартып кыз-хатыннар товар ташый иде. Аерым урында йоклау юк инде, барыбыз да бердән тезелешеп ятабыз.

Үзебезнең кешеләребез генә булса бер хәл. Хәтта чегәннәр дә кергәләделәр. Аларны инде кем дә кертми: үзләре күбәү, балалары, атлары. Кешеләр язмышларын беләселәре килә, чегәннәр ат азыгына, ашамакка карыйлар иде. Акча дигән нәрсә булмагандыр инде ул. Авылда 2–3 көн кунып, халыкны өметләндереп, килер көннәренең якты булачагын әйтеп, шатландырып китәләр иде.

Әни бит – килен кеше. Ачуы килә, тынычлык юк. Кертәсе килмәгәне күренеп тора, ләкин каршы килүнең файдасы юк. Бу өйдә бабайга каршы килү гадәте бөтенләй юк. Аның һәр гамәленә дәлиле бар: «Яхшы хуҗа этен дә чыгармаслык кыш көнендә, ничек каршы килергә мөмкин? Без җылы өйдә, җылы урында, юлдагыларга Алла ярдәмен бирсен», – дип башка сүз әйтергә урын да калдырмас иде.

Әби-бабайлардан ишеткәннәрне гомерең буе язсаң да язып бетереп булмый. Алар берсе дә артык та, урынсыз да түгел. Һәрбер сүзләрендә тирән мәгънә ята. «Тәүфыйклы булсаң, бәхетең була. Тәүфыйк белән бәхет бергә йөри», – диләр иде. Сүзләрне ишетәм, ә мәгънәсен аңламыйм. Кемнәр икән алар? Кайда йөриләр икән дип уйлап йөри идем.

Без, ишеткән-күргәннәребезгә тиешле бәяне биреп, шул шәхесләргә, олы буын кешеләренә рәхмәтле булып, яшь буынга, укучыларыбызга гына түгел, аларның әти-әниләре, әби-бабалары белән дә халкыбызның милли хәзинәләре турында очрашып сөйләшсәк, файдасы тими калмас иде.

Сәмәрканд шәһәрендә үзем белән булган хәлгә тукталып китәсем килә. Өч яшьлек улым белән трамвайга килеп кердек тә, баланы утыртып, үзем янына бастым. Шунда бик пөхтә киенгән, ягымлы гына бабай миңа: «И, кызым, шундый матур гына угыл тудыргансың, ә дөрес тәрбия кылуны белмисең. Йөзең үзгәрде, балам, ачуланма. Килер вакыт, рәхмәт әйтерсең. Ир бала әнисе басып торганда һичкайчан утырырга тиеш түгел», – диде. Балам үзе дә аңлап, шунда ук сикереп торып, мине утыртты. Мин рәхмәт әйттем, бабай мактады да мактады. Шул көннән алып, бүгенге көнгә кадәр Сәмәркандтагы бабайның үзе дә, сүзләре дә исебездән чыкмый. Аның тылсымлы сүзләре минем балаларымны гына тәрбияләмичә, хәзер инде оныкларымны да тәрбияли. Мин аңа гомер буе Аллаһының рәхмәтен телим. Көннән-көн әти-әниләр, әби-бабайларның гаилә, тәрбия эшендә кылган гамәлләре бик зур һәм моның бәхәссез икәнлегенә инана барам.

# ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙ ТУРЫНДА ХАТИРӘЛӘР

*Ф.Х. Мәҗитов*

Аның әтисе, Габделмәҗит бабай, үзенең гаиләсе белән Татарстанның Чүпрәле районы, Каракитә авылыннын шушы Ертуган авылына килеп төпләнгән. Габделмәҗит бабай укымышлы булarak, шушы авылның мәчетенә имам итеп билгеләнә.

Габделҗаббар башлангыч белемен әтисеннән ала, шуннан соң Чистай якларына китеп берничә мәдрәсәдә укый. Белемгә омтылучан, туры сүзле, кайнар холыклы, яшьтән үк гарәп, фарсы телләрендә укый-яза алган, берничә телне белгән. Мәдрәсәдә укыган вакытында ук поэмалар яза башлаган.

Габделҗаббар Кандалый иҗатының башында язган әсәрләре гарәп, фарсы сүзләре күп булуы белән аерылып торган. Олыгайгач, ул халыкка якын, аңлаешлы гади сөйләм телендә яза башлаган.

Татарстанның күренекле язучылары һәм тел белгечләре татар әдәби теленә нигез салучы итеп XX гасыр башы әдибе Габдулла Тукайны түгел, ә XIX гасыр шагыйре Габделҗаббар Кандалыйны хаклы рәвештә санарга телибез, дип яздылар. Шуңа күрә Тукай үзе дә күп нәрсәләрне Габделҗаббар хәзрәт әсәрләрен укып өйрәнгән дип саныйлар икән.

1824 елда (27 яшендә) Габделҗаббар Кандалый туган авылына кайта, имам булып халыкка хезмәт итә башлый. Биредә ул 20 елдан артык имамлыкны алып бара.

Гаять үткен һәм туры сүзле, гадел булуы сәбәпле, җирле муллалар кайвакыт аның белән килешмәгәннәр, бәхәсләр килеп чыга. Ул фәкыйрь, күп балалы кешеләр муллага садака бирергә тиеш түгел, ә киресенчә, муллалар аларга ярдәм итәргә тиеш дип аңлата. Җирле муллаларның моңа ачуы килә, Габделҗаббар бабай өстеннән властька шикаять язалар, имеш, ул халык арасында дәүләткә каршы эш алып бара дип. Шул сәбәпле, аны 2 елга хөкем итәләр һәм ул Олы Кандалдан ерак түгел ИТКда (исправительно-трудовая колония) утырып чыга. Гади халык аның гаепсездән хөкем ителүен аңлый һәм аны яңадан имам итеп алалар.

Мин бу язмамда әби-бабаларым сөйләгәннәргә таяндым. Алар сөйләвенчә, якынча 1857 елда, Габделҗаббар бабай Ертуганда туып үскән, Әсән авылының таза тормышлы, зур нәселле кешеләренең берсе булган Мәҗитов Камалетдинның кызына өй-

ләнгән. Бу яшьләр шушы авылда яшәп калганнар. Аларның ике балалары туган: беренчесе – минем туган бабам Мәҗитов Җәләлетдин, икенчесе – СССР ның халык артисты – Габдулла Шамуковның әнисе ягыннан туган бабасы – Мәҗитов Фәттәхетдин.

Минем бабам, Мәҗитов Җәләлетдин, 1858 елда туган, 1940 елда, 82 яшендә, миңа 5 яшь тулып килгәндә, вафат булган. Мин моны бүгенгедәй хәтерлим.

Җәләлетдин бабайның балалары әйтүенчә, ул 4 яшендә вакытта, әтисе Камалетдин бабай көтмәгәндә вафат булган. Димәк, Камалетдин бабайның вафат булуы 1863 елга туры килә. Туган елын якынча санап чыгарырга мөмкин. Әгәр ул 20 яшендә өйләнеп 5–6 ел чамасы гаиләсе белән яшәсә, вафат булса (1863 –26 = 1837), бу вакытта Габделҗаббар бабайга 40 яшь. Димәк, яшьли вафат булган Камалетдин бабай белән 25 ел Армиядә хезмәт итеп кайткан Садретдин бабай, Габделҗаббар бабай Кандалыйның уллары дигән сүз.

Хәзер мин Габделҗаббар бабайның миңа туган булуын дәлилләп китерәм: Әсән авылында 1919 елда туган абыем – Мәҗитов Закирҗан, укытучылыкка укып бетергәч, юллама буенча Ертуган авылына укытучы итеп җибәрелә. Ул анда 1938–1939 елларда укытучы булып эшләгән. Аңа олы яшьтәге укытучылар – Сөләйманов Шаяхмәт һәм Туктабиев Мизвахетдин абзыйлар белән эшләргә туры килгән. Ул, яшь булуына карамастан, аларга искәрмәләр (замечание) ясый торган булган. Бу аларга ошамаган. Алар Закир абыемны кисәтеп болай дигәннәр: «Син, малай, бик тирән керешмә, без синең койрыгыңа тиз басарбыз, син бит Габделҗаббар хәзрәт нәселеннән», – дип янаганнар.

Аңлашыла ки, бу вакытта сай белемле, тар карашлы, надан большевиклар Габделҗаббар бабайны, «ул буржуазия вакытындагы шагыйрь, аның хезмәтләрен юк итәргә, аның исемен дә онытырга кирәк», – дип аңлатканнар. Шуңа күрә, абыемны куркытырга сәбәп тапканнар.

«Өмет» газетасында (2014, № 23) бик яхшы мәкалә язылган иде. Ул СССР халык артисты Габдулла абый Шамуков турында. «Сагындырып искә төшә һаман» дип исемләнгән. Мәкаләне язучы, Габдулла абый белән күп еллар бергә эшләгән, Татарстанның халык артисты – Хәлим Җәләлов болай язган: «Габдулла абый Әсән авылында туып үскән булса да, аның нәселе, күренекле татар шагыйре Габделҗаббар Кандалыйга барып тоташа икән», – дигән. Күрәсең, Габдулла абый аңа бу турыда сөйләгән булып

чыга, ә Габдулла абыйның әнисе – минем әтием белән якын туганнар (двоюродные), Габдулла абый белән мин дә туган булам (троюродные).

Ни дисәк тә, Габделҗаббар бабабыз күпне күргән, күпне белгән, күпне кичергән шәхесләрдән санала дип уйлыйм. Әле хәзерге заманда да Татарстанның күренекле әдипләре, галимнәреннән шундый сүзләр ишеткәнем бар: «Без үзебезнең хезмәтләребездә әле дә Габделҗаббар Кандалыйның иҗатына мөрәҗәгать итәбез», – дип әйтәләр.

Габделҗаббар бабабыз гади халыкка тугрылыклы булып хезмәт итәргә тырышкан, авырлыклар, каршылыкларны да күп күргән. Аллаһыбыз аның урынын җәннәттә кылса иде. Амин.

## СӘХИПҖАМАЛНЫҢ ПРОТОТИБЫ ТУРЫНДА

*Р. Шәфигуллин*

Парау илендә төш күрдем,
Ки бер кош тоттым, укаттым,
Парау илендә бер матур
Өчен уйкумны югалттым.
Г. Кандалый

XIX йөз татар язучылары арасында Габделҗаббар Кандалыйның күренекле урын тотканын әйтеп тору кирәкмәстер. Шуңа да карамастан без аның шәхси тормышын, уй-кичерешләрен аз беләбез әле.

Югарыда китерелгән шигырь юлларын мин аның «Сәхипҗамал» исемле поэмасыннан алдым. Ул үзенең әлеге поэмасында барлык бүтән татар шагыйрьләреннән аерылып, «Гаять бөек әхлакый прогресс – хәзерге замандагы индивидуаль җенси мәхәббәт» тойгысын җырлау аша, бу тойгының шулхәтле кайнарлыгын, шулхәтле матур икәнен ача һәм «Сәхипҗамал» поэмасында мәңгеләштерә.

Гөлем бул, гөл агачым бул,
Я былбыл-сандугачым бул,
Бу дәрдемгә гыйлаҗем (дәвамым. – *Р.Ш.*) бул,
Сәхипҗамал абыстай ла!

Парау... Урманнар ышыгына сыенган гади генә, әмма бик дини татар-мөселман авылы. Янәшәсендә генә, Кече Чирмешән ярында урнашкан, заманында Болгар дәүләте сагында торучы «Яңа Сакчы», югарырак – «Олы Сакчы» чуваш авыллары...

Биш урамлы, озынлыгы өч чакрымнан артыгракка сузылган Парау авылында заманында ике мәчет, мәктәп, Поташ заводы, ике су тегермәне, 2 200 га тирәсе җире булган, ике меңнән артыграк кеше яшәгән. Шулай тормыш үз җае белән барган. Халык яз-җәй айларында игенчелек, умартачылык белән шөгыльләнгән, терлек-туар тоткан, буралар бурап, яңа өйләр торгызган, буа, күл суларына юкә кабыгы батырып мунчала төшергән. Көзен-кышын әлеге мунчаладан кап суккан. Салаван, Матак, Мәләкәс базарларына олауга йөргән. Гыйшык утында янган шигъри күңелле хәзрәткә Сәхипҗамалның туган авылы да күңеленә хуш килгән. Шуңадыр ул Парауда еш булгалаган.

Иртуган белән Парау арасындагы кара урман юлларын әле мин дә яхшы хәтерлим. Инде әйтелгәнчә, Г. Кандалый – мәхәббәт җырчысы. Ул үзенең иҗатында социаль мәсьәләләрне турыдан-туры күтәрми. Ләкин аның мәхәббәткә багышланган бик күп шигырьләрендә тормыш чынбарлыгы бар. Әдип крестьянның авыр хезмәтен шыксыз күренешләре белән безнең алдыбызда рәхимсез чынлыгы белән җәеп күрсәтә.

Кандалый хатын-кызның, гомумән хезмәт ияләренең, шул исәптән крестьяннарның бу фаҗигаләрдән котылу юлын күрсәтә алмый, шушы зур мәсьәләгә килеп терәлгәч, бик тар караштан чыгып җавап бирә: чибәр кызлар мужикка кияүгә чыкмаска, вакыты җиткәч муллага, укымышлы кешегә чыгарга тиеш янәсе. Менә монда инде без, бүгенге күзлектән караганда, Кандалый карашларының чикләнгәнлеген һәм примитив булганлыгын үтә дә ачык күрәбез. Ул, әлбәттә, тормышны социаль яктан үзгәртү рецептын бирә алмый, моның өчен әле ул чакта алдынгы, иҗтимагый фикер өлгереп җитмәгән була. Бигрәк тә татарлар арасында.

Әлеге мәхәббәт поэмасында «Сәхипҗамал» (тулы исеме – Бибисәхипҗамал) исеме 30 мәртәбә (Сәхипҗамал, Җамал, Биби, Сәхип кебек исемнәр астында), «Парау» авылы исеме 8 мәртәбә кабатлана.

«Сәхипҗамал» поэмасы тәүге тапкыр Каюм Насыйриның «Фәвакиһелҗөласә» (Әңгәмә җимешләре) китабында (Казан, 1887 ел) дөнья күрә. Бу хакта «Яңалиф» журналының 13 нче

санында (1929 ел, 14 бит) телгә алынган. Аңа хәтле, 1881 елда Казан университеты нәшрияты «Мәгъшукнамә» исемле китап чыгарган. Анда басылган күпчелек шигырьләр Г. Кандалыйныкы, әлбәттә. Ләкин алар имзасыз гына бирелгәннәр. Өстәвенә, бик күп җырлары башка басмаларда халык җырлары исәбенә кертелгән.

К. Насыйри беренчеләрдән булып, Г. Кандалыйны шагыйрь итеп ачкан кеше. Әйе, Кандалый әле дә тулысынча өйрәнелеп бетмәгән шагыйрь. Миңа калса, бу үзенә җәлеп итә торган бик кызыклы тарихи тема.

«Яңалиф» журналында язылганча, Сәхипҗамал Парау авылының танылган умартачысы Сәйфетдин кызы булган. Әтисе Сәйфетдин Сәхипҗамалны авылның Пәскә исемле тол калган бер кешесенә көчләп диярлек кияүгә биргән. Беренче баласы Ногман тугач, озак та үтми, Сәхипҗамал 25 яшендә фанилыктан бакый дөньяга күчкән. Хәзер инде шушы «серләрне» акырынлап чишәсе генә калды.

Әйе, Сәхипҗамалның ире, ягъни, Ногманның әтисе Гыйльми Пәскәсе – Фәсхетдин булырга тиеш. Үсеп буй җиткәч, Ногман Татар Аппагы авылыннан Фәрзана исемле кызга өйләнгән. Ногман үзенең төсе, бите, башка сыйфатлары белән әнисе Сәхипҗамалны хәтерләткән. Нәкъ менә аның кебек үк, кыска сүзле, кеше өенә килеп кергәч, беравык сүз башламыйча елмаебрак торучан булган дип сөйли Параудагы күршем 90-ын ваклаган Бибиҗиһан апа, әтисе – Пәскәнең туганы Кәшафетдин бабайның хатирәләрен искә төшереп.

1894 елда Ногман белән Фәрзананың Миңнегөл исемле кызлары туган. Миңнегөл апаны мин бик яхшы хәтерлим әле. Ул искиткеч ягымлы, йомшак сүзле, артык каударланмыйча гына яшәүче кеше иде. Ире – авылыбызның бик күренекле балта остасы Шәрип абый Хафиятов белән бик матур гомер иттеләр. Аларның беренче уллары Ханиф 1946 елда Германия башкаласы Берлинда үтерелгән. Икенче уллары Госман бөтен яктан булдыклы механизатор иде. Ә өченче уллары Дамир Шәрип улы Хафиятов Ульяновск өлкәсе күләмендә алдынгы мәгърифәтче сыйфатында танылды. Озак еллар дәвамында Парау авылы мәктәбендә директор вазыйфаларын уңышлы үтәде. Дамир абый Парау өчен күп кенә изге эшләрен башкарып, берничә ел элек гүр иясе булды. Кече кызлары Наилә катлаулы язмыш сукмагын узды. Анысы да фани дөньяда юк инде. Әлбәттә, аларның берсе дә

үзләренең ерак әбиләре «Сәхипҗамал» поэмасы героинясы икәнен белмичә бакыйлыкка күчтеләр. Бүгенгесе көндә Миңнегөл апа белән Шәрип абыйның онык-оныкчыклары төрле төбәкләрдә яшиләр.

Миңнегөл апаның әтисе ягыннан нәселе зур. Пәскәнең – Фәсхетдиннең туганнан туган энесе Сираҗи бабайның уллары Кәшафетдиннең, Шәйхетдиннең, кызлары чүпрәче Сәкинәнең, Мәфтуханың дәвамнары Парауда еш очрый.

Данлыклы шагыйребез Г. Кандалыйга әйләнеп кайтсак, аңа «мәхәббәт җырчысы» дигән исем тикмәгә генә тагылмаган. Аның сөеп йөргән, яраткан асылзатларга багышланган шигырьләре – «Фидаҗаным», «Сәрвиҗәмал», «Кавыша алмасак», «Бернәзарда», «Кызыл алма», «Шәфгый», «Гөлстанга» (хатыны). «Әминәгә», «Камиләгә», «Сәнһәмбән», «Сәламнамә», «Кара колтик» һ.б. моңа дәлил булып торалар. Иң күләмлесе һәм миңа, авылдашым буларак иң кадерлесе, әлбәттә инде, «Сәхипҗамал» поэмасы. Менә әлеге әсәрдән өзек:

...Кемне генә табыйм икән,
Күреп Сәхипҗамалемне,
Гыйшыкымны бәян итеп,
Сөйләп бирердәй хәлемне?..

Тагын шунысын да ассызыклап үтәсем килә, «Сәхипҗамал» поэмасы үз чорына карата гади генә поэма түгел. Бу – ислам диненең, суфичылык идеяләренең, шул исәптән ишаннар авылы Парауда да иң көчле вакыты. Аннары, Кандалый бу әсәрендә сөйгәнен тышкы сыйфатыннан гына түгел, эчке рухи дөньясы ягыннан да танырга тели, шуңа омтыла. Аныңча мәхәббәттә бәхетле булыр өчен үз яратуың гына җитми, әле тагын яраткан кешеңнең дә сиңа карата шундый ук хистә булуы кирәк. Менә шушылар «Сәхипҗамал» поэмасына нindидер җылылык, шигъри матурлык өсти дә инде.

Парауда Кандалый исеме төрле риваятьләргә чорналып, чыны-ялганы белән бергә кушылып дигәндәй, халык арасында киң таралган. Әйе, Г. Кандалый һаман да халык теленнән төшми, мөгаен аның рухы да бездән, исәннәрдән дога өмет итәдер, яхшы сүз көтәдер. Иншаллаһ, безнең бүгенге чарабыз да Г. Кандалый рухына нур өстәр. Сөекле шагыйребезнең дөньялыкта булган хата-кимчелекләре кичерелеп, Аллаһының рәхмәтләренә ирешер.

# ПЕРЕВОДЫ СТИХОВ ГАБДЕЛЬДЖАББАРА КАНДАЛЫЙ

## Стихи хазрета

*(Стихотворения Г. Кандалый в переводе Сергея Малышева; предисловие Рузии Сафиуллиной)*

Поэта Габдельджаббара Кандалый, имя которого знакомо ценителям татарской поэзии еще со страниц школьных учебников, по-настоящему я открыла для себя лишь в 2004 году, когда стала известна тема моей будущей кандидатской диссертации: «Традиции фольклора в творчестве Габдельджаббара Кандалый». И прониклась его стихами навсегда: для того чтобы понять и принять поэта, относиться объективно к его творческому наследию – это первостепенно. При этом меня огорчало то, что Кандалый ныне почти забыт, его хорошо знает лишь узкий круг литераторов и литературоведов. Разумеется, подобная «забывчивость» обедняет нашу многовековую литературу: даже среди известных личностей, далеких от литературы, порой встречаются люди, которые полагают, что основоположником татарской поэзии является Габдулла Тукай (1886–1913). Многообразие жанров, стилей, форм творческого наследия татарских поэтов, достойнейшим и талантливейшим представителем коих является Габдельджаббар хазрет, зачастую не учитывается.

Поэзия Г. Кандалый, на мой взгляд, актуальна сегодня и останется такой во все времена, поскольку она базируется на общечеловеческих ценностях, в ней затрагиваются вопросы бытия. Значит, стихи и поэмы хазрета также близки и понятны носителям других языков. Данная подборка стала первым опытом художественных переводов произведений Г. Кандалый Сергеем Малышевым. Впоследствии был также опыт сотрудничества с Алексеем Саломатиным и Максимом Амелиным. Я очень признательна тем мастерам Слова, которые помогли «заговорить» Кандалый по-русски так же красиво и звучно, как на его родном татарском языке.

## Габдельджаббар Кандалый

* * *

Скрипит перо, мол, не жалей чернил,
Твои слова усладой будут ей.
Корит перо, мол, что притормозил? –
Усладу сделай чуточку длинней.

* * *

Пригрезится мне облик твой…
И стройный стан, и взор живой,
Плывя, танцуя предо мной
Пленят – не отводить бы глаз.

И если ты – из мира снов,
Видений, легких облаков,
Нырнуть в беспамятство готов, -
Безумным легче быть подчас.

Пески пустынь, твердыни скал
Тебя б не скрыли – отыскал,
Я словно бы к воде припал, –
Твоих объятий водолаз.

Страсть непременно доведет.
Твои уста подарят мед,
Познаем взлет, паденье, взлет,
Не мерясь, кто грешней из нас.

О Боже, уж не обессудь:
Блаженством заверши мой путь,
Чтоб я как в омут мог нырнуть, –
Ее объятий водолаз!

* * *

Кто испил вина любви, тот обречен,
Лишь возлюбленной бывает исцелен.

Опоён тобою, душенька моя.
Не увижу, так вконец измаюсь я.

Камнем на сердце легла ты тяжело,
Мглою слёз глаза мои заволокло.

Горько плачу я над горестной судьбой:
Сердцу больно, жизнь погублена тобой.

Пелена в глазах затмила белый свет,
Он немилый, если милой рядом нет.

Мне в мечтах о гибком стане погибать.
Сладость губ твоих ужели не узнать?

* * *

Фатима, такое дело,
Чтой-то нынче ты не та:
С виду тесто пригорело,
А в серёдке – сырота.

* * *

Безбородый, был я парень хоть куда,
Шибко нравился красавицам тогда.

А с тобой мне, борода, одна беда:
Разбегаются красотки кто куда!

* * *

Мой недруг радости не знает:
В беде смеюсь – мрачнеет он.
Когда ж напасть отполыхает,
Он горем прямо сокрушен.

* * *

Со временем и яхонты найдешь,
Но времени за них не обретешь.

* * *

Ах, солнце, ты взойдешь? Избавишь ли меня,
Спасешь меня, возьмешь из этого огня?!

* * *

Дитя мне потерять пришлось…
Стекала чернь моих волос,
Разлились речки из-за слез,
Казалось – близок смертный час.

С судьбою совладеешь как?
О землю плющит так и сяк, –
Но только б не могильный мрак,
Но только бы не смертный час.

Страдалец встанет чуть живой,
Спешит к беде очередной,
О камни бьется головой,
Чтоб отодвинуть смертный час.

Кто был насильно разлучен,
На безнадежность обречен.
Но не уйдет из жизни он,
Пока не встретит смертный час.

* * *

Такой огонь горит во мне –
Потёк бы снег во всех краях,
Когда б он полыхнул вовне…
О, дай терпения Аллах!

Так много надо бы сказать,
Но не могу связать слова.
Хотел бы знать, где силы взять,
Перо – и то держу едва.

Когда в рассудке складу нет,
Как мунаджаты тут писать?
Моя головушка на свет
Явилась беды принимать.

Сведения о переводчике:

*Малышев Сергей Владимирович (1950–2007) – талантливый казанский поэт, переводчик, заслуженный работник культуры Республики Татарстан, лауреат литературной премии имени Гавриила Державина. Член Союза писателей СССР с 1989 года. Работал редактором отдела республиканского молодежного журнала «Идель». Перевел на русский язык стихотворения более чем сорока татарских поэтов. Возглавлял секцию художественного перевода в Союзе писателей Татарстана.*

## Габдельджаббар Кандалый: второе приближение

*(Переводы стихов и предисловие Алексея Саломатина)*

Нельзя сказать, что имя Габдельджаббара Кандалый (1797–1860), выдающегося поэта и полиглота, чей вклад в становление татарской поэзии часто сопоставляется с «державинским переворотом» в поэзии русской, русскоязычному читателю совсем неизвестно – несмотря на отсутствие собранного или избранного, переводы отдельных его стихотворений неоднократно появлялись на страницах поэтических антологий. Говорить о близком знакомстве, впрочем, пока рано. И дело не только в сравнительно небольшом количестве переведённых текстов.

Поэт – это в первую очередь стиль. Лексические средства и синтаксические конструкции, особенности метафорики и звуковая организация текста, предпочитаемые стихотворные размеры и взаимоотношения с литературной традицией – из всего этого и складывается сакраментальная творческая индивидуальность.

И тут приходится признать – большинство переводов Кандалый выполнено в соответствии со сложившимся в советские годы стандартом «условно-поэтического восточного перевода». Отдельные остроумные отступления от канона – скажем, выполненное Л. Пеньковским переложение александрийским стихом сатирического стихотворения «Мулла и его жена» – свидетельствуют скорее о знании переводчиком русской поэтической традиции, нежели об особенностях поэтики переводимого автора. Смелое сопряжение в рамках одного стихотворения высокого стиля и просторечий, архаических конструкций и народных поговорок, арабизмов и разговорного языка, словом, всё то, что делает Кандалый поэтом-новатором, оставалось вынесенным за скобки, лишая тексты классика последнего шанса на узнаваемость в ряду прочих.

Вхождение стихотворца в иноязычную литературу делится на две стадии: этап предварительного знакомства, для которого годятся произвольно рифмованные пересказы содержания, и этап возможно точной передачи специфики оригиналов средствами другого языка, обретения автором своего голоса в рамках иной культуры.

Благополучно миновав первую стадию, Кандалый вступает во вторую. И эта небольшая публикация – попытка представить русскому читателю не отретушированное лицо татарского классика.

Задача перед переводчиком стояла не из простых – необходимо было не только воспроизвести строфику подлинника с подчас весьма прихотливой системой рифмовки и передать по возможности авторскую просодию, но и подыскать адекватные средства воссоздания стилистических особенностей текстов Кандалый.

Татарский поэт творил в иной языковой и культурной реальности. Вполне естественно, что и по-русски он не мог заговорить, как наш современник, потому и переводы выполнены в соответствии с правилами грамматики и поэтики XVIII века. Арабизмам, привносящим в татарскую речь возвышенность и патетику, в русской традиции соответствовали церковнославянизмы, уже в XVIII веке выполнявшие аналогичную функцию, – к ним, по мере необходимости, и приходилось прибегать.

Разумеется, в задачи входило создать не только близкий к оригиналу, но и эстетически не ничтожный продукт, поэтому при общей ориентации на максимальную точность переводчику порою приходилось жертвовать буквальностью во имя поэтичности. Но в этих нечастых ситуациях он, по слову Гнедича, заменял «объявши сумму слов гомерических… иногда одно слово другим, у Гомера же находящимся», подбирая исключительно те выразительные средства, которые использовал сам Кандалый в переводимом стихотворении.

В заключении же хотелось бы выразить сердечную благодарность Рузие Сафиуллиной, без чьих подробнейших подстрочников и обстоятельных комментариев этот труд едва ли был бы возможен.

## Письмо о пользе силлабики

*...низок был бы я, кабы*
*В послании к другу не знал числить силлабы.*

В. Ходасевич

При переводе с языка, в котором укоренилась отличная от русской, силлабо-тонической, система стихосложения, неизбежно возникает вопрос – как передать звучание оригинального текста. В большинстве случаев проблема решалась путём

переложения первоисточника в традиционные метры. Не миновала чаша сия и татарскую силлабику.

Отдал дань такому склонению на русские нравы и автор этих строк в предыдущей публикации («Идель», 2012, № 12), извиняя себя лишь тем, что переводимые восьмисложники для непривыкшего к силлабике русского уха зазвучали бы, в лучшем случае, как тоника, а в худшем – как испорченная силлабо-тоника. Однако утрамбовать пятнадцатисложные дистихи нижеследующего стихотворения в восьмистопный хорей «Пьяного дервиша» означало бы угодить в известный исторический анекдот: Василий Капнист, не тем будь помянут, не оценив ритмической новизны державинской «Ласточки», провёл «работу над ошибками» и отправил автору его стихотворение, переписанное аккуратным четырёхстопным ямбом…

«Татарский Державин» также любил смелые ритмические эксперименты, завуалированные мнимой простотой силлабического мелоса. Данное стихотворение – отличная тому иллюстрация. Из восьми его двустиший ритмический рисунок не повторяется ни в одном, хотя определённая мелодия – то более, то менее явно – проходит через весь текст. Более того, порою можно говорить о своего рода скрытых строфах, поддерживаемых ритмическим рисунком и непредсказуемо возникающими внутренними рифмами. Так, в строфах, где лирический герой переходит от размышлений к наставлениям, угадываются очертания рубаи – игра со звучанием оборачивается игрой с жанровой традицией.

Не считая себя в праве пренебречь этим интонационным и смысловым богатством, переводчик в предлагаемом переложении попытался возможно близко воссоздать оригинальную ритмику татарского текста.

## Габдельджаббар Кандалый

* * *

Беспредельна была б любовь, не знай предела земля,
Не перестать любить, пока не возьмёт тела земля.

Побудил груди моей жар засесть за письмо меня,
Да узнаешь: пламя любви в чёрный угль сожгло меня!

Ну, душа моя, будет слёз, пусть и стучат ныне врозь
Наши сердца волей Творца – поскорей роптанья брось!

Чужим себя ты не дразни – иль после судьбу не брани,
От взоров и от ласк чужих себя, родная, храни!

Один простак свой земной путь абы с кем стал бы делить,
Сокровенное вряд ли кто с чужим желал бы делить.

Дивен двух сердец разговор, когда не подслушать их,
Чуден пышных цветов пожар, коль волчицы не душат их.

О, как ты прекрасна, мой свет, кто б равняться смел с тобой,
Разлучить, поверь, в мире нас под силу смерти лишь одной.

Пусть блудодеи в злобе мнят, что души лишат меня,
Что мне до них, коль Аллах повсюду охранит меня?

* * *

Учёность – тысячи карат
В душе взращённая звезда;
Спесь – хищный змий, что сыщет кров
В твоей могиле, как в гнезде.

Мудрец и в смертныя чреде
Нетлен пребудет, и везде
При жизни – в неге и в труде –
Почтен меж сограждан всегда.

Себя спесивец восхвалит,
Надмен, наукою презрит,
В порока бездны низлетит,
Страстьми растерзан без следа.

**Баит о чае**

Аллаха милостью святой
Сладчайших в свете яств не счесть,
Но мир подлунный обойди –
И всюду чаю равных несть.

Целебней снадобия несть,
Сколь польз сокрыто в нём – не счесть,
Голодному его испить –
Что снеди сытныя отъесть.

Коль в зной полдневный некий муж
Палящим солнцем оглушён,

То паки станет, выпив чай,
Умом и станом крепок он.

Быв мразом каверзным казним,
От хлада возымевши жар,
Да знает – хворь изгонит вмиг
С горячим чаем самовар!

*Свойства чая*

Исполнен бодрости самой,
Развеет дрёму, как не бысть.
Тот богатей на свете ист,
Кто чаем балуется всласть.

У самовара вспомни лишь,
По ком огонь в душе таишь –
Водой заливши чайный лист,
Любовну жажду утолишь.

Толь весел самовара свист,
Что вешня жаворонка весть,
На скатерть водрузи его –
И гостю взора не отвесть.

Пусть брашен праздничных не счесть,
Коль самовара с чаем несть,
Томится гость, угрюм лицем,
Укор тая, ни пьёт, ни ест.

Но подан чай – и вот уж он,
Что крин раскрывшись на водах,
К беседе сладкия зовя,
Щебечет, точно певчий птах.

Аллахум, чая не лиши
Рабов, смиренных пред Тобой,
А выпит весь – купить ещё
Ссуди монеткою-другой!

*Порядок чаепития*

Закон всему положен свой,
Трапезы чайной от меня
Прияв уроки – не зевай,
Мотай на ус, душа моя.

Опрежь иного – самовар
Пусть вознесётся над столом,
И, нежа взор, твоя любовь
Приспеет отразиться в нём.

Теперь не позабудь про мёд –
Тягуч и свеж, едва из сот,
По пиалам уже разлит,
Сребряной только ложки ждёт.

Мёд зачерпнувши, не спеши
Им усластить горячий чай,
Ведь, с мёдом смешан, станет чай
Совсем паршивым, так и знай.

Лишь та годится в чай вода,
Что токи резвы по земле
Струит к полнощи от полдня,
Верь слову лекаря – не мне.

Тут дивно присовокупить
Лимона драгоценный плод:
Кто чай свой сдабривает им,
Воистину, счастливец тот!

Коль соблюдён, сей правил свод
Сулит забав, услад сулит,
Падёт ярём сует дневных,
И дух отрадой воспарит.

Ну а повинный в сих словах
По праву значится в муллах,
Грехам прощение суля,
Радеет чаяньям Аллах!

* * *

Единожды цветку взрасти –
И в персть убор свой отрясти;
И косну сухость обрести,
Главу пред осенью склоня.

Вот так и жизнь твоя пройдёт –
Вотще цвет вешний опадёт,
Ланит румянец пропадёт,
Коль смладу скорбь гнетёт тебя.

СЛОВАРЬ АРХАИЗМОВ

Брашно – кушанье;
Крин – цветок лилии;
Паки – снова;
Персть – земля;
Полдень – (здесь) юг;
Полнощь – (здесь) север.

Сведения об авторе предисловия/переводчике:

*Алексей Саломатин – поэт, литературный критик, переводчик. Родился в 1983 г. в Казани, где живет до сих пор. Докторант кафедры русской литературы Казанского федерального университета. Публикует критические статьи в журналах «Арион», «Знамя», «Октябрь» и др.*

*Стипендиат Министерства культуры РФ (2012). Лауреат премии журнала «Октябрь» за лучшую критическую статью (2013). В 2014 году вошел в шорт-лист премии «Дебют» в номинации «эссеистика» с подборкой рецензий и статей «Критический минимум».*

## «Упаси от напастей лихих…»

*(Стихи Габдельджаббара Кандалый
в переводе Максима Амелина)*

*Предисловие*

Габдельджаббар Кандалый (1797–1860) – забытый классик татарской литературы XIX века. В советское время его поэзия была искусственно оттеснена на второй план. Однако сами стихи – лучшее свидетельство о поэте. В 1990-е годы вышли две книги, приоткрывшие завесу молчания, стали появляться исследовательские работы о его разнообразном поэтическом творчестве, глубоко укоренённом в традиционной татарской культуре, как устной, так и письменной.

Действительно, тематическое и жанровое разнообразие творчества поэта впечатляет: от духовных и философских стихов – до любовных и эротических, от высоких рассуждений и мусульманской книжной дидактики – до остроумного юмора и весёлой иронии. Всё это говорит о том, что Кандалый – крупный

и, вероятно, только по каким-то внелитературным причинам недооценённый поэт, которого стоит переводить, и не только на русский.

Национальный фольклор и арабская книжность – два неиссякаемых источника, из которых Кандалый черпал вдохновение. Для переводчика на русский язык, за свою многовековую историю впитавший разные традиции, но всё-таки во многом остающийся близким к европейской, именно это и представляет огромную сложность. Найти язык внутри языка, создать схожую систему образов, предложить метрические эквиваленты – непростая, но вполне осуществимая задача.

Эти переводы появились на свет благодаря Рузие Сафиуллиной, исследовательнице и пропагандистке творчества поэта. Недавно в журнале (Идель, № 12, 2012 г. – *прим. Р. Сафиуллиной*) были опубликованы и переводы, сделанные Алексеем Саломатиным по её же подробным и тонким подстрочникам. Хотелось бы, чтобы русскоязычный читатель не остался равнодушен к стихам поэта, так ярко и образно писавшего о сущностных вопросах бытия, так глубоко и точно выразившего несгибаемый дух татарского народа.

* * *

Распускающийся цветок
Обречён увянуть в свой срок, –
Облетел, пожух и поблёк,
Лишь осенней предан поре.

Всё, что живо, будет мертво:
От цветения твоего
Не останется ничего,
Коль измлада предан тщете.

* * *

Свет учёности – для души
Украшения нет ценней;
Мрак невежества – плоть твою
Под землёй терзающий змей.

Кто учён, и по смерти тот,
Обратившись в прах, не умрёт,
И при жизни ему почёт
По заслугам среди людей.

Кто невежествен, тот, надут,
Недостойным считая труд,
В развращённость впадёт и в блуд,
Раб ничтожный своих страстей.

* * *

О Аллах, Вселенную всю
Сотворивший мощью Своей,
Упаси щедротой Своей
От напастей меня лихих.

Утром ветры из стран иных
Достигают пределов сих.
– Есть ли весточки от родных? –
Расспросить пытаюсь о них.

– Эй ты, ветер, по чести честь
Расскажи мне, где они есть?
Не послали ль какую весть? –
Расспросить пытаюсь о них.

– Эй ты, ветер, вея везде,
Повстречал ли в чуждой среде
Мне любезных, когда и где? –
Расспросить пытаюсь о них.

– Эй ты, ветер, в каком краю
Ни отыщешь мою семью,
Не забудь молитву мою
Передать дословно для них.

– Эй ты, ветер, ринувшись в путь,
Не старайся так быстро дуть, –
О моей тоске не забудь,
Повстречав, уведомить их.

– Эй ты, птица, видишь, иль нет,
Высоко взлетая, иль нет,
Мне любезных сверху, иль нет? –
Расспросить пытаюсь о них.

– Эй ты, птица, где твой птенец?
Где твои и мать и отец?
С ними долго ль в разлуке ты?
Сколько ты не видела их?

Я тоскую по ним, – скажи, –
Как родной по родным, – скажи.
«Где вы, кто мной любим?» – скажи, –
Пусть звучит молитвой для них.

Если выйду я на простор
И древес увижу собор,
То, приблизившись к ним, в упор
Расспросить попытаюсь их:

– Много ль, древо, тебе годов?
Потеряло сколько плодов,
Так печалясь, как я готов? –
Расспросить попытаюсь их.

– Велико ль тех утрат число?
Сколько листьев ты растрясло?
Без ветвей стволу тяжело? –
Расспросить попытаюсь их.

Листья – молодости года,
Ветви – дети твои тогда,
А разлука – поверь, беда
Быть оторванным от родных.

От древес что услышишь ты?
Чем утешат тебя цветы?
Исцеленья от пустоты
Не найдя, я отстал от них.

Дальше мне писать, или нет?
Отойдёт напасть, или нет?
Сей напасти лихой навек
Из души пропасть, или нет?

Сведения об авторе предисловия / переводчике:

*Максим Амелин (родился в 1970 г.) – поэт, переводчик, издатель. Лауреат литературных премий: премия журнала «Новый мир» (1998), «Антибукер» (1998), «Anthologia» (2004), «Московский счет» (2004), Бунинской премии (2012), премии Александра Солженицына (2013). Автор книг стихов «Холодные оды» (1996), «Dubia» (1999), «Конь Горгоны» (2003), «Гнутая речь» (2011). Переводчик Катулла, Пиндара, Гомера и других древних и новых поэтов. Стихи переведены на немецкий, английский, французский, итальянский, польский, китайский, вьетнамский и другие языки.*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ БАРЫШЫ
## (Габделҗәббар әл-Кандалый)

*Җамал Вәлиди (1887–1932)*

Без тарихи әдәбиятымызда чын татарча нәзымнар язучыны эзләгәндә, иң элек Габделҗәббар әл-Кандалыйга очрыймыз. Буның заманында вә буннан элек, белмим, буның өслүбе илә нәзым язучылар булдымы икән? Әлбәттә, бөтенләй булмыйча булмас. Фәкать матбугатка чыгарлык булмагандыр, яхуд булып та һәрничек булса заигъ булгандыр.

Кандалыйның назымнары мәүзугъ җәһәтеннән бик тар вә бертөрле рәвештәдер, ул аларны үзенең мәгъшукаларына яза. Ул Кандалый исемле бер авылда мулла булып берничә кызга (әлбәттә, берсе соңра икенчесенәдер) гашыйк була вә шигырьләрендә шулар хакында язадыр. Габделҗәббар әфәнденең бу нәзымнары бездә, язсаң җилдләр тәшкил итәчәк «Чыктым басу капкасын, җәйдем киндер басмасын» һәм дә «Озындай озын бүрәнә, чанага салсаң сүрәлә» рәвешендәге сыйрыф гавами[1] җырлардан әллә кая өстен тора вә шуның белән бергә ул халыкныкы буладан да чыкмый, күз күрмәгән вә колак ишетмәгән вә һичбер аңлашылмый торган вә аңлашылуы мәтлуб тотылмаган[2] нәрсәләр илә чуалмый. Ул һичбер урында дип әйтерлек татар телен бозмый, гавамы фәкать һәркемгә аңлашылырдай ачык вә урынлы тәгъбирләрдән качмый, чит сүзләргә вә тәкәллефле тәгъбирләргә бик аз урын бирә; татарча сүзләрне бик осталык вә тапкырлык илән кулланадыр. Без анда яхшы гына куәи шигърия булганын сизәмез. Анда талант булган. Фәкать аннан тиешлечә файдаланырга заман вә әхваль мөсагыйд[3] булмаган, Габделҗәббар әфәнденең шигырьләрендә өч мәгъшуканың исемнәре очрый: Сахибҗамал, Бәдига, Фәрхи. Шагыйрьнең болар илә хакыйкатән дә мөнәсәбәте гашиканәсе булдымы? Яки болар хыялда ясалган сурәтләр генәме? Буны белә алмыймыз, шулай да әүвәлге ихтимал бик якын. Габделҗәббар әфәнденең назымнарында шигърият куәтле түгел. Шулай да булса без татарча күрдекемез иң элеккеге бу мәгънәле вә фәсыйх нәзымнарга әһәмият нәзары белән карыймыз вә ал арга бер мәүкыйг ихтирам бирәмез.

---

[1] Сыйрыф гавами – саф халыкчан.
[2] Мәтлуб тотылмаган – таләп ителмәгән.
[3] Мөсагыйд – мөмкинлек.

Габделҗәббар әфәнденең мәгъшукасы Сахибҗамалга хитабән язылган нәзымнары шөйлә башлана:

Сәңа, җаным, дога итдем, дога илә сәлам әйтдем,
Сәламнәрең соңы, җаный, язып гозре кәлям[1] итдем.
Сахибҗамал, чибәрем лә, и матурым, сөярем лә,
И белмәдем нидәрем лә, сагышыңны мәдар иттем[2].
Гүзәлсең алтын алмадай, җәмалың күңелем алдадый.
Түзәр хәлем дә калмадый, алай да күп чыдар иттем.

Соңра шагыйрь, мәгъшукасенең үзенә килмичә бер кара мужикка китеп әрәм булуыны ярым куркыту, ярым ялыну тарызында ихтар итә[3] вә мужикның тормышыны һәм хатынына мөгамәләсене тасвир итеп диядер:

Иман сүзен дия белмәс, дине сартын[4] көя белмәс;
Бикәч диеп сөя белмәс – барырсың андый фасикъка[5].
Бу хәл илә – гомер буйлай кулыңдин эшләри куймай,
Йөрерсең тамагың туймай, ки бәгъзе чакта ачлыкка.
Борынгылар шулай димеш: балыкчының күте юеш,
Тамагы ач булыр имеш, тотыш йөрсә дә балыкка.
Сука белән сабан сөреп, тузан-туфрак үзә йөреп,
Каралубән килеп кереп, ки охшап кара калмыкка.
Изеп, атына болгатып, арыдым диеп, тиз үк ятып.
Оеса, булмас уйгатып, башын бер куйса ястыкка.
«Сукаладым, арыдым», дир, «увалдым», дир, «арыдым», дир,
«Каты йиргә тарыдым», дир, – «сарутлык» я «тамырлыкка».
Ирең сөймәккә теләсәң, «Кил уйнаек», ди сөйләсәң,
Үбеп, кочып та көйләсәң, бер ай тулганда тансыкка,
«Йөремә!» диде ырылдап, тиз үк әйләнә пырылдап,
Ятып та йоклый гырылдап, ки һич ял иткәне юкка.
Янә сөймәс бер аенда чытып чиркен[6] чыраен да,
Качып печән сараенда ятырга китә аулакка.

Әгәр дә Габделҗәббар әфәнде бу нәзымнарыны мәгъшукасе Сахибҗамал абыстайга хитабән[7] язмаса иде, без аны хакыйкатән

[1] Гозре кәлям – үтенеч сүзе.
[2] Мәдар итү (мәдам итү) – дәвамлы, чиксез итү.
[3] Ихтар итә – дикъкатен тарта, искәртә.
[4] Сартын – хакында, өчен.
[5] Фасикъ – әхлаксыз, бозык.
[6] Чиркен – яман, начар.
[7] Хитабән – сүзне юнәлтеп, эндәшеп.

хатыннар хокукын химая итүче вә аларның хөрриятен теләүче диеп карар вә аның бу нәзымнарына Тукаевның:

Кич булгачдин үзе тагы эчеп кайта,
Авызы-борыны сасып, өст-башын тынчып кайта.
Яткызмакчы булсаң, кулыңнан ычкына,
Тәмсез сүзләр сөйли, сүгенә, кычкыра,

лары илә бер рәткә куяр идек. Фәкать Кандалый хәзрәттән хәзерге шагыйрьләремездәге (гуманность) вә (феминизм)ны беркем дә сорамас. Ул, теләсә ниндәй максат белән булса булсын, татар мужигының хатыны илә мөгамәләсене бик дөрест сурәттә тасвир кыладыр. Аннан шуннан артыгыны дәгъва кылып булмый. Күп шагыйрьләрнең авызлары гыйшык җырлары илә ачыладыр. Нечкә билләр, аһу[1] күзләр, ай йөзләр, кыйгач каш вә шикәрле иреннәр – шагыйрьләрнең иң элекке илһамчыларыдыр. Соңра ул торган саен даирәи бәсарын[2] киңәйтә, бер яктан, аны «җанкай җанаш, каләм каш» кеби буш вә ялтыравыклы сүзләр туйдыра, ул тугрыда аңа артык материал да калмый, икенче тарафтан, үзенең мәүкыйгын (назначениесен) югарырак күрә башлый. Үзене тәрбия вә ихтирам иткән халыкка бурычлы икәнен вә бу бурычларның «кайсы тиркәм, тирләсә җанкам яңагындан чыга; сәлсәбил[3] шул инде фирдәвес[4] багыннан чыга», дип көйләү илә генә үтәлмәгәнен сизә. Аны хәзер шул заманның бөек гакылларыны ишгаль иткән[5] мәсьәләләр китереп кыса. Аны хәзер җанкәсенең яңагына кунган чебен борчымый һәм ул ходайдан шул чебен булырга сорамый, аны хәзер халкының иҗтимагый вә икътисадый тигезсезлекләре, кимчелекләре, һәртөрле әхлакый, мәдәни, игътикадый, фәлсәфи төеннәр борчый, ул ходадан шул төеннәрне чишүен сорый.

Фәкать без күп вакытта шагыйрьнең иң элеккеге куәи шигъриясе илә бергә ачылган гончәи[6] мәхәббәтнең үлгәнчәгә кадәр аны ташлап бетермәвене күрәмез. Бәгъзе бер шагыйрьләр бөтен дөнья вә ма фиһадан[7] ваз кичеп бөтен шигырьләрене Аллаһ

[1] Аһу – газәл (матур күзле кыр кәҗәсе).
[2] Бәсар – күз күрүе.
[3] Сәлсәбил – бик тәмле су, җәннәттә суы бик тәмле чишмә.
[4] Фирдәвес – җәннәт, бакча.
[5] Ишгаль иткән – биләгән.
[6] Гончә – ачылып җитмәгән чәчәк, чәчәк бөресе.
[7] Ма фиһа – аның эчендә булган нәрсә.

гыйшкы илә көеп, янып язалар вә шунда да алар үзләренең җанкәләрене онытмыйлар. Безнең Тукаев та үзенең шагыйриятене «җанкай җанаш» белән башлады, вә соңра киткән саен без аның буннан ераклашканын күрәмез, ләкин ул һаман аларны ташлап бетерми. Үзе бушбугаз мәддахлардан[1]:

Ошбулар язган шигырьнең бик кызык шигърияти
Һа, имеш, йолдыз тәти, солтан тәти, кызлар тәти, –

диеп көлә торып, үзенең диванында шушы кыйтганың астында да, өстендә дә шундай ук тәтиләр хакында язадыр. Аерма шунда гына, Тукаевның язган тәтиләре йолдыз һәм солтан түгел. Әгәр дә бер кеше чыгып, Тукаев кеби шагыйрьләр хакында:

Ошбулар язган шигырьнең бик кызык шигърияти
Һа, имеш, куллар тәти, битләр тәти, күзләр тәти –

дисә, безнең бөек шагыйремез ни диер иде икән?

Габделҗәббар әфәнденең бунда тагын берничә гүзәл назымнарын язмыйча китеп булмый.

Парау илендә төш күрдем ки – бер кош тоттым, ук аттым.
Парау илендә бер матур өчен уйкумны югалтым.
Ничә кемсә ничәләрдә ашыйлар да, эчәләр дә,
Ки бән шул көн кичәләрдә аш үтмичә елап яттым.
Сезә булдым барыр кеби, сәңа юлда тарыр кеби,
Сөеп-кочып арыр кеби – хыял дәрьясына баттым.

---

Бере Сок та, бере Сак та – икесе дә ике якта,
Моңаеп егълаган чакта, еламый һич түзеп булмай.
Бере Сак диюбән сызып, моңаеп йибәрә сузып,
Икенчесе дәхи кызып, моңаеп Сок дәйү егълай,
Ишетеп аңла бу сүзи, ходаем сакласын үзи.
Болар тик итмәсен бези, юк исә халь начар бугай.

Габделҗәббар әфәнде үзенең шигырьләрендә халык мәкальләрене һәм халкың фантазиясендә мәүҗүд[2] булган нәрсәләрне кертеп әсәренә никадәр гүзәллек бирә вә үзенең чын-чын халык рухлы бер татар идекене күрсәтәдер.

---

[1] Мәддах – бик артык мактаучы.
[2] Мәүҗүд – бар булган.

———

Саба җиле исәр булсаң, Парау атлыйг нәфис җайга
Сәламемне йиткергәйсең Сахибҗамал абыстайга!
Ин нулта йа рих ас-саба йауман или әрзи-л харам
Баляга сәлами раудатан фиһа ән-нәби әл-мөхтәрәм[1].

Габделҗәббар әфәнде шигыре илә соңгы гарәпчә шигырьне фәсахәт вә бәлягатьтә[2] бер-берсенә якын китереп буламы? Бунларның кайсы артыграк? Гарәби вә төрки әдәбият илә мәшгуль затларның дикъкатьләрен җәлеп итәм.

Гөлем бул, гөл егачым бул, я былбыл-сандугачым бул,
Бу дәрдемгә гыйлаҗем бул, Сахибҗамал абыстай ла.
Әгәр мужикка барсаң:
Алыр сырт каешың телеп, ки мин һәм ишетеп белеп,
Йибәрермен язып көлеп: «Менә Сахиб! Кияү сайла!»

———

Исем китә бу каләмгә бу ел басканда кадәмгә
Язып һәр бәни адәмгә чыгарды сереми фашка.

Мин Габделҗәббар әфәнденең бу бәетләрен бик кечкенә чагымнан бирле беләм. Мин аны 8–9 яшьләремдә икәндә авыл мәдрәсәсендә торганда, әллә ниндәй бер кечкенә генә китапта укыйдыр идем төсле. Берникадәр мисраглары бөтенләй исемдә калган. Ләкин ул кечкенә китап, белмим, ниндәй китап булгандыр. Хәзерге шигырьләрне исә Каюм Насыйриның «Фәвакиһелҗөләса»сеннән күчереп алдым, һәр нә исә Габделҗәббар әфәнденең бәетләре, үзе әйткәнчә, бөтен татар арасына таралган булырга охшый. Ул үзе буннан алтмыш еллар элек вафаттыр. Үзе исән вакытта болар басылып таралдымы? Яки басылмыйча язылып таралдымы? Яки фәкать буның гыйшкы хакындагы хәбәрләр генә таралдымы? Буны, әлбәттә, картрак әдипләремез белерләр. Элегрәк заманнарда бездә матбугат булмыйча вә халыкның берbegin бере илә аралашуы аз була торып, шундай әһәмиятсез генә вакыйгалар берничә губерна аша таралганнар вә бөтен татарлар арасында дастан булып киткәннәр. Бундай вакыйгаларның болай

———

[1] Саба җиле, әгәр дә син изге җиргә барып җитсәң,
Минем сәламем мөхтәрәм пәйгамбәр йөргән бакчага да барып ирешер.

[2] Фәсахәт вә бәлягать – сүздә, язуда булган ятышлы, матур тулылык, гомумән матурлык.

шөһрәт тотуына сәбәп – асыл вакыйга булмыйча, алар хакында язылган бәетләр була. Мәсәлән, Бөгелмә шәһәрендә бер Хәбибҗамал исемле купең кызының җиңгәсене суеп Себер китүе хакында, һәм дә Чистай өязе Адәмсуы иленең мәсҗедене яшен бәреп яндыруы тугрысында булган бәетләрне безнең Тәтеш өязендәге авыл мәдрәсәләрендә һәммә шәкерт яза вә бик күп җырыны күңелдән беләдер. Бездә авыл мәдрәсәләрендә әүвәлдә бәет чыгару бик модада иде. Мәдрәсә эчендә яки авылда, яки күрше авыл тирәсендә бер әһәмиятлерәк вакыйга булса, мәсәлән, берәү суга төшеп яки утка янып үлсә, берәү солдатта яки ничек тә булса еракка китеп үлсә, берәү нахактан Себер китсә, яки төрмәгә керсә, бундайлар хакында мотлакан[1] авыл шәкертләре тарафыннан бәет чыгарыладыр. Шулай ук угырлау, кеше үтерү, яки ят җегет, яки хатын белән тотылулар да бәетсез калмыйлар иде. Бу бәетләрнең күбесенең асылы бер булып, шул «Хәбибҗамал бәете» яки «Төрек сугышы бәете» кебек гомумирәк булганнардан үзгәртәләр иде. Әгәр дә шәкертләр арасында талантлыраклары булса, үзләре тарафыннан да күп нәрсәләр иҗат итеlә иде. Мәсәлән, әлеге «Хәбибҗамал бәете»:

Тарих мең дә сикез йөз дә ...нче ел эчендә
Хәбибҗамал Себер китте унйиденче яшендә, –

диеп башлана.

Безнең авылда суга төшеп үлгән «Кәзү бәете» дә шулай ук:

Тарих мең дә сикез йөздә ...нче ел эчендә
Кәзү мискин суга төште 41 нче яшендә, –

диеп башланадыр.

«Хәбибҗамал бәете»ндәге:

Безнең ындыр артына боздан бәке уеңыз,
Бу дөньяга бала килсә Хәбибҗамал куеңыз

дигән бәет Кәзү бәетендә:

Безнең ындыр артына боздан бәке уеңыз,
Бу дөньяга бала килсә Кәзү атлы куеңыз

сурәтендә әйтеләдер.

Бу бәетләрнең күбесе шундай аластикый булып өстәгән вакыйга һәм кеше хакында әйтергә мөмкин буладыр. Соңра Габ-

---

[1] Мотлакан – шиксез, ничек булса да.

делҗәббар әфәнде үзенең сайлап-сайлап та тазга очравына үкенеп диядер:

Үземгә тапмадым тиңне – тик эстәп кашкалы, миңле,
Юлыктым аңлы да миңле, җүләр ярга, и җанкай ла.

———

Утырып саба җиленә очарым Парау иленә
Куеп кулымны биленә, кысып Сахибҗамалымны.
Билең нечкә кысыйм дисәм, буең зифа кочыйм дисәң,
Сәңа таба очыйм дисәм, кирәк баде[1] Сөләймани.

Аның Сахибҗамалга язганнары шуның белән тәмам була, соңра ул Бәдига исемле кызга язадыр:

Әгәр чынди мине мәхрүм итәрсең,
Күрәек ниндәй егеткә китәрсең.
Мәхәббәт булмасын барган йирендә,
Сафалар сөрмә һич барган ирендә.
Болыт тик кайгылар башыңа ягсын,
Тәәссефдин[2] күзләреңдин яшьләр аксын.
Этен сөргәндәй сөрсә иде катындин,
Җәфа күрсәтсә иде көндәш хатындин.
Я сөямен дип, алдап бер мут алсын,
Утырыр йиреңне баргач ут алсын.

Соңра Фәрхи исемле бер кызга яза:

Илтимасым[3] ошбу саба йиленә,
Бер хатым бар илтсә Борнай иленә.

Соңра шул ук Фәрхигә, ни сурәттә гашыйк булганлыгыны сөйли:

Тәрәзәдән караганда бер көни
Көн төшеп күрдем йөзенең күркени.
Күз каравың мәсәнни гошшак[4] икән,
Ике кашың гүя ике так[5] икән.
Сурәтең күргән кеше вәхия китәр
Гашыйк улып алдыңа сәҗдә итәр.
Көн дә сагыш, төн дә сагышың тотып
Би намазым, би ниязым ут йотып.

---

[1] Бад – җил.
[2] Тәәссеф – казага төшү, бәхетсезлек.
[3] Илтимас – үтенү, инәлү.
[4] Гошшак – гашыйк.
[5] Так – гөмбәз.

Сорыйсәнлә Фәхри, үткән кичәми,
Йоклыймынмы я сагышлап кичәми?

Бездә тагын бер «Чәй бәете» илә бер «Уңмаган килен» хакында бәет бар. Боларны Каюм Насыйри «Фәвакиһелҗөләса»дә язса да, кемнеке булганын зикер итмидер. Боларның өслүбләре югарыдагы нәзымнарга бик охшаганлыктан, мин боларның шул ук Габделҗәббар әл-Кандалыйныкы булуын гөман итәм. «Килен бәете»не бунда күчерү муафыйк күрелде:

Уңмаган булса килен, пешерә белмидер белен;
Тартып өзәргә телен – сүзгә шәптер тидия.
Ятадыр мисле бүре, торып ясамый шүре;
Ачуланмыйдыр ире яткан өчен тидия.
Иртә мичкә якмыйдыр, менеп морҗа ачмыйдыр;
Кайнатадин качмыйдыр, – оятсыздыр тидия.
Иртә сыер саумыйдыр, сачен тарап үрмидер;
Бер киләп җеп җерлидер[1] биш-алты көн тидия.
Ятадыр мисле туар, торса пешерә чумар;
Бәрсә, колагың тонар, – каты була тидия.
Болар ике килендәш, тора микән, бар, эндәш,
Ята мисле карендәш[2], – кузгалмасмы тидия.
Ялкау килен шушыдыр: эштән тизрәк бушыйдыр,
Мисле тивә күшидер ашаганда тидия.
Йитмәсә эш сайлыйдыр, коймакны күп майлыйдыр;
Бер оекны бәйлидер ун-унбиш көн тидия.
Рәхәт булсын аларга каймак өстен яларга, –
Хәзер тора танарга: «Капканым юк!», – тидия.
Кырга чыкса, юк урак; куя белмидер зурат;
Ятадыр мисле сурәт, ах-ах итеп тидия.
Мунча якса – бар утын, чыгармыйдыр һич төтен;
Күтәреп ята ботын кичә – көндез тидия.
Бәет булды тәмаме, яшь киленнең яманы –
Мисле атның чаманы эшләгәндә тидия.

*Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2010. 624 б. Б. 165–173.*

---

[1] Җеп җерлидер – җеп эрлидер.

[2] Карендәш – биредә: сүз ике килендәшнең ялкаулыкта «туганлашуы» хакында бара.

# ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ

*Хатип Госман (1908–1992)*

I

XIX йөз татар язучылары арасында Габделҗәббар Кандалый күренекле урында тора. Тик аның турында без аз беләбез әле.

Габделҗәббарның бабалары – Каракитә авылыннан (Татарстанның Чүпрәле районындагы авыл булуы мөмкин). Шагыйрь үз нәсел шәҗәрәсен борынгыдан бу заманга таба болай күрсәткән: Йосыф – Ибраһим – Биктимер – Ибниәмин – Габделмәҗит – Габделҗәббар. Габделмәҗит Каракитәдән Иртуган авылына (Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы) күчкән һәм монда муллалык итә башлаган. Габделҗәббар шушында дөньяга килгән. Иртуган авылын элегрәк «Иске Канадал» дип тә йөрткәннәр. Габделҗәббар, үсеп буйга җиткәч һәм яза башлагач, фамилия урынына «Кандалый» дигән сүзне әнә шуннан алган.

Габделҗәббарның яшьлек еллары турында мәгълүмат бездә бик аз. Халыкта сакланган истәлекләргә караганда, ул урта буйлы, җиңел сөякле, хәрәкәтчел, төскә-биткә коңгырт, зәңгәр күзле, кара чәчле кеше булган. Ул үзенең зиһене, тапкырлыгы, сүзгә үткенлеге белән аерылып торган, туры сүзне кистереп, кыю әйткән, шуңар да үз тиңнәре арасында күпләр белән тыныша алмаган. Башта атасыннан укыган, соңрак шул тирәнең билгелерәк Кизләү, Кышкар, Ыры, Шентала мәдрәсәләрендә булган. Шагыйрьлеге мәдрәсәләрдә укыган чакта башланган. Кышкар мәдрәсәсендә укыганда шул авыл мулласы турында ул «Мулла белән абыстай» бәетен язган. Бәет тиз арада телдән телгә күчкән, таралган. Мәдрәсә башлыклары, хафага калып, Габделҗәббарны бер көн үз каршыларына бастырганнар, үгетләгәннәр, тәүбә итәргә, язу-иҗат эшләреннән ваз кичәргә кушканнар. Ләкин Габделҗәббар тәүбә итмәгән, ваз кичмәгән. Шуннан соң аны мәдрәсәдән куганнар. Яшь шагыйрь мәдрәсәдән киткәндә үзенең кайнар хисле протест шигырьләрен язган.

Мәдрәсә шагыйрь көткәнне бирмәгән. «Анда күп гомер бушка үтте», дип, үкенеч белдергән шагыйрь. Шулай да аның таланты тик кенә югалмаган. Телләр өйрәнүгә һәвәслеге аркасында, ул рус, чуваш, мордва телләрен белгән, гарәпне һәм фарсыны өйрәнгән. Ыры мәдрәсәсе хәзрәте, гарәпкә һәм фарсыга осталыгын күреп, Габделҗәббарны башкаларга укытучы иткән. Телләр

белүе аркасында ул төрле халыкларның әдәбиятларын укый алган. Ләкин шунысы аяныч, ул замандагы тормыш шартлары аңар ахыр чиктә мулла булудан башка юл бирмәгәннәр: 1824 елда ул Иртуган авылында муллалык урыны алган, Гөлстан исемле кызга өйләнгән, бер-бер артлы биш баласы булган.

Габделҗәббар үз ишләре – муллалар белән тынышмаган. Ул атасы исән чагында аңар арка терәгән. Ләкин атасы 1840 елда үлгән. Шагыйрьне дошман күрүчеләр кыюланганнар. Башта: «Ул динсез, ул тәүфыйксыз, ул халыкны шәригать юлыннан яздыра, шигырь яза – шайтан эше белән шөгыльләнә», – дип, җәмәгатьчелекне аңар каршы котырткannар. Соңрак аның өстенә Әбүбәкер Әхмәров исемле берәүне мулла итеп куйганнар. Җәнҗаллы бу вакыйга турында бер язма сакланган: «Мәзкүр мәсҗеттә имам булды Әбүбәкер Әхмәр угылы. 1841 елда июньнең 14 көнендә мөнбәрә чыкты, хотбә укыды». Габделҗәббар һәм аның яклылар мәчетне ташлап чыкканнар: «Кире чыктылар: Мәннаф Ногман угылы, Хисаметдин Мохи угылы... карт мулла Габделҗәббар»[1]. Моңардан Габделҗәббарны үз күргән кешеләр булуы аңлашыла: алар, махсус мәхәллә аерып алып, 1843 елда аны шунда куйганнар. Бу хәлнең шагыйрь тормышына ничек тәэсир итүен әйтеп булмый. 1848–49 еллар тирәсендә Кандалыйның башына зур кайгы төшә: аның иң сөекле улы Садретдин солдат хезмәтенә алына. Ул заманда кеше, солдатка 21 яшендә алынып, өзлексез 25 ел хезмәт иткән. Бу бик зур бәхетсезлек булган. Шуңар күрә байлар үз урыннарына «наемщик» яллап җибәрә торган булганнар. Мулла була торып та, Кандалыйның иң сөекле улын солдат хезмәтеннән коткарып кала алмавы төрлечә уйларга мәҗбүр итә: я аның наемщик ялларлык байлыгы булмаган, яки ул моны теләмәгән, я аның куштаннар, чиновниклар каршында түбәнлек күрсәтәсе килмәгән, яки алар шагыйрьне дошман күргәннәр һәм аңардан үч алганнар.

Хезмәттә Садретдин рус телен бик яхшы өйрәнгән. Аны ефрейтор иткәннәр. Атасының шигъри хатларына ул да шигырьләр белән җавап биргән. Кызганычка каршы, аның бер генә строфасы сакланып кала алган:

Нә Шам эстәр, нә Истамбул,
Нә Мисыр, нә Бохар, Багдат,

[1] «Безнең юл» журналы. 1927. 8 сан. Б. 32.

Күңел даим тели, атам,
Сафасын шәһре Кандалның!

Бу юллардан Садретдинның белем дәрәҗәсен, романтик пафосын чамаларга мөмкин.

Шагыйрьнең тормышын күздән кичереп барганда, тагын бер факт игътибарны үзенә җәлеп итә: «Бән, Габделҗәббар ибн Габделмәҗит, Фәрхиҗәмал исемле хатынымны 1851 елда 3 гыйнварда хәлг кыйлдым. Имза: Габделҗәббар ибн Габделмәҗит»[1],– метрика дәфтәрендә әнә шулай диелгән. Сүз шагыйрьнең хатынын аеруы турында бара. Моның сәбәбе нәрсәдә икәне мәгълүм түгел. 54 яшьлек кеше үз гаиләсендәге мондый зур эшкә җиңел генә барыр дип әйтүе кыен.

20 нче елларда шагыйрь турында материаллар җыю белән шөгыльләнгән И. Бахтиев бер кызыклы мәгълүмат китерә. Кандалый «Сөбәтелгаҗизин» исемле китапка гарәпчә аңлатмалар ясаган һәм кульязмасы ахырына: «Зур авырлыклар күрергә, ике ел буена төрмәләрдә утырырга туры килде, шул вакыт менә шул китапны яздым»[2], – дигән юлларны өстәп куйган. Бахтиев, бу турыда патша администрациясенең берәр документы табылмасмы дип, Ульяновск шәһәренең архивында да тикшеренеп караган, ләкин нинди дә булса документ таба алмаган. Кандалый тормышындагы бу хәл кайчан, ни өчен булган? – Хәзергә бу сорауларга җавап юк. Киләчәк тикшерүчеләр моңар игътибар итәрләр, әлбәттә.

Шигырь остасы булу өстенә, Габделҗәббар төрле һөнәрләр дә белгән: кирәк чагында сабын кайнаткан, мич чыгарган, йозакачкыч кебек нәрсәләрне төзәткән, китаплар төпләгән.

Шагыйрьнең шәхесе һәм тормышы турындагы азмы-күпме игътибарга лаеклы белешмәләр шуның белән чикләнә. Дөрес, ул үлгәч, туган якларында аның турында анекдотлар, легендага охшашлы сөйләкләр барлыкка килгән. Аларда Габделҗәббар, күбесенчә, тылсым иясе, үткен телле сүз остасы итеп тасвирлана, шагыйрьнең талантына хыялый формада соклану белдерелә. Әлбәттә, алар шагыйрь биографиясенә турыдан-туры бәйләнә алмыйлар.

Татарча китап басу эшенең ул заманда Казан университетында яңа гына башланган чагы, һәм татар язучыларында үз

[1] «Безнең юл» журналы. 1927. 8 сан. Б. 31.
[2] «Яңалиф» журналы. 1929. 13 сан. Б. 14.

әсәрләрен бастыру гадәткә кермәгән була әле, Габделҗәббар да үз шигырьләрен бастырмый. Алар, борынгы гадәт буенча, күчереп алу, көйгә салып әйтү, ятлау юллары белән таралганнар; матбугатка килеп җитсәләр, имзасыз басылганнар. Мәсәлән, С. Күкләшевнең «Хикаят диван татар» (Казан, 1859) китабында Кандалыйның сигез юл шигыре имзасыз басылган. (Без аны «Аерма» дип исемләдек.) Шагыйрьнең туган якларында өлкән буын кешеләре, Кандалый исеме чыкканда, бу шигырьне әле дә хәтердән әйтеп бирәләр. 1881 елда Казан университеты нәшрияты «Мәгъшукнамә» исемле китап чыгарган. Мондагы күпчелек шигырьләр Кандалыйныкы. Ләкин алар имзасыз бирелгән. «Записки Оренбургского отделения Императорского географического общества»ның 1870 елда чыккан беренче китабында (Казан университеты басмасы) татар һәм башкорт җырлары урнаштырылган. Ләкин шунда халык җырлары исәбенә Кандалыйның ике йөз юлдан артыграк шигыре кертелгән.

Кандалый әсәрләрен басканда шагыйрьнең исемен беренче башлап атап әйтүче кеше Каюм Насыйри. Ул 1884 елда басылып чыккан «Фәвакиһелҗөласә» исемле китабына Кандалыйның мең юлдан артыграк шигырен урнаштырган һәм аларга, «имля вә иншасы байтак яхшы төзелгән» дип, бәя дә биргән. Әнә шуннан башлап әдәбият укучылар һәм фән дөньясы Габделҗәббар Кандалый исемле татар шагыйре булган дип нигезле рәвештә белә. Шулай да әдәбиятчылар шагыйрьнең «Фәвакиһелҗөласә»да басылган әсәрләреннән тыш яңаларын эзләү, барлау эшенә, ни өчендер, озак вакытлар керешмәгәннәр. Тик Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, 20 нче елларда, Гыйльми Үзәк эшкә керешкәч кенә, Кандалый иҗаты белән чынлап кызыксыну башлана. Шагыйрьнең җыентыгы төзелүе турында хәбәр ителә, әмма, ни өчендер, җыентыгы чыгарылмый. Хәзерләнгән материалларның язмышы безгә билгеле түгел. 1947 елда әдәбиятчы Б. Яфаров шагыйрьнең бер җыентыгын хәзерли. Ләкин ул да чыкмый кала. Аңарда тупланган әсәрләр, бәхеткә, күчермә аша булса да, безгә мәгълүм.

Шагыйрьнең үз кулы белән язган җыентыклары бөтенләй сакланмаган. Күчермә җыентыкларны тапкан кешеләр дә бу хәзинәгә саксыз караганнар, аны дәүләт карамагына тапшырмыйча, үз милекләрендә калдырып, югалтканнар. 1959 елның җәендә шагыйрьнең туган якларында безгә аның күчермә бер җыентыгын табарга мөмкин булды. Өлкән буын хәтерендә

сакланган әсәрләр дә язып алынды. Шунысын әйтергә кирәк: шагыйрьнең төрле чыганаклардан алынган бер үк әсәрләре арасында котылгысыз аермалар очрый: кайчакта аермалар зур да була, әсәр вариантлаша. Болар, әлбәттә, әсәрләрнең җанлы хәрәкәт белән яшәүләрен күрсәтәләр.

Эзләнү дәвам итәргә тиеш, шагыйрьнең әле без белмәгән әсәрләре табылыр.

II

Кандалый безнең әдәбиятыбыз өчен кай яктан әһәмиятле?

– Нинди **яңалык** китерсә, шул яктан.

XI–XIV йөзләрдә Идел буе төрки телендә зур-зур гына шигъри әсәрләр язылган. Идея юнәлешләре ягыннан алар арасында төрлесе бар: бер ишесе дини нәсихәт бирә, бер ишесе ерткыч ханнарны мактый, ләкин дәверенең бөек гуманист шагыйрьләре тәэсирендә иҗат иткән яки аларның әсәрләрен туп-туры төркигә күчергәннәре дә очрый. Әдәбиятның динигә һәм дөньявига бүленүе аермачык күренә. Дөньяви өлешнең үзендә ике юнәлеш сизелә: берсе – ханнар дөньявилыгын алга сөрә, икенчесе исә кеше тормышының иҗади мәгънәсен ачарга омтыла, хезмәт, фән, дәүләт белән гадел идарә итү кебек мәсьәләләргә кагыла. Бу соңгысына без Низами Ганҗәвинең (1141–1203 елларда яшәгән) Котыб тарафыннан 1342 елда фарсы теленнән Идел буе төркисенә күчерелгән «Хөсрәү вә Ширин» әсәрен мисал итеп китерер идек. Низами исеме белән бу әсәр бөтен дөнья тарафыннан танылган.

Казан туфрагында үсеп киткән татар әдәбияты борынгы Идел буе төрки әдәбиятыннан үзенә куәтле традицияләр алган, әлбәттә. Монда берьяклы фикер йөртүдән сакланырга кирәк: традицияләрнең дөньявисы да, динисе дә булган. XVII–XVIII йөзләрдә исә дини традицияләр өстенлек алганнар, дөньяви традицияләр кысылган. Мөхәммәт пәйгамбәр һәм һәртөрле «изгеләр» тормышын күрсәткән әсәрләр үрчегән. Кыска шигъри әсәрләрдә турыдан-туры дини нәсихәт бирү, суфи булырга өндәү төп урынны алган. Мондый хәл язма поэзияне җанлы тормышның үзеннән килә торган яңа тойгылардан, яңа фикерләрдән кискен аерып куйган, аның баю һәм үсү чыганакларын бикләгән.

Шушы урында мәйданга Габделҗәббар Кандалый чыга. Ул, беренчедән, борынгы дөньяви поэзия традицияләрен яңарта,

икенчедән, аларны үз заманы биргән яңалыклар белән баета. Суфи шагыйрьләр үз иҗатлары өчен эчтәлек чыганагын дини өйрәтмәдә күрсәләр, Кандалый моңардан ваз кичә. Ул үз иҗаты өчен яңа чыганак ача: бу – кешенең үзе, кешенең үз тормышы. Теге шагыйрьләр белән чагыштырганда, аның төп яңалыгы әнә шунда – үз заманындагы татар язма поэзиясендә, аллачыл принципны җиңеп, кешечел принципны куәтләп, үстереп җибәрүендә. Аның безгә мәгълүм булган әсәрләрен, тулаем яки теләсә нинди генә шигырен аерым алып карасак та, без анда кешене, җанлы кешенең хис-кичерешләрен, уй-фикерләрен, шатлык яки кайгыларын күрәбез, һәр очракта уртада кеше шәхесе тора. Шулай да нинди кеше соң бу? Үзенең иҗтимагый хәле ягыннан хезмәт ияләренең, ярлы крестьяннарның вәкиле түгел, ул авылның мөлкәтле катлавыннан. Ул җәмгыятьнең изелүчеләргә һәм изүчеләргә бүленүен турыдан-туры гаепләми, хәтта әле үзенең мөлкәтле катлаудан булуы белән кәпрәя, ярлы катлау кешеләрен, түбәнсетеп, «мажиклар» дип атый. Шулай да бу мөлкәтле катлауның теләсә нинди вәкиле түгел, бәлки яшь вәкиле – яшь кеше, үз мохиты яшьләре арасында заманына, шартларына күрә алдынгысы, борынына ис кергәне, фикере ачыла башлаганы. Аңарда үз катлавы реакционлыгының бер ягы белән конфликт туып килә: ул, үтә сизгер хис кешесе буларак, кичерешләрендә үзен дин кагыйдәләре белән чикләп тормый, рухи мөстәкыйльлеккә, рухының дини схоластикадан бәйсез булуына омтыла, дөньяны киңрәк һәм тирәнрәк танырга тели. Югарыда без Габделҗәббарның, схоластик хәлфәләр белән килешә алмыйча, мәдрәсәләрдән куылып йөрүен искәрткән идек. Аның шул чакта язган «Җен, Иблистән дә битәрмен» шигырендә түбәндәге юллар бик кызыклы:

Тарсынма бер дә, китәрмен:
Җен, Иблистән дә битәрмен,
Үз белгәнемне итәрмен,
Ки әгълә-гаршә ашкындым!..

Кусагыз да, һич уфтанмам,
Язуымнан да тукталмам,
Котылмассыз барыбер сез,
Әле болай гына калмам:

Төреп чалма-чапаннарны,
Йөресәм кыр-япаннарны,

Онытмам сез наданнарны,
Элеп салмыйча һич калмам!

Күренә ки, Кандалый дин башлыкларының иң әшәке сыйфатларыннан итеп аларның наданлыгын саный, шушы яктан үзен аларга каршы куя, үзен алардан өстен тоя. Дини фанатизм котырынып, җен яки Иблис исеме ишетелгән саен аять укырга керешелә торган бер заманда яшь шагыйрь буйсынмауда үзен җенгә, Иблискә тиңли, хәтта алардан да битәррәк булуын әйтә, гарше-әгъләгә ашкынуын, ягъни алланың үзе белән бер биеклеккә омтылуын белдерә. Бу инде шәхеснең фанатизмга каршы күтәргән ялкынлы бунты, кешегә рухи мөстәкыйльлек яулавы. Икенче шигырендә Кандалый схоластик мәктәпләрне тулаем хөкем итә:

Ничә еллар гомер сөрдем,
Даим мәдрәсәдә тордым,
Җаһиллегем[1] бүген белдем:
Йөрепмез гафләтә һәр ан[2].

Кандалый үзенең «наданлык»ка кискен дошманлыгын белдергәндә «гыйлемлек»нең эчтәлеген, аның нинди фәннәрдән гыйбарәт булырга тиешлеген туп-туры әйтеп салмый. Шулай да аның иҗатында төп пафос кешенең рухи мөстәкыйльлеген алга сөрү булуына таянып, гыйлем турындагы төшенчәсендә дә төп нәрсә гуманистик эчтәлектән гыйбарәт булырга тиеш ди алабыз. Аның иң күп язганы – кешенең матурлыгы. Бу мәсьәләдә дә ул дини фанатизм белән каршылыкка керә. Бер мисал китерик. Аның Фәрхисорурга багышланган әсәрләрендә мондый юллар бар:

Көн дә сагыш, төн дә сагышың тотып,
Бинамазым, бинияэым ут йотып,

Аллаһ-әкбәр дип әгәр каксам колак,
Сурәтең күңлемә уладыр кунак.

Та сәлам биргәнчә, и Фәрхисорур,
Кан кеби буыннарымда тик йөрер.

---

[1] Җаһиллек – наданлык.
[2] Йөрепмез гафләтә һәр ан – гел юкка йөргәнбез.

Шагыйрьнең эчке дөньясында кызыклы хәл: гыйбадәт вакытында ул үз күңелен бөтенләе белән аллага багышларга, аллага юнәлдерергә тиеш иде. Башкача итсә, көфер, гөнаһ була. Ләкин, аллага коллык хисен җиңеп, шагыйрь күңеленә Фәрхисорур килеп керә, керә дә аның бөтен җанын, хисен, күңелен берүзе биләп ала, хәтта бөтен барлыгына үтеп, кан кебек, буыннарында йөри башлый. Дини хис асылда юкка чыга, кешегә соклану, кешегә мәхәббәт хисе тантана итә. Әлбәттә, мондый кичереш ул заманда бер Кандалый күңелендә генә булып үтмәгән, тик башка кешеләр бу психологик хәлнең рәсемен сүз белән кәгазьгә төшереп күрсәтә генә белмәгәннәр. Кандалый исә дин ягы белән кеше ягы арасында шушындый эчке көрәшне бик нечкәләп, бик төгәл тотып ала алган да, аның рәсемен, нәфисләп, үтә дә чын, үтә дә ачык итеп, сүз ярдәмендә ак кәгазьгә төшергән. Монда аның гаять көчле художниклык таланты күренә.

Кешенең матурлыгы дигәннән Кандалый иң элек, әлбәттә, хатын-кыз матурлыгын күздә тота. Ул сөйгәненең буен-сынын, битен-йөзен, кашын-күзен сокланып тасвирлый. Соң болар тышкы матурлык кына түгелме? Бу сорауга «Белалмадым» шигырен күзәтү белән җавап бирик.

Килеп ирдем сәбәп берлә өеңә,
Күзем төште сәнең күркәм йөзеңә.

Күреп ирдем сәнең гөл йөзләреңне,
Ишеттем бал-шикәр дик сүзләреңне,

Дахи күрдем мөбарәк буйларыңны...
Белалмадым вә ләкин уйларыңны.

Шагыйрь кызның сылу буен, гөл йөзен күргән, сокланган, ләкин иң әһәмиятлесенә – кызның рухи дөньясы серләренә барып ирешә алмаган, – шунысы бик үкенечле булып калган. Кызның рухында, күңелендә ниләр бар икән? – менә иң әһәмиятлесе, иң кыйммәтлесе. Кешене, сөйгәнен, шагыйрь тышкы күренешеннән генә түгел, эчке, рухи дөньясы ягыннан да танырга тели, шуңар омтыла. Ни өчен? Чөнки ул үзе белән сөйгән кешесе арасында рухи тиңлек эзли. Аныңча, мәхәббәттә бәхетле булу өчен үз яратуың гына җитми, әле тагын яраткан кешеңнең сиңа карата да шундый ук уйда булуы кирәк. Шушы хәл аның әсәренә гуманистик җылылык һәм шигъри матурлык бирә дә.

Ул заманда татар язма әдәбиятында хөкем сөргән суфичылык, аскетизм белән чагыштырганда, бу бик җитди казаныш, җитди яңалык. Кандалыйны моңар ирештергән сәбәпләр нәрсәдә? Әлбәттә, монда шагыйрьнең зур талантка ия булуы да үз ролен уйнаган. Ләкин бу мәсьәләнең бер ягы гына әле. Югыйсә Кандалыйга кадәр дә зур талантлар тумый тормагандыр, алар туган, ләкин аларның үзләрен күрсәтер өчен иҗтимагый тормыш шартлары өлгереп җитмәгән һәм алар, ул талантлар, үзләрен дөньяга күрсәтә алмыйча үтеп киткәннәр.

XVIII йөзнең 70 нче елларында ук татар язма поэзиясендә дөньяви, мәхәббәт шигырьләре күренгәли башлый. Мәсәлән, 1770 елда Бәшир бине Габдулла дигән кеше тарафыннан язып калдырылган түбәндәге юлларны гына карагыз:

Сәүдекем сәнең ядыңдин улдым инде бикарар,
Гыйшкың уты кыйблаюбдыр, һәрвакыт кыйлыр зарар.

Тәндә җаным гаҗиз улды гөл йөзең күрмәк өчен,
Һич тәкатем калмаюбдыр сән сәүкле яр өчен.

Хак тәгалә рузый кыйлсын кавышмакка, я гүзәл,
Ахры бер көн морадыйга етештүрсен, я гүзәл[1].

Ислам хорафатчыларының дәһшәтле хакимлеге әдәбияттагы мондый яңалык яралгыларына ул заманда юл бирми әле. Ләкин тиздән Емельян Пугачев җитәкчелегендә күтәрелгән крестьян сугышлары һәм анда татар халкының да актив катнашуы татар феодалларның да хакимлеген тетрәтә. 1812 елгы Ватан сугышы да халыкның тарихи активлыгын үстерә, татар халкының поэтик иҗатында да гражданлык мотивлары яңгырап китә. Руханилар дөньясына билгеле таркаулык керә башлый, яшьләр арасында дөньявилык белән кызыксыну үсә, суфичылыктан, аскетизмнан аерылу кискенрәк төс ала һәм Кандалый кебек каләм ияләре килеп чыгалар. Без аларның килеп чыгуы өчен кирәкле объектив шартларны үз тарихи эшчәнлеге белән халык хәзерли дип әйтә алабыз. Тарихи чынлык ягыннан бу шулай булса да, Кандалый кебекләр моның шулай икәнен үзләре, әлбәттә, аңламаганнар; киресенчә, үзләренең иҗат мәйданына чыгулары өчен юл ачкан халыкка алар, кимсетеп, «надан мажиклар» дип караганнар.

[1] Газизева З. Унсигезенче йөздәге татар мәдрәсәләрендә матур әдәбият // Безнең юл. 1927. 11 сан. Б. 36.

Шушы хәл аларның үзләрен бик тә каршылыклы итеп әверелдергән: суфичылыкны, аскетизмны кире кагулары белән алар прогрессив юнәлештә эш итсәләр дә, хезмәт ияләренә чирканып караулары белән реакцион идеяләрне гәүдәләндергәннәр.

Кандалый – мәхәббәт җырчысы. Ул үз иҗатында турыдан-туры социаль мәсьәләләрне күтәрми. Ләкин аның мәхәббәт җырында тормыш чынлыгы бар, реализм көче күренә: шулай булгач, ул вакыт-вакыт иҗтимагый тормыш картиналары каршына килеп чыкмыйча кала алмый, максаты бүтән булса да, ул аларны тасвирлап үтәргә мәҗбүр була. Мәсәлән, ул күп кенә әсәрләрендә кешенең матурлыгы һәм колларча авыр хезмәтнең бу матурлыкны җимерүе мәсьәләсенә туктала, көнкүрештәге, гаиләдәге рәхимсез патриархаль, дини гореф-гадәтләрнең хатын-кызны ничек изүен, таптавын, имгәтеп, тәмам гарип-горабәгә әверелдерүен, тәмам кешелектән чыгаруын күрсәтә. Шушылар уңаенда ул безнең алдыбызда рәхимсез чынлыгы белән крестьянның авыр хезмәте, шыксыз көнкүреше картиналарын җәеп җибәрә. Бу яктан бигрәк тә «Сәхипҗәмал» әсәре кызыклы. Монда крестьянның хезмәте «бояр колыныкы» белән бер булуы, мондый хәлдә хатын-кызның да

Көне-төне кулы эштә,
Үзе зур каты тел-тештә

икәне күрсәтелә. Аның «Кара колтик» исемле икенче әсәрендә без мондый юлларны укыйбыз:

Ки көз көне дә кыш көне –
Мужикның бары да эш көне;
Буламы елда биш көне
Тыныч, эшсез, Җәмиләкәй?

Җәен жарга[1] тәнең пешеп,
Дәхи дә кыш көне өшеп,
Битең, борның, башың шешеп,
Катып-туңып, Җәмиләкәй,

Кадерсез шулкадәр йортта,
Кичә, көндез дә һәм иртә
Агыр эш эшләп биретә,
Кара кол тик, Җәмиләкәй.

[1] Жар – эссе, кызу.

«Сәхипҗәмал» поэмасында шагыйрь әнә шундый «кара кол»-лардан берсенең коточкыч фаҗигалы хәлен киң күләмдә тасвирлап бирә («Аның кебек була күрмә»). Әйтергә кирәк, XIX йөз башындагы татар крестьян хатын-кызлары тормышының авыр күренешләрен болан чынлыклы итеп тасвирлаган әсәрләр татар язма .поэзиясендә Кандалыйга кадәр юк иде. Бу ул китергән яңалык булып тора. Сәхипҗәмалның язмышы да соңрак барыбер шундый ук хәл белән беткән. Ул Парау авылының умартачы Сәйфетдин кызы булган. Кандалый күпме генә өндәсә дә, ул аңа бармаган. Тагын башка бик күп егетләрнең йөрәген яндырган. Ләкин ахырда бу тәкәббер кызны атасы Парау авылының Пәскә исемле тол калган бер кешесенә тотып биргән. Анын мондагы тормышы ничек булганын күз алдына китерергә мөмкин: беренче баласы Ногман туып, озак та үтмәстән, Сәхипҗәмал 25 яшендә дөнья куйган[1].

Колларча хезмәтнең хатын-кызны имгәтүен, гарипләндерүен һәм, иртә картайтып, вакытыннан элек кабергә тыгуын Кандалый дөрес һәм кыю сурәтли. Аның бу эше, һичшиксез, уңай яктан тәкъдир ителергә тиеш. Ләкин хатын-кызның, гомумән хезмәт иясе крестьяннарның, бу фаҗигалардан котылу юлы кайда? – Шушы зур мәсьәләгә килеп терәлгәч, Кандалый бик тар һәм көлке бер караштан чыгып җавап бирә: чибәр кызлар мужикка бармаска, иле-көне җитеш муллага, укыган кешеләргә барырга тиешләр. Моңарда без Кандалый карашларының чикләнгән, примитив һәм тискәре якларын үтә дә ачык күрәбез. Ул социаль тормышны үзгәртү мәсьәләсен куя алмый, моның өчен татарларда ул чагында демократик иҗтимагый фикер дә өлгереп җитмәгән була әле. Ул фикер соңрак өлгерде, социаль тормышны үзгәртү мәсьәләләрен көн тәртибенә бүтән тарихи чор тудырган яңа кешеләр куйды. Кандалыйның төп уңай эше исә аскетизм чылбырын өзеп чыгуда булды. Ул моны «гаять бөек әхлакый прогресс» – «хәзерге замандагы индивидуаль җенси мәхәббәт»[2] тойгысын җырлау аша эшләде, әсәрләрендә бу тойгының кайнарлыгын, матурлыгын ачты, шуның белән XIX йөз башындагы барлык бүтән татар шагыйрьләреннән аерылып, өстен булып торды.

---

[1] «Яналиф» журналы, 13 сан, 14 бит, 1929 ел.

[2] Маркс К., Энгельс Ф. Сайланма әсәрләр: ике томда, рус телендә. Т. II. 1948. Б. 215.

## III

Кандалыйны, шагыйрь буларак, газаплаган мәсьәлә – үзенең тирәннән килгән кайнар хисләрен, тулы куәте белән икенче кеше күңеленә илтеп җиткерү, алай гына да түгел, аны да дәртләндереп, аның да күңел түреннән шундый ук хислар ташытып чыгару, нәтиҗәдә ике кеше арасында рухи халәт уртаклыгына, рухи тиңлеккә ирешү мәсьәләсе. Ул сүзнең шундый эшне башкара алырлык шигъри куәтен эзли, хисне, тойгыны үзенә тутырып, шигырь юллары буйлап йөгертеп алып китәрлек чаралар табарга тырыша. Ислам дине мифологиясе рухы белән сугарылган язма поэзия мондый чараларны хәзерләмәгән, бу аның хәленнән дә килмәгән. Ә менә дөньяви рухтагы элекке поэзиядә мондый чаралар эшләнгән булган. Кандалый аларның байтагысын, традицион чаралар буларак, үз поэзиясенә ала. Моның бер карауда ук күзгә ташланып торган дәлилләре бар. Алыйк Котыбның «Хөсрәү вә Ширин»ен. Дөньяның матурлыгына соклану бу әсәрдә урыны-урыны белән гаять җанлы тасвирларда гәүдәләнгән. Әсәрнең геройларыннан берсе Шауыр, Ширинне эзләп, Әрмәнстанга килеп чыга, аның алдында бу илнең хәйран калырлык язгы, матур картинасы ачыла:

Йитеп килде языйлар, таглар аша,
Кыйлу тагларга-ташларга тамаша,

Күрер кем: тагъ үзәрә хуш чәчәкләр
Ачылмыш, зәндавачлар каршы сайрар;

Килеп яз көннәр, ул кызлар уш анда
Тамаша кыйлыр ирмешләр хуш анда;

Бу Шауыр йитмеше вакытында таглар,
Чәчәк ачылып, яшәрмеш ирде багълар,

Алып ташлар, чәчәкләр язгы рәнге:
Бере саригъ, бере ал, бере зәңге...[1]

Котыбның тасвир юнәлеше бу юлларда ук күренә. Без Кандалый белән чагыштырмалы мисаллар китерик. Котыбта:

---

[1] Котыб. Хөсрәү вә Ширин. Варшава, 1958. Факсимиле – 30 бит, транскрипция – 49 бит. Сүзлек: *язый* – дала, *кыйлу* – кыйлып, итеп, *уш* – инде, *рәнге* – төс, *зәңге* – зәңгәр.

Янә сүз айгучы ир мондаг әйде,
Сүзенең енҗүсен галәмгә йәйде[1],

Кандалыйда:

**Агыздан енҗүләр** сачып,
Сөйләш дәю бәян иттем.
(«Сәхипҗәмал»).

Котыбта (сөйгәненең үлеп, кабергә күмелүе турында сүз бара):

Кара тупракка кермеш **тулун аем**...[2]

Кандалыйда:

Әя җаным, абыстаем,
Кызыл йөзең – **тулан аем.**

Котыбта:

Нә яздым, нә яман кылдым мән ахыр,
Кем **ул таш күңелең инде йомшамас бер**...[3]

Кандалыйда:

Бу сүзгә йомшар иде каты ташлар,
Бу йомшару һич тә синдин кәлмәз имди.

Котыбта:

Сәнең кайгуңда күңлем **кан-яшь еглар**[4].

Кандалыйда:

**Яшьләр түгеп, кан елыймын**
Сәне сагынган чагымда.

Котыбта:

Бу яңлыйгъ **гыйшкы илләргә яелде,**
Бу гашыйк булганын **ил барча белде**[5]

Кандалыйда:

---

[1] Котыб. Хөсрәү вә Ширин. Варшава, 1958. Ф. – 30 б., т. – 49 б.
[2] Шунда ук. Ф. – 138 б., т. – 182 б..
[3] Шунда ук. Ф. – 173 б., т. – 225 б.
[4] Шунда ук. Ф. – 194 б., т. – 252 б.
[5] Шунда ук. Ф. – 126 б., т. – 167 б. Сүзлек: *яңлыйг* – рәвешле.

Сәне бик каты сөйгәнем,
**Гыйшыкың берлә көйгәнем,**
Ни язганым, ни дигәнем
**Җәелеп беткән илләрдә.**

Котыбта (Ширинне тасвирлау):

**Йөзе көн дик, сачы төн,** алны ай ул,
**Күзе нәргис,** иңе гөл, күрккә бай ул[1].

Кандалыйда (Шәфгыйне тасвирлау):

**Сачың** кара ирер – **төндик,**
**Сачың** ара йөзең – **көндик.**

Яки:

Сылу әйләде үзеңне,
Тулы ай итте йөзеңне,
Итеп **нәргистәй күзеңне,**
Матур итте бигаяти.

Мондый мисалларны шактый дәвам иттерергә мөмкин. Тик бер нәрсәне онытырга ярамый: Кандалый, әлбәттә, бер шагыйрьдән, бер әсәрдән генә традиция алмый. Ул тулаем дөньяви рухтагы классик әдәбияттан традиция ала.

Моңа да дәлил китерик. Харәзминең«Мәхәббәтнамә»сендә (1354 ел) мондый строфа бар:

Сәламем гөлгә илт, **әй таң нәсиме,**
Кем ирер ай колы, әхтәр нәдиме.

**Сәламемне тикер** ул дилстанга,
Рәхимсез, бивафа җан вә җиһанга[2].

Кандалыйда мондый строфа бар:

Сәба йиле, исәр булсаң
Парау атлыйгъ нәфис җайга,
**Сәламемне тикергәйсән**
Сәхипҗамал абыстайга!

---

[1] Котыб. Хөсрәү вә Ширин. Варшава, 1958. Ф. – 26 б., т.– 44 б.
[2] Щербак Д.М. «Огуз-наме», «Мухаббат-наме». М., 1959. Б. 135.
Сүзлек: *таң нәсиме* – таң җиле, *әхтәр нәдиме* – саклаучының юлдашы, *дилстан* – йөрәкне биләүче.

Шагыйрь эшләгән бу эшнең мәгънәсе җитди: борынгы Идел буе төрки әдәбиятында туып та, ислам дине реакциясенең һөҗүме аркасында, әдәби процесстан өзелеп калган кыйммәтле дөньяви поэтик казанышларны ул, яңадан күтәреп, бу заман татар язма поэзиясенә китереп ялгый, борынгы әдәбиятта ирешелгән уңай казанышлар белән яңа заман татар язма поэзиясе арасына күпер сала.

Кандалый борынгы дөньяви поэзиянең уңай традицияләрен яңарту белән генә чикләнсә, әлбәттә, аз булыр иде. Ул алай гына калмады. Татар поэзиясенә аннан да бигрәк яңалык китерде. **Беренче яңалыгы аның героенда.** Аның герое борынгы легендалардан килә торган романтик персонаж түгел, бәлки шагыйрьнең үз заманында яшәгән тормыш кешесе. Бу аның иң кыйммәтле ягы. Шушы кешенең рухи дөньясын тулы ачып бирерлек чараларны Кандалый үз заманы теленнән, үз заманы төшенчәләреннән эзли. Ул халык теленә, халыкның телдән иҗат ителгән сәнгатенә дә мөрәҗәгать итә. Мондагы чараларда, халык теле фразеологиясендә ул үзенең хисләрен мөлдерәмә тутырып әйтерлек матур формалар, матур өлгеләр таба, ул да кешенең рухи дөньясына халык лирик җыры керә торган яктан килеп юл сала. Ул, билгеле, халык иҗатын топ-томал гына күчерми, бәлки аңардан сәнгатьчә фикерләү принципларын ала; үз талант көче белән баетып, аларны иҗади үстерә, аерым сурәт чараларының, фразеологиянең, традицион шигъри бизәкләрнең конкрет яңа функцияләрен ача. Мәсәлән, Агыйделне алыйк. Халык поэзиясендә ул борын-борыннан килгән күркәм образ. Ә менә Кандалыйга кадәр без татар язма поэзиясендә Агыйделне очратканыбыз юк. Шагыйрьнең өлкән кешеләр хәтерендә сакланган әсәрләре арасында «Рабиганың сагышлары» исемле бер әсәр бар. Хәтереннән әйтеп яздырган Рокыя Мөхәметова (Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы Кызылсу авылы) бу әсәрне үзе үк «Габделҗәббар бабайныкы»,– ди. Шигырьдән бер строфа китерик:

Сәба җиле белән шаулый
Агыйделнең камышлары,
Йөзләремә сары сукты
Рабиганың сагышлары!

Монда Агыйдел образы безнең алдыбызга үзенең көче-куәте, шигъри матурлыгы белән ташып килеп чыга.

Сәнең буең – Агыйделнең камышы,
Сүләгән сүзләрен, былбыл тавышы! –

кебек юллар турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Кандалыйның әсәрләре шулай ук халык фразеологиясеннән «эреп сарка йөрәк маем», «ике күзем – кызыл алмам», «фида җаным сиңа, җаный», «кыяфәтең, сыйфатың – суда кондыз» кебекләр белән бик бай итеп бизәлгән. Кайбер строфалар бөтенләе белән халык фразеологиясенә корылган:

Сән әллә әйтә торгансың,
Боңарга яр табылмас дип?
Үзем кебек берәү булыр,
Вә иллә гыйшыкым сәндә!

Поэтик сөйләменә тормыш көче кертердәй барлык нәрсәләрне ул ала. «Сайлаган тазга тарый», «шикәр-бал татлы дип, бармакны йотып булмый», «тавык төшенә тары керә», «егермесен унга саткан» кебекләр аның шигырьләрен бизәп бара. Алар өлгесендә шагыйрь үзеннән дә иҗат итә:

Гомер һәм чылтырап суккан сәгать тик:
Бу форсатлар үтәр тиз, йөгерек ат тик,

Якутлар табыладыр вакыт белән,
Вакытлар табылмыйдыр якут белән.

Бу кадәрлу катып каның,
Ни хәлгә түзәдер җаның?

«Аягың астында туфрак булыйм», «бер күрергә тилмерәм», «газиз гомрең җилгә койма» кебек фразеологик күренешләр Кандалый әсәрләренең тукымасын тәшкил итәләр. Монда да шагыйрь халыкныкы өлгесендә яңа фразеологик әйләнмәләр иҗат итә. Мәсәлән, «Тәнендин яра китмәде, күзендин кара китмәде» кебекләр. Моннан башка шагыйрь халык иҗатыннан күп санлы традицион сурәт чараларын ала: «зифа буй», «нечкә бил», «йөзең гөл», «кызыл алмам», «каләм каш», «йөзе тулган ай», «күзе – Зөһрә йолдыз», «камыш каләм», «көмеш йөзек», «арсландай егет» һ.б. Болар Кандалый әсәрләренең интонация төсмерен дә баета. Чыннан да аңар кадәр язган XVII–XVIII йөз шагыйрьләре, «китап теле» коллыгыннан чыкмаганга, ялыктыргыч нәсихәт авазыннан башканы белмиләр. Кандалыйда исә шигырь бер ярсый, бер сабырлана, бер әле кинаяле аваз белән яңгырый, бер

көлә һәм бер елый. Сез аның «Җен, Иблистән дә битәрмен» исемле әсәрен генә укып карагыз. Башта шигырь үкенеч катыш уйлану белән ага, соңга таба ярсый, ачу һәм нәфрәт ташкыны булып шауларга керешә. Яки «Фәрхисорур» төркеменнән «Гомрең үтәр» шигырен укып карагыз. Монда күңелен көрлек тойгысы тутырып торган берәүнең, тел тезгенен тотыбрак, сүзне сайлап-сайлап кына әйтүе һәм шунда да үзенең шактый хәйләкәр, җор кеше икәнен сиздереп куюы аңлашылмыйммыни? Боларга шагыйрь күп өлешендә интонация аһәңе аша ирешә.

Кандалыйның әсәрләрендә кешенең котын алу ниятендә китерелгән ислам дине мифлары бик сирәк очрый. Ә бит аңа кадәрге шагыйрьләрдә болар тулып ята, ләкин аларның язганнарында татар халкының борынгы заманда шушында – Идел буенда туган мифлары очрамый. Кандалый, киресенчә, язма поэзиягә, беренче буларак, җирле мифларны кертә. «Сәхипҗәмал» әсәрендә, мәсәлән, шүрәле телгә алына.

Ә менә аңарда, үз заманы хорафатчыларына ачуы кайнап, үзен аларга каршы, җен һәм Иблискә тиңләү бар.

Шагыйрь халыкта сакланган борынгы аң формаларын үзгәртә һәм алардан сурәтләү чаралары китереп чыгара. Мәсәлән, фигуралар төркеменнән риторик эндәшләр, риторик сораулар өлкәсендә ул шулай эшли. Дини әдәбиятта аллага туп-туры төбәп мөрәҗәгать итү тулып ята. Бу – мистик мөрәҗәгать. Халык мифологиясендә табигать күренешләренә мөрәҗәгать итү бар. Бу анимизм заманыннан калган ышану. Ул чагында кешеләр табигатьтәге барлык нәрсәләр дә, хәйваннар гына түгел, чишмәләр дә, җилләр дә кеше кебек үк ишетә, тоя, рәнҗи, яхшылык яки явызлык эшли ала дип ышанганнар. Тарихи үсеше нәтиҗәсендә халыкның дөньяга карашы үзгәргән, табигать күренешләренә мөрәҗәгать итүләрнең ул функциясен алмаштырган, халык аларны лирик җырларында художестволы чарага – фигураларга әверелдергән. Халык җырда сандугач һәм бөркетләргә, чишмә һәм диңгез дулкыннарына, искән җил һәм агар суларга, өзелеп-өзелеп, үз итеп дәшә, иң тирән һәм нечкә кичерешләрен уртаклашуда аларны үзенә сердәш итә. Ләкин бу эндәшүләрнең эчтәлегендә инде хорафат дигәннең эзе дә юк. Киресенчә, монда инде үзенә үзе хуҗа булган кешенең үз рухи олылыгын белүе, хисапсыз күп рәвешләргә кереп, өзлексез кайнап, ташып торган дөнья, галәм тормышын чиксез яратуы, аның матурлыгына соклануы, зиһене, тойгысы белән шул күренешләрнең эчке

асылына ирешүе һәм нәтиҗәдә үз рухи дөньясы чикләрен тагын да киңәйтүе гәүдәләнә. Халык аңында туып үсә барган бу яңа сыйфаттагы риторик эндәшләр татар язма поэзиясенә дә килеп кергән. Без аларны Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ында ук очратабыз.

Анда Якуб, таң җиленә мөрәҗәгать итеп, болай ди:
Акрын искел, сәбах йиле! Нә үтәрсән?
Сән хакыйкать Йосыфымнан ис тотарсән,
Җәрәхәтем уңармага сән йитәрсән,
Сән исәле, бән мөфәррах булдым имди[1].

Шулай да бу матур яңалык татар язма поэзиясендә активлашып китә алмаган. Язма поэзиядә аллага, фәрештәләргә мистик мәгънәдә дәшүләр озак вакытлар өстенлек иткән. Кандалый художестволы эндәшләрне зур кыюлык белән активлаштыра. «Сәба җиле» образына ул, яңа рух өреп, безнең поэзиягә аны кабат кайтара, гашыйкларның арадашчысы вазыйфасын биреп, аны үстерә, вакыйгаларга катнаштырып, баета, яңа функцияләрен ача. Ул җилне генә түгел, табигатьнең бүтән күренешләрен дә шигъри сөйләмнең актив элементына әверелдерә, кеше кичерешләрен төрле яклап ачуда алардан иркен файдалана. Менә аның үз сөйгәненнән аерылу хәсрәтен җырлап биргән шигыре:

Нәчә Сәхраларга чыксам,
Нәчә төрле егач күрсәм,
Бән һәм катларына барсам,
Хәбәр сорыйм бән анлардин:

«Әя егач! Яшең күпме?
Түгелгән яфрагың күпме?
Бәнем дик михнәтең күпме?»
Диеп сорыйм егачлардин.

Мондагы лирик герой, сөйгәне турында уйлаганда, бу эшкә үзеннән өстен нинди дә булса бүтән берәр рухи көчне катнаштырырга исәпләми. Агачларга сорау бирүе дә алардан нинди дә булса җавап алу өчен түгел, бәлки йөрәгендә кайнаган тойгыларын кая ташларга белмичә, ашкынып, аларны уртаклашырдай

[1] «Кыйссаи Йосыф». Казан, 1841. Б. 49.

Сүзлек: *сәбах йиле* – таң җиле; *ис тоту* – хәбәр китерү; *уңару* – төзәлү; *исәле* – искәч; *мөфәррах* – шат.

сердәш эзләвеннән генә. Сердәш итәр өчен ул әллә нинди илаһи көчләргә дәшми, нәкъ менә табигать күренешләренә мөрәҗәгать итә. Моңарда аның шушы җир тормышына ихлас мәхәббәте, шушындагы тормышка ышануы, өмете гәүдәләнә. Ул үзенең рухи тормыш чикләрен шушындагы табигать, шушындагы тормыш күренешләрен бер-бер артлы үз итү юлы белән киңәйтә бара, ул рухи байый, матурая.

Ул чордан алып Тукайга кадәрге вакыт эчендә татар язма поэзиясендә мондый чараларны Кандалыйдан башка беркем дә бу дәрәҗәдә оста һәм аңардагыча кабатланмас ягымлы төсмер белән кулланмады.

Аның традицияләрдән кайсысын ничек яңартуына тагын бер мисал китерик. Харәзминең «Мәхәббәтнамә»сендә шундый «Газәл» бар:

Яраткан кем тән эчрә җан яратты,
Сәне күрклеләр үзрә хан яратты,

Кояш яңлыйгъ йөзеңезне яратты,
Фәләк тик безне сәргәрдан яратты.

Хәлаек кыйбласы булды җәмалың,
Ушал көн кем сәне яздан яратты.

Әзәлдә кыйлды Харәзмине мохтаҗ,
Тагы манзурыны солтан яратты.

Без моны Кандалыйдагы «Сән һәм бән» исемле шигырь белән чагыштырып карыйк:

Сәне анда, бәне бонда яратты,
Бәне егъламага моңлы яратты.

Сәне анда, бәне бонда яратты,
Бәне сәңа, сәне бәңа каратты.

Сәнең өчен күңелдә гамь яратты,
Ике күземне тулы кан яратты.
Уламын шат, әгәр күрсәм йөзеңне.
Тулар дөньям, әгәр алсам үзеңне.

Бу ике әсәрне бер-берсеннән 500 ел вакыт аерып тора. Шулай да беренче карашка ук алар арасында ниндидер уртаклык барлыгын сизү кыен түгел. Иң элек шигырьләрнең бер калыпта һәм бер үк газәл жанрында язылулары күзгә ташлана. Тегесе дә,

бусы да шагыйрьнең аерым шәхескә мөнәсәбәтен белдерә. Беренче очракта хан, икенчесендә матур кыз мактала. Шушында инде ике әсәрнең бер-берсеннән аерылуы башлана. Харәзми ханны зурга, үзен кечегә куя, хан белән үз арасында кискен контраст картина тудырырга тели, үзен кимсетү исәбенә ханны зурайтып күрсәтергә омтыла. Феодаль дәрәҗәләр баскычы (иерархиясе) кагыйдәләре белән бәйләп алып караганда, шигырьнең шулай язылуына гаҗәпләнмисең дә. Кандалыйга килсәк, монда кешене олылау бөтенләй икенче яссылыкка куелган: шагыйрь олылаган кешесе белән үз арасында рухи тиңлек эзли, бу тиңлеккә ирешү юлындагы киртәләрне, аңлашылмауларны җиңеп үтәргә, олылаган кешесенең күңеленә керергә тели. Димәк, шагыйрь борынгы поэзиянең форма элементларыннан файдалана, ә эчтәлекне инде үз заманы тормышыннан ала.

Кандалыйның кеше турында фикер йөртүендә фәлсәфи төсмер сизелә. Бу хәл аңа кешенең рухи дөньясын тануда эчкәрәк үтәргә мөмкинлек бирә.

Күз карашың җан эчендә җан идәм,
Шөгъләсене[1] тән эчендә кан идәм, –

ди ул. Икенче шигырендә дә шундый ук юллар бар:

Җанымның эченә генә
Куяр идем, сыярмүсән?

Ул шигырьнең элекке формаларын да шул килеш кенә файдаланмый, аларны баета, үстерә, нәфисли. Менә аның «Сәламнамә» шигыре. Ул:

Сәламулла йөрәгем парасига,
Тәнем рухы, күземнең карасига, –

дип башлана.

Монда «тәнем рухы» сүзләре тирән мәгънә белән яңгырый. Без бу юлларны укыгач, Кандалыйда шигъри тойгының кеше матурлыгын тану, аңарга соклану нәтиҗәсендә туганын аңлыйбыз. Шигырь баштагы строфаны кабатлау белән тәмамлана, шунысы белән Кандалый татар язма поэзиясендә рефренның яңа формасын гамәлгә кертә. Ул шулай ук шигырьне нәфисләү чараларыннан анафора, эпифора кебекләрне дә активлаштыра, эшкәртә. Татар шигыренең моннан соңгы үсеше өчен шартлар хәзерли.

---

[1] *Шөгъләә* – ялкын.

## IV

Кандалыйның крестьян тормышын яманлавы яшьлек еллары өчен хас кебек күренә. Соңга таба, күрәсең, дөньявилыгы аның үзен дә югары катлаудан читләштерә, шул ук вакытта ул үзенә бүтән мохит та таба алмый. Аның ялгызлыгы башлана. Тормышында материаль мохтаҗлык та көчәя. Садрый хәсрәте газаплый. 1851 елда хатыны Фәхриҗамал аерылып китә. Мондый хәлләр шагыйрь карашларына тәэсирсез калмаганнар булса кирәк. Кеше язмышы турында ул инде җитдирәк уйлана:

Бу тәкъдир дигәнең нидер? –
Изеп, яньчеп орыр җиргә, –

ди ул һәм өсти:

Кеше дигән дә мазлумдыр:
Йөгерер, егылыр, торыр,
Башыны ташлара орыр,
Сөренмим дип әҗәлләргә.

Улы Садрый турында яки аңа туп-туры атап язган шигырьләрендә без инде тиңсез хәсрәтләргә тарыган зур җанлы ата йөрәген тоябыз. Тормыш аның каршына күп төрле мәсьәләләр китереп куя, ул уйлана, әсәрләрендә сораулар күбәя. Гомеренең алтмышка караган булуы, ялгызлыгы – болар үзләрен торган саен ныграк сиздерәләр. «Яна бәгырем, бу җирдә юк бәнем кадрем», – ди ул,

Каләмем дә тая инде,
Ки яза алмый турыдан, –

дип уфтана. Аңарда ятимсенү, хәтер калу интонациясе еш-еш яңгырый башлый. Без шагыйрьнең соңгы гомере, ничек авыруы һәм нинди шартларда үлүе турында бернәрсә дә белмибез. Без аның 1860 елда – 63 яшендә үлгән булуын гына беләбез. Хәзерге көндә аның Иртуганда (Иске Кандалда) үлгән булуын да кистереп әйтүче юк. Ул, әлбәттә, шушында үлгән. Иртуган авылының зиратына керәсең. Халык җилкәсен кимереп ятудан башканы белмәгән, хәзер исеме һичкемне кызыксындырмаган әлләкем хәзрәтләрнең каберләрендә җил-яңгырларга, еллар елгасының агымнарына бирешмәс ташлар утыра. Ләкин каберстанда Габделҗәббарга куелган таш күренми. Алай гына да түгел, аның кабере тигезләнгән, хәзер бу кабернең урынын төбәп күрсәтә алучы да юк инде.

Безнең сөекле Тукаебызның әле сабый вакыты – «Кечкенә Апуш» чагы булган. Менә кич белән аның кулына Каюм Насыйри төзегән «Фәвакиһелҗөласа» китабы эләгә. Китапның соңгы өлешендә Кандалый шигырьләре басылган. «Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам»[1] – дип исенә ала шул вакытларын Тукай. Бу сүзләр Кандалый иҗатының көче, сүрелмичә, Тукайга кадәр килеп җитүе турында сөйлиләр. Моңардан без татар поэзиясе үсешенә шагыйрьнең тирән тәэсир ясавы турында уйлый алабыз. Бу иҗат әле бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмаган: бердән, ул татар әдәбиятының тарихи юлын билгеләүдә булыша, икенчедән, күптән үтеп киткән бер заманның тормыш картиналарын бүгенге укучы каршына җанлы образларда китереп бастыра. Шуңар күрә дә без бу иҗатны бастырып чыгару урынлы дип саныйбыз.

*Кандалый Г. Шигырьләр. Казан:*
*Татар. кит. нәшр., 1960. Б. 4–34*

## Г. КАНДАЛЫЙ:
## БЕР ГОМЕРДӘ ИКЕ ЧОР

*Миркасыйм Госманов*

Шагыйрь Г. Кандалыйның исеме, иҗатының бер өлеше киң җәмәгатьчелеккә күптәннән мәгълүм. Шул мәгълүм өлештән генә чыгып та, шагыйрьнең язу осталыгы, аның татар әдәбияты үсешенә керткән бәхәссез яңалыгы ихлас күңелдән тәкъдир итә киленде.

Г. Кандалый 1797 елда элекке Самар губернасының Ставрополь өязе (хәзерге Ульянов өлкәсенең Иске Майна районы) Иске Кандал (хәзер – Иртуган) авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Шагыйрьнең туган елы хакында үзгә фикерләр дә бар. Мәсәлән, И. Бәхтиев язуынча, ул 1794 елда туып, 1862 елда вафат булган, ләкин К. Иртуган белән Г. Сәгъди һәм күпчелек галимнәр «1797–1860» тарихына тукталалар.

Кандалыйның социаль чыгышына килсәк, монда бәхәс юк: руханилык кәсебенең алар нәселендә ерактан килүе иске

---

[1] Тукай Г. Академик басма: ике томда. Казан, 1948. II т. Б. 21.

шәҗәрә буенча да (Кандалый – Габделмәҗит – Ибнейәмин – Биктимер – Ибраһим – Йосыф...) һәм шагыйрьнең үз сүзеннән дә төгәл раслана. Мәсәлән, Мәгъшукасына мөрәҗәгать итеп, ул болай ди:

Безем бу меллалык йирле (нигезле, төпле).
Ки йите бабадин бирле
Килеп өзелмәгән бер дә!..

Кайбер мәгълүматларга караганда, Г. Кандалыйлар нәселе элек Каракитә авылында (хәзер Татарстандагы Чүпрәле районы) яшәгән булган, Иске Кандалга шагыйрьнең ерак бабаларыннан берсе килеп урнашкан. Мәсәлән, Габделмәҗит Ибнейәмин улы шунда муллалык иткән, дан-абруй казанган. Габделмәҗитнең гадәти генә авыл мулласы булмыйча, шактый зур белемле, китапәсәр язу, «шәрех-моталака кыйлу» белән шөгыльләнүче галим кеше булганлыгын аның «Болгари» тәхәллүсен – әдәби псевдонимын йөртүе дә раслый. Г. Кандалый үзе дә соңрак үзен укучыларга: «Бу фәкыйре Г.Г. Кандалый, зәгыйфь, бине Габделмәҗид Болгари, нәхиф», – дип тәкъдим итә.

Башлангыч белемне Г. Кандалый үз атасыннан ала. Белемгә һәвәсе күренеп торган сәләтле улын Габделмәҗит хәзрәт тагын да зуррак мәдрәсәләрдә укытып, нәселдән килгән руханилык дәрәҗәсен ышанычлы кулга тапшырырга уйлаган булса кирәк, шуңа күрә соңрак Г.Г. Кандалыйны мәдрәсәдән мәдрәсәгә күчеп йөри. Иң элек Чистай якларындагы Мораса, аннары бер-бер артлы Кизләү, Күркәле, Кышкар, Шонталы мәдрәсәләре...

Кызу холыклы, туры сүзле, ачы телле, үзе хакында югары фикердә торган һәм, иң мөһиме, үз ирегең югары бәяләгән егет, күрәсең, мәдрәсәдәге ишләре белән еш кына төрткәләшеп яшәгән, мөдәррис-хәлфәләре белән дә көтелмәгән низагларга кергәләгән. Һәрхәлдә, шагыйрьнең мәдрәсә тәртипләре, кара муллалар хакындагы сатирик шигырьләреннән, ачы телле эпиграммаларыннан шундыйрак мәгънә аңларга мөмкин. Бер мәдрәсәне ул үзе кул селтәп ташлап китсә, икенчесеннән аның үзен куганнар, шуңа күрә «нигә мине тиз ятсындың», «туган илем ерак калды», белем эзли-эзли «җәяү йөреп сыйрак талды» дип көрсенгән егет үзен куучыларга йодрык та янап ала:

Кусагыз да, һич уфтанмам,
Язуымнан да тукталмам;

Котылмассыз барыбер сез, –
Әле болай гына калмам:
Төреп чалма-чапанларны,
Йөресәм кыр-япанларны,
Онытмам сез наданларны, –
Элеп салмыйча һич калмам!

...Ул үзенең тырышлыгы, сәләтлелеге белән мәдрәсә белемнәрен, бигрәк тә гарәп һәм фарсы телләрен нык үзләштерүгә ирешә. Шуңа күрә, мәсәлән, Күркәле авылы хәзрәте гарәпчә бик әйбәт белгән Г. Кандалыйны, авыл картларының коткысына карамастан, мәдрәсәдән куарга ашыкмый. Орыда укыган чакта исә, уку йортын тотучы мөдәррис Г. Кандалыйның үзен башка шәкертләргә гарәпчәдән дәресләр бирү эшенә җәлеп итә. Истәлекләр буенча мәгълүм бу хәбәрләрнең дөреслеген шагыйрьнең үзеннән калган бәхәссез документлар да раслый: шәкертлек чорында иҗат ителгән «Рисаләи-л-иршад», «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» әсәрләре Кандалыйның гарәпчә белән фарсычаны да, классик төрки язма телне дә бик яхшы белгәнлеген күрсәтә. Бу хәл исә аңа бай традицияле Шәрекъ әдәбиятлары хәзинәлегенә ачкыч бирә. Кайбер мәгълүматларга караганда, Кандалый чувашча, мордвача да аңлаша алган, кирәк дәрәҗәдә рус телен дә үзләштергән.

...Кешеләр белән мөнәсәбәттә актив табигатьле Кандалый мәдрәсәдәге әшнәләренең куен дәфтәрләрендә саклана торган «Шәкерт дәфтәрләре» белән якыннан танышкан. Аларда теркәлгән җырларны хәтеренә сеңдерә барган, үз дәфтәренә күчереп алган, үзгәртеп язган, йәисә аларны үзе иҗат иткән шигырьләренең тукымасына ук кертеп җибәргән.

Орыда укыту эшләрен башлап җибәргән Кандалый, атасы чакыруын истә тотып, туган авылына кайтырга була. Һәм аңа, ничә еллар мәдрәсәдә уку нәтиҗәсен рәсми кәгазь ярдәмендә раслау өчен, Уфага барырга, Диния нәзаретендә муллалыкка имтихан тотарга туры килә.

...Туган авылына ул 1824 елда кайтып төшә, атасына варис буларак, Иртуганда муллалык вазифасын үти, Шәфигулла дигән кешенең кызы Гөлстанга өйләнеп, бер-бер артлы балалар үстерә башлый. Тора-бара Г. Кандалый икенче, хәтта өченче хатынга да өйләнә, ләкин тормышы бары тыштан караганда гына шулай җайлы булган. Чынлыкта аның картлык чоры да шундый

ук дәрәҗәдә борчуда, бимазалыкта, хәтта трагик рәвештә авыр хәлдә узган.

Ул үз авылындагы һәм күрше тирәдәге байлар, руханилар белән сыеша алмаган. Соңгылары аны динсезлектә, тәүфикъсызлыкта гаепләгәннәр. Атасы мөгътәбәр Габделмәҗит Болгари хәзрәтләре вафатыннан соң (1840 ел) Г.Г. Кандалыйга юнәлгән һөҗүмнәр аерата көчәеп киткән: элекке яшерен гайбәтләр, ачык гаепләүләргә әверелеп, төркемнәр көрәшенә кадәр үсеп җиткән. ...Үзенә мәчет мөнбәре һәм мәхәллә тапшырылу «ышанычын акламаган», мәгәр шәхси мәнфәгатен җәмәгать интересыннан өстен куйган Г. Кандалыйның «персональ эше» барлыкка килгән; махсус «комиссияләр» төзелеп, бер-бер артлы утырышлар оештырылган. Ниһаять, каныккан төркемнең тырышлыгы нәтиҗәсендә аны эшеннән азат итү хакында карар чыгартуга ирешелә һәм, объективлык хакына дип, бушаячак урынга Кандалыйның якын туганы – энесе Әбүбәкер Әхмәт (Әхмәтнең атасы Ибнейәмин, аның атасы Биктимер...) тәкъдим ителә.

Кандалый тарафдарларыннан Мөхетдин Уразов 1843 елны авылның икенче (югары) очына яңа мәчет салдырып, ягъни мәхәллә аерып, шунда Г. Кандалыйны куюга ирешкән. Көрәш шактый катлаулы булган, күрәсең. Кайбер мәгълүматларга, мәсәлән, «Мәгъшукнамә» китабындагы ишарәләргә караганда, Г. Кандалый бер ара үз авылыннан китеп торганга да охшый (китап авторының үзен Түгәлбай авылы мулласы дип әйтүе шуңа ишарәли шикелле). Болай эзәрлекләнү, үзенә күрә «эшсез калу» фактлары Г. Кандалыйның шигырьләрендә дә чагылыш таба:

Ходаүәндә яна бәгърем:
Бу йирдә юк бәнем кадрем,
Чыдарга калмады сабрым, –
Сабыр бирсен үзе алла!

Дошманнарының әләге аркасында Г. Кандалый төрмәдә дә утырып чыккан... 1848–1849 еллар тирәсендә аның башына тагын зур кайгылар төшә: язу-каләмгә сәләтле, бәет-мөнаҗәт чыгаруга оста улы Садретдин 25 елга солдат хезмәтенә алына... Кайчандыр күбрәк гыйшык, кәеф-сафа турында мавыгып җырлаган, шул юнәлештә осталык күрсәтеп, чын шедеврлар тудырган шагыйрь, аерылышу темасы буенча да күпкырлы энҗедәй ялтыраган, тирән мәгънәле, нечкә хисле шигъри юлларны тудыра:

Бу бала хәсрәте түкде
Кара сачларем башымдин,
Инешләр ташды йәшемдин...–
Җитешмәсме әҗәлләргә?!

... Муллалык дәрәҗәсе өчен барган көрәш кайгысы гына, солдатка киткән бала хәсрәте генә изми Г.Г. Кандалыйны. Аның гомум гаилә тормышына да бәйле. Фәрхиҗәмал исемле кызга күңеле төшеп йөргән чакларда ул мәхәббәт хисеннән канатланып, дөньяны селтәп ташлардай җилкенеп ала, үзенең иң матур «әбъятларының» (бәйт-шигырьләренең) бер көлтәсен язып ташлый. Өйләнә. Тик ахырда эшләр аерылышу белән тәмамлана.... Яшь хатыны Хәлимәгә килсәк, ул, кайбер ярым ронияле җыр кисәкләрен исәпкә алмаганда, әллә ничек эзсез генә үткән шикелле... Күңелдә җуелмас эз калдырганы, хәтта йөрәкләргә, бәгырьләргә тирән җәрәхәттәй уелып кергәне – ул Сәхипҗамалга булган гыйшык хисе. Бәлки, шул Сәхибкә багышланган җырлар, аның тарафыннан кабул ителмәгәч, шулай адресаты үзгәртелгән хәлдә, икенче чибәргә – Фәрхигә күндерелгәндер?...

Баласын өзелеп сагыну, уңышсыз дип әйтерлек хәлдә бимазалы узып киткән шәхси тормыштан туган канәгатьсезлек агай-эне һәм мәхәллә тирәсендәге ыгы-зыгылар – һәммәсе бергә өстәлеп, бер җилкә күтәрә алмаслык йөккә әверелә. 1860 елның маенда Г. Кандалый вафат була.

Шагыйрь вафатыннан соң егерме ел узуга аның бер китабы – «Мәгъшукнамә» басылып чыга, язучысының исеме күрсәтелмичә генә. Шуңа күрә моңарчы аны Г. Кандалыйга тулысынча «бирергә» дә теләмәдек, йәнәсе анда аның аерым шигырьләре генә кергән...

* * *

Мәгълүм булганча, урта гасыр дөньяви Шәрык әдәбиятларында мәхәббәт темасы төрле яклап өйрәнелгән, үзләштерелгән темаларның берсе һәм нигездә, тәссауыф тенденцияләренең вакыт-вакыт ерып керүләрен исәпләмәгәндә, кеше хисен тасвирлаган, гадәти җир бабаларының шәхси-интим мөнәсәбәтләрен җырлау аша, кеше дигән хикмәтле затның бәхеткә хокукын яклаган чын гуманистик юнәлеш иде. ... Әмма соңрак, мөселман илләрендә социаль-иҗтимагый торгынлык урнашып, иҗтимагый-әдәби фикердә дә регресс башланып, беренче планга гел

дини әдәбият, аның дәвамы булган суфичылык әдәбияты чыккач, мәхәббәт дигән төшенчә дә нигездән үзгәрә, бөтенләй икенче эчтәлек, ала. Нечкәлекләренә хәтле төпченеп эшкәртелгән тәссауыф тәгълиматы буенча кеше бары «Аңар» – Аллага гына гыйшык тотарга, «Аның» белән генә кавышу өчен омтылырга тиеш. Тәмам төгәлләнгән тәссауыф өйрәтүе буенча гадәти бәндәнең үзе кебек үк җир кешесенә мәхәббәт тотуы – түбән хискә бирелү ул...

...Әлеге чорларга караган язма әдәбиятыбызда, төгәлрәк әйткәндә, «профессиональ» әдәбиятта чын дөньяви мәхәббәткә багышланган әдәби әсәрләр бездә юк дәрәҗәсендә дип әйтерлек иде. Г.Г. Кандалый татар әдәбиятына үзенең мәхәббәт тематикасы белән анда менә шундый бушлык, традиция өзелүдән туган тәҗрибәсезлек хөкем сөргән заманда килеп керде һәм бер гомер эчендә сирәк кенә күренә торган зур казанышларга иреште. Аның бу юнәлештә узган юлы да турыдан гына бармады, чөнки ул, әдәби әсәр язу эшенә традицион иске әдәбият – суфичылык әдәбияты позициясеннән чыгып тотына.

Г.Г. Кандалыйның беренче җитди әдәби тәҗрибәләре сыйфатында хәзергә аның ике поэмасын – «Рисаләи әл-иршад» һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» әсәрләрен исәпкә алабыз. Аларның яшь автор каләменә карауларын, күчермәдә тарихы, елы күрсәтелмәгән булса да, түбәндәге фактлар ярдәмендә расларга мөмкин. Күчермә китап XIX йөзнең башы өчен характерлы күгелҗем-яшькелт кәгазьдән эшләнгән. Кәгазьдәге «1816» ел дигән су билгесе (филигрань) материалның фабрикадан кайчан чыгуын күрсәтә. Димәк, кәгазь, сатып алучыга барып җитеп, кульъязмага әверелеп өлгергәнче 2–3 ел узып китсә дә, бу нөсхә 1820 ел тирәсендә күчерелгән булып чыга. Ә инде зур күләмле, авыр формалы ике әсәрнең беренчесе языла башлауга кимендә ике-өч ел, аннары ике әсәр дә редакцияләнүгә, карадан акка күчерелүгә, ягъни хәзер Ленинградта саклана торган күчермә төгәлләнеп бетүгә йәнә ике-өч ел кирәк булганлыгын исәпләсәк, әлеге әсәрләрдән «Рисаләи-л-иршад»-ның языла башлау вакыты 1815–1816 елларга, ягъни Г.Г. Кандалыйның 17–18 яшьләр тирәсендәге чорына туры килә дигән сүз. Кыскасы, мәдрәсә чорында, аңы формалашып өлгермәгән егетнең эзләнгән чорында туа башлаган.

Әсәрнең исеме үк – «Рисалә әл-иршад», ягъни «Тугры юлга күндерүче китап» (алга таба «Рисалә» генә дип йөртербез) –

аның дини-әхлакый юнәлештә булган дидактик характердагы поэма икәнлегенә ишарә итә. Әйе, озын гына кереш, махсус исемнәр белән тәэмин ителгән 28 бүлек һәм иң ахырда йомгак сыйфатында китерелгән бер мөнәҗәттән торган әсәр тулысынча диярлек кешеләрне изге нияткә, яхшы гамәлгә, димәк, «чын мөселманлыкка» чакырган «нәсәихтан», ягъни үгет-нәсихәтләрдән гыйбарәт. Моны әсәрнең йомгак өлешендә автор үзе үк ачык әйтә:

Нәсаих әйләдем, и йар,
Сәнең өчен язып әшгар (шигырьләр).
Кабул итеп дотып юл вар (юл белән бар),
Еракка китмәгел найа.
Нәсыйхәтләр сәңа хуб бад (яхшы булсын),
Боның исмен идәрсәң йад,
Атап «Рисаләи-л-иршад»,
Язылган ошбу дүрт пайа (дүртаяк – дүртьюллык).

Нәсихәтләр, табигый, поэманың кереш өлешеннән үк башланалар, һәм алар нигездә «теге дөнья» өчен бу дөньяда ук әзерлек күрергә, җәһаләтлектән (наданлыктан) качарга, шуңа күрә зарур гыйлемнәрне өйрәнергә, димәк, яхшы укырга чакыра:

Ки, зинһар, калмагыл надан...
Ки, зинһар, калмагыл надан,
Дога алгыл ата-анадан...

...Бу әйтелгәннәрнең гадәти абстракт мәгърифәтчелек өндәмәләре булмыйча, гыйлем дигән нәрсәне суфиларча аңлауның нәтиҗәсе икәнлеген шул ук керештәге дөньяви тормышка, хезмәткә карата булган кире мөнәсәбәт ачык күрсәтә. ...Шагыйрь фикеренчә, кара эш белән иза чикмәс өчен, наданлыктан качып, белемлелеккә омтылырга кирәк. Бер үк вакытта болар безгә таныш мотивлар: Кандалыйның электән билгеле әсәрләрендә дә аның хезмәткә, шул хезмәт белән шөгыльләнүче гади кешеләргә түбәнсетеп каравы яхшы мәгълүм. Димәк, аның бу чикләнгән карашы шәкерт чакта язылган беренче әсәрләрендә үк формалаша башлаган икән.

Менә шулай авторның уй-фикерләрен кыскача гәүдәләндергән озын керештән соң Г.Г. Кандалый, әлеге фикерләрен дәлилләр өчен, әсәренең «иллюстратив» өлешенә күчә. Беренче бүлек сабыйларга үгет-нәсихәт бирүгә багышланган:

Сабыйлыкда уен кыйлсаң,
Шәйатингә (шайтаннарга) муен сонсаң,
Күнәлмәссең бөйлә улсаң,
Егетлекдә улып сөкран (сөкран – исерек)...

«Егетлек вакытындагы нәсихәтләр вә вәгазьләр» дигән икенче бүлек бик тиз узачак яшьлек чоры белән масаймаска, гомерне әрәм уздырмаска дигән фикердән башланып китә. ...Автор «җиһангирга салмагыл мәйли», явызлык эшләмә, хәйлә-мәкердән кач, йөзең күрке белән масайма, эшсез йөрмә, шайтан коткысына бирелмә, кыскасы, фани дөньядан биз (тәрек әйлә) дигән ише бер үк фикерләрне кырык строфа (160 юл) буена туплый.

Өченче бүлектә кызларга әдәп-хәя, сафлык һәм гыйффәт саклау хакында киңәшләр бирелсә, дүртенчесендә хатын-кызларның «тәмле телле» булуы мактала. Урынлы һәм дөрес куллана белмәсәң, ди автор, тел кешегә иң авыр җәрәхәтләрне ясарга сәләтле.

Ирләргә адресланган бишенче, һәм булдыксызлар хакындагы алтынчы бүлекчәләрдә дөньяга хирыслык сыйфатлары кире кагыла; шагыйрь бу начар сыйфатның татар халкы арасында киң таралган булуы өчен ачына. Хатыннарга махсус вәгазьләр укыгач (җиденчесе), ирләрен рәнҗетүче «яман хатыннар» турында сигезенче бүлекне яза. Соңгысының төп эчтәлеге «яман хатын – зиндан ул» дигән сүзләргә кайтып кала.

Тугызынчы бүлектә дөньяның тиз үтүе, шуңа күрә мәгърурлык белән мавыкмаска дигән идея алга сөрелсә, унынчысында аздыргыч шайтанның сыйфатлары сурәтләнә. Унберенче бүлектән алып уналтынчыга кадәр дөрес юлда булу, явызлардан качу, нәфескә иярмәү, аллага сыгыну, сабыр булу һәм башкаларны тугры юлга өндәү хакында үгет-нәсихәтләр әйтелә.

Унҗиденче бүлек «Пирлек (пирлек – картлык) вә карилык вакытындагы хәлләр вә нәсыйхәтләр» дип аталып, анда элгәрге бүлекләрдәге кебек үк оста эшләнгән, образлы һәм үткен юллар бар:

Акарды сакалың, башың,
Саны йөзгә йитеп йәшең,
Ки вармы дүгелән (түгелгән) йәшең,
Идеп тәүбә мин эттогйан!.. (азгынлыктан)

Бүлекнең мәгънәсе начар юлда кичкән йөз ел гомердән гыйлемлектә, тугърылыкта узган егерме яшь артык дигән фикергә

кайтып кала. Кеше гафләттә торган чакта «кинәт» үлем килүгә багышланган унсигезенче бүлек, үзенең үтә мистик рухта булуына карамастан, гаять көчле язылган өлешләрнең берсе, чөнки монда әлеге мәсьәлә буенча элгәрге суфичылык традициясендә ирешелгән әдәби казанышлар, сәнгатьчә чаралар киң файдаланылган.

...Бер-бер артлы «тормыш мизгелләрен» узып, әҗәл заруриятын аңлаган укучыны автор калган бүлекләрдә (19–28) җан бирү, димәк, ахыр заман җитү, теге дөньяда яңадан терелү, сыйрат күперен кичү, оҗмахка йәисә тамугка керү, кайда нәрсәләргә дучар ителү кебек хәлләр белән «таныштырып чыга». Бу бүлекләрдә ислам дине өйрәтүләренең «теге дөньяга» караган төп моментлары традицион рәвештә яктыртыла, чөнки авторның әллә ни ирекле кылана алмавы алдан ук хәл ителгән. Шулай да бер мәсьәләдә, әйтик, хур кызлары белән очрашуны тасвирлаган чакта, шагыйрь үзен мөгътәбәр җәннәт әһеленнән бигрәк әдәптә авызлыксыз җир бәндәсе шикелле тота башлый... «Кызлар тематикасы»ннан йәнә аллага күчкәч, шагыйрь тагың традицион вәгазьчегә әверелә, җәһәннәм хакында язган мәгълүм әйберләрне кабатлаудан узмый. ... «Мөнаҗат» (мөнәҗәтләр) дип исемләнгән соңгы бүлегенә күчкәч, безнең алга яңадан шушы «гөнаһлы җирнең» кайбер сыйфатларын дөрес тота алган үткен күзле, ачы телле Г.Кандалый килеп баса. Әлбәттә, монда да ул начарлыклардан качарга өндәүче, укучыларны изге юлга, күңел пакьлегенә дәшүче дидактик булудан туктамый. Бер үк вакытта әле генә үзе артык игътибар итеп тормаска чакырган реаль тормыштагы типик гаделсезлекләргә карата протест белдерүдән дә тыела алмый ул:

Гаҗәб хәйрат (таң калу), гаҗәб вәйа (вай диерлек):
Нәзар (күз салу) кыйлсаң бу дөньяйа;
Фәкыйрә игътибар һич юк,
Идәрләр гыйззәти – байа (кадерне – байга)...

Дөнья һәм ахирәт мотивларын шулай үреп бару, шул рәвешчә кеше алдына «гыйбрәт көзгесе» кую, аны аң-белемгә, саф әхлакка, тугры иманга, гаделлеккә өндәү дөнья әдәбиятында шактый киң таралган ысул ул. Кыскасы, дини сюжетлар, иляһи мотивлар белән файдаланып, бу «фани дөньяны» төзәтергә омтылу, матди тормышны тәртипкә салу юлында бары идеяне генә корал итеп алу, ягъни гаделсезлеккә җитү мөмкинлеген гел «иман

пакьлеге»нә ирешүгә кайтарып калдыру – феодализм идеологиясе хакимлек сөргән чорлардагы шагыйрьләргә, әдипләргә, бигрәк тә тәссауыф юлындагы каләм ияләренә хас, уртак сыйфат, гомум күренеш иде.

Әгәр Г. Кандалый иҗатының, дөресрәге, бу очракта «Рисаләи әл-иршад» поэмасының әһәмиятен билгеләгән чакта мәсьәләгә шушы күзлектән карасак, гомуммирас фонында әлеге истәлекнең урыны дөресрәк табылып, аның объектив әһәмияте күренәчәк.

Мондый алым әсәрнең идея-эчтәлеген, иҗтимагый кыйммәтен билгеләүдә генә түгел, бәлки аның әдәби дәрәҗәсен бәяләү, шул дәрәҗәнең табигатен ачыклау өчен дә зарур. Моның шулай икәнлеге шагыйрьнең Ленинград кульъязмасындагы икенче поэманы күзәткәндә дә күренә. Сүз шартлы рәвештә «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» дип аталган зур күләмле әсәр, дөресрәге, аның сакланып калган өлеше хакында бара.

...Әсәрнең башыннан, урталарыннан һәм ахырыннан шактый өлеше югалганга күрә, аның автор тарафыннан куелган төгәл исеме сакланмаган. Шулай да әсәр үзәгендә тәкъвалек хакына шаһлыктан бизгән Ибраһим Әдһәм торуын һәм поэманың үзендә аның жанрына, исеменә карата ишарәләр булуын («Бер кәтабәт кыйссалардин әйләгел», «күрде кыйссадин бу фәкыйрь күп көтөб...») игътибарга алып, аны «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» дип атарга мөмкинлек табылды. (Кыскалык өчен алга таба «Кыйсса» дип кенә йөртелер.)

Әсәрнең төп өлеше борынгы Бәлх солтаны Ибраһим Әдһәмнең (874–875 елларда үлгән) – Шәрекъ әдәбиятларын да үзенең акылы, гаделлеге, динлелеге белән легендага әверелгән традицион геройның – хакыйкать эзләү максаты белән тәхетен, бөтен мал-милкен ташлап, иске-москыга төренеп, ил гизеп китүең тасвирлаудан башлана.

«Алла ризалыгы» өчең гариблектә шактый гомер кичергән, ул бер көнне акылы һәм гаделлеге белән падишаһлар арасында дан казанган хәлифә Һарун әр-Рәшид иленә юнәлә. Юлчы Һарун падиша яшәгән шәһәргә җитәрәк караңгы төшеп, шәһәр капкасы ябылудан ул төнне къәлга тышында уздырырга мәҗбүр була. Шунда аны төнге дозор тотып ала.

Начар киемле Ибраһимны карак дип уйлаган сакчы аны кулга алып, этеп-төртеп, падиша янына китерә, Һарун әр-Рәшид исә, сораша-белешә торгач, тоткынның зур акыл иясе хәким икәнлеген аңлый һәм, ялган сөйләп, шундый кешегә җәбер күрсәт-

кәне өчен дозорның үзен суктырып, Ибраһим Әдһәмне табынга чакыра. Һарун белән Ибраһим арасында шул рәвешчә бәхәс булып ала. Хәерче дәрвишнең акылына, тапкырлыгына сокланган патша аны үз янында калырга һәм сохбәт – әңгәмәдәш булырга чакыра. Үзенең кем булуын, нишләп йөрүен яшермәгән Ибраһим Әдһәм Һарун әр-Рәшид тәкъдим иткән палудәдән (җимеш суы кушып ясалган желедан) дә баш тартып, дәрвишлек юлын дәвам иттерә, чөнки ул рәхәттән, ләззәттән ваз кичкән, чөнки ул хәкимнәргә баш иеп яшәргә теләми...

Ибраһимның шөһрәте Йәмән мәмләкәтенә аның үзеннән элегрәк барып җитә. Моны сизгән тыйнак дәрвиш, кәрваннан бүленеп калып, шәһәргә аерым гына керә. Изге кунакны каршы алырга җыенган халык аның хакында Ибраһим Әдһәмнең үзеннән, сораша башлый. Ул исә, үзенең патша булганлыгын онытканга, Ролх шаһын шулай кызыксынып сорашуларына гаҗәпләнә кала. Изге солтанга карата шик белдергәне өчен, әлеге халык Ибраһимны кыйнап ташлый. Шулай итеп, бу юлы ул үзен хөрмәтләүчеләрдән җәбер күрә...

Ибраһим Әдһәмнең тәхеттән ваз кичүенә күп еллар уза. Ул һаман ил гизеп, каңгырып йөри. Тамагы ачса, үз акчасына ризык сатып ала, акчасы булмаса, ризыкны агач башмакларына алышып ала, бушлай бирелгән ризыктан баш тарта. Иманын тимер тәңкәләргә сатканчы, Аллага сыену, Алла исемен олылап мөнәҗәтләр әйтү аның өчен кыйммәтрәк.

Көннәрдән бер көн Ибраһим Әдһәм бер зур мәҗлес өстенә килеп чыга һәм, аны-моны уйламыйча, әйванда (верандада) утырган казый янына килеп җайлаша. Йолкыш берәүнең үз янына утыруыннан гарьләнгән казый аны түбәндә торган ярлылар арасына куып төшерә. Шунда ук казый һәм башка хәллеләр җыелган әлеге әйванда бәхәс куба, беркем дә аны чишә алмый. Мәсьәләне бары теге йолкыш карт кына хәл кыла. Шуннан соң киң җәмәгатьчелек кенә түгел, хәтта әлеге тәкәббер казый да дәрвишнең хәкимлеген икърар кылып, башыннан чалмасын салып бирә. Хикәянең морале:

Кадер-гыйззәт мал-милек белән имәс,
Һәм мәратибләр бозоргилән имәс.
(һәм мәртәбәләр зурлык (олысыманлык) белән түгел.)

...Кызганычка каршы, әсәрнең нәкъ шушы төшендә, сюжетның үзенә күрә кульминацион ноктасына ирешкән җирендә,

текстның зур гына өлеше югалган. Хәзер 40 һәм 41 дип тәртип саннары сугылган кәгазьләр арасыннан иң кимендә берничә бит төшеп калганлыгы бәхәссез. Моңа кадәр Ибраһим хакындагы хикәя өченче заттан сөйләшкән булса, моннан соң сүз беренче затка күчә, ягъни, үзе персонаж рәвешендә сәяхәт итә һәм хикәяли башлый.

Өзелүдән соң сакланып калган текстта сүз бер Болгар җире кешесенең белем алу максаты белән чит җирләргә барып чыгуы сөйләнелә. Шулай ил гизеп, төрле кешеләр белән очрашып йөргәндә, ул бер сөргеннәр (рандәләр – качаклар) авылына кереп куна. Алар юлчының кем булуы, нишләп йөрүе хакында сорашалар, хәтта бәйләнә дә башлыйлар. Вакыйга түбәндәгечә сурәтләнеп китә:

Рандәләр ул кичә безне сәмгъ улып (ишетеп),
Собх улачак (иртән) килде бонлар җәмгъ улып (җыйнаулашып)
Диделәр: «Сезләр кайу йирлек кеши,
Ошбу йирдә нә идәрсез, нә эши..?»

Сорауга каршы хикәяче үзенең Болгар җиреннән, Кандиле авылыннан икәнлеген әйтә. Бандәләр исә, ышанмыйча, таныклык кәгазе таләп итәләр, ләкин таныклык булмый. Егетнең аягына богау салалар. Нәкъ шул вакытта, аның бәхетенә, бер бай сәүдәгәр килеп чыгып, «бони беләрем, һәм – йирен» дип, тоткынны йолып ала, аякка кешән салучының үзенә суктыра.

Бәладән котылган Болгар җире егете, икенче вакыйгага күчеп, үзенең иске-москы киемдә килеш халык күп җыелган бер гаед намазында вәгазь сөйләүче имам белән бәхәскә керүе хакында хикәя итә башлый... ләкин тагын текст өзелә (ягъни 42 һәм 43 битләр арасыннан да кәгазьләр төшкән...)

Моннан соң сүз нәфескә бирелеп дөреслеккә хыянәт иткән, гыйлемнән йөз чөергән һәм шунысы белән падишаһларга якынлашкан берәү хакында бара, аның әлеге начар фигыле хөкем ителә:

Галим үз кадрене бәйлә тәрк идеп (ташлау, калдыру),
Сим-зәр чөн нәфсен тәхәррек идеп,
(Алтын-көмеш өчен нәфесне аздырып.)
Галим улмады кем, улды ул бәзир (түбән төшү),
Лик галим улды шаһә хассе вәзир.
(Ләкин ул галим шаһка лаек вәзир булды.)

Хикәянең, ихтимал, бөтен әсәрнең фәлсәфәсе түбәндәге сүзләргә кайтып кала: «И туган, югары дәрәҗәне ташла, һәм үзең теләп шаһларга якынлыктан кач, солтаннарга якынлык – җанга бәла, андый бәла чиренә сабышма!»

Бу өзекнең әһәмияте, беренчедән, әсәр эчтәлегенең төп идеясен, автор фәлсәфәсен ачудан тыш, безгә дефектлы хәлдә килеп җиткән кулъязманың төрле әсәрләр өзегеннән түгел (хикәяләүче затлар алмашуыннан шундый фикернең тууы да ихтимал), бәлки бер поэманың начар сакланган өлешләреннән гыйбарәт икәнлеген раслый. Өстәвенә, моннан соң китерелгән мөнәҗәтләр дә мәгънә һәм сюжет бердәмлегенә зарар китермиләр: аларда сүз, нигездә, тугъры юлга төшү, гаделлек эстәү, моңа ирешү өчен байлыктан, властьтан баш тарту хакында бара.

Икенчедән, әсәрнең гомум юнәлешен, фәлсәфәсен чагылдырган әлеге «карбе солтан уладыр җанга бәла» фикере Г.Г. Кандалыйның үз оригинал уй-хыялы түгел, бәлки классик суфичылык әдәбиятында әллә кайчан, әллә ничә мәртәбәләр кабатланган традицион фикер. Төгәлрәк әйткәндә, монда өйрәнчек шагыйрь югарыда исеме бер кат аталган бөек суфи шәех Фәридетдин Мөхәммәд Гаттарның мәшһүр «Пәнднамә»сендәге мәгълүм юлларны кабатлый:

Карбе солтан атәш-и сузан буд,
Ба бәдан өлфәт һәляк-и җан буд.

Ягъни: «Солтаннарга якынлык ут кебек көйдерер, начарлар белән дуслашу җанны һәляк итәр». Әгәр заманасында безнең мәдрәсәләрдә киң таралып, фарсы теле буенча Сәгъдинең «Бөстан»ы кебек үк дәреслек-хрестоматия хезмәтен үтәгән әлеге «Панднамә» китабын игътибар беләнрәк актара башласак, андый уртаклыкларны күпләп табачакбыз; боларга турыдан-туры тәрҗемәләп күчерелмичә, иҗадирак рәвештә алынган фикерләрне дә өстәсәк, мисалларның саны бермә-бер артачак.

Әгәр безнең элекке мәдрәсә репетуарыбызда булган фарсыча башка тәсауыф китапларын да актара башласак, «Рисалә» белән «Кыйсса»ның өстәмә чыганаклары да ачылуга шик булмаячак. Моның шулай икәнлегенә «Кыйсса»ның керешендә Г.Г. Кандалыйның үзе үк ишарә ясый: «Күрде кыйссадин бу фәкыйр күп котеб, деләйүр язмага аны җәмгъ идеб». Ә «бер кәтабәт... әйләгел» дип үтенгән дус-ишләре һәм укучылары исә автор алдына, аның чыганак-үрнәкләре башка телләрдә булуын

белгәнгә күрә, «төрки улсын ул көтабәте шәриф» дигән шартны да куйганнар икән...

Әлбәттә, «Рисалә» белән «Кыйсса»да, аларның идея ягыннан чикләнгән әсәрләр булуына карамастан, ахирәткә бәйләнешлелек мотивлар белән дөньяви мотивларның үзара үрелеп, ярышып барган моментлары да шактый.

... «Рисалә», ...автор үзе образлы итеп әйткәнчә, «дүрт аяк», ягъни дүрт юллы строфа белән язылган: строфадагы һәр юл сигезәр иҗектән тора торган бу шигъри форма Г.Кандалыйның башка әсәрләрендә дә еш очрый. Гомумән, дүртьюллыклар белән эш иткәндә, шагыйрьнең иң яраткан рифмалау системасы ул, нигездәаааб, вввб, гггб... рәвешендә янәшә строфаларны уртак рифма белән үзара бер «җепкә тезеп» барудан гыйбарәт (мондый «үтәли» рифманы шартлы рәвештә б-рифма дип атыйк). Вакыт-вакыт автор дүртьюллыкларга (яки аларның аерым төркемнәренә) «автономия» бирә, ягъни, ееек, зззк тибындагы рифмалардан да файдалана (ара-тирә дигәндәй, абаб, яисә аабб рәвешендәге дүртьюллыклар да очрарга мөмкин, ләкин мондыйлары система түгел). Шундый ук эзлекле күренеш «Рисалә»дә саклана.

Егетләргә нәсихәт ителгән 40 строфалы икенче бүлектәге дүртьюллыклар да, рифмалары буенча, түбәндәге дүрт төркемгә бүленә: aaaб (1–5 строфалар), вввд (6–13), гггн (14–26), дддр (27–40). Поэманың башка бүлекләрен дә шулай анализлый башласак, бу системаның бөтен әсәр өчен характерлы булуы, димәк, Г. Кандалыйга гомумән хас дигән олеге форманың да егет чагында ук шагыйрь тарафыннан үзләштерелгән икәнлеге раслана.

«Кыйсса»дагы икеюллык строфаларның рифмалары махсус анализга мохтаҗ булмасалар да, «Рисалә»нең кайбер үзенчәлекләре игътибарга лаек. Мәсәлән, аааб тибында строфаның беренче өч юлындагы рифмалар һәм конкрет дүртьюллыкның индивидуаль бизәкләре булса, башка строфаларның да ахырларында кабатлана баручы б-рифма бөтен бүлек, яисә бүлек эчендәге строфалар циклын характерлый. Чама белән төрлеләндереп кулланган чакта мондый алым шигъри строфаларга кабатланмас бер төзеклек, эчке бердәмлек бирә. Моның шулай икәнлеген җитлеккән шагыйрьнең «Сәхипҗамал»ында күрергә мөмкин. «Рисалә»гә карата моны әйтеп булмый, чөнки әлеге б-рифманың кирәгеннән артык җәлеп кылынуы һәм авторның форма белән чамасыз мавыгуы аны сүзләрдән ясалма, формаль рәвештә фай-

далануга, күп очракта аңлаешсыз һәм махсус үзгәртелгән сүзләргә мөрәҗәгать итүгә китергән.

...Шагыйрьнең иң яраткан рифмаларының берсе -ан иҗегенә беткән сүзләр (углан, мәкян, имкян, заман, фәрман кебек). Мондый рифма сүзләре урынлы һәм дөрес кулланылган чакта строфаларга үзенә күрә бер төгәлләнгәнлек, әйтелгән мәгънәләргә ачыклык төсмере өстәгән шикелле була. Г. Кандалый яраткан икенче б-рифма -ар иҗегенә беткән сүзләр (мәсәлән, йар, дар, хар, нар, эшрар кебек). ... Җыеп әйткәндә, «Рисалә» поэмасының шигъри техникасында форма белән мавыгу үзен нык сиздерә.

Соңгы фикернең дөреслеген автор кулланган шигъри фигураларның башка төрләреннән дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, «Рисалә»дә төгәл яисә өлешчә омонимик рифмалардан да актив файдаланыла. Кайчакларын чама сакланмау, әйтик, укучының текстка күз йөртү процессында кабул итү мөмкинлеген исәпкә алмау нәтиҗәсендә ачык мәгънәле вәгазь-нәсихәт шигыре урынына башваткычлар килеп чыга:

Шәрафәтең шәр афәтә.
Кәмаләтең кәм аләтә,
Бирүбән ошбу халәтә
Соңыда калма дәр-тогъйан...

Хәзерге телгә күчерсәк, ул бик гади: «Намусыңны усаллык-явызлыкка, осталыгыңны исә кимчелекле коралга биреп (алмаштырып), шушы хәлдә соңра азгынлык эчендә калма!». Мондый башваткычларны «Рисалә»дә шактый табарга мөмкин. Кайчакларын шагыйрь уңышлы гына фигуралар тудырып та, вакытында туктый белмәү, чама белмәү аркасында, әлеге энҗе кебек ялтырый башлаган юлларны буяулы пыяла кыйпылчыклары белән күмеп калдыра. Поэмаларның, бигрәк тә «Рисалә»нең теле дә гаять чуар, ясалма, «урта белемле» укучы өчен дә аңлаешсыз. Өстәвенә, анда, рифма интересыннан чыгып, элементар тел нормаларын бозу фактлары да аз түгел:

Шәйатин үзрә кем бака,
Ходавәндә аңа кака:
Бакайларны уда яка, –
Белерсең кәнд үзең, и йар.
(бака – бага, карый; кака – кага,
читкә тибәрә; яка – яга, яндыра).

Җыеп әйтсәк, әлеге поэмаларда без талантлы, тәҗрибәсез кешенең каләмен күрәбез. Еш кына авторның «бик тә» гыйлемле булып күренергә тырышуы ярылып ята: китаби гарәп-фарсы сүзләрен, катлаулы фәлсәфи атамаларны уңга да, сулга да сиптерә...

Бәхеткә, сәләтле һәм мин-минлекле, шул мин-минлеге аркасында һәр җирдә низагъларга кереп, бер мәдрәсәдән икенчесенә күчеп йөргән Г.Г. Кандалыйның каләме алга таба шомара бара, тәҗрибәсе күзгә күренеп арта. Моның шулай икәнлеген «Рисалә» белән «Кыйсса»ны чагыштырып караудан да күреп була. «Кыйсса»да тел чагыштырмача гадиләшә, төзекләнә төшә, фикерләр дә артык формаль рәвештә яңгырамый, әмма барыбер ул да Кандалый иҗатында яшьлек чоры тәҗрибәсе булудан артык еракка китми әле.

...Бер үк вакытта шуны да онытмыйк: әлеге беренче әсәрләрендә үк яшь шагыйрь әдәби осталык җәяәтеннән үзен чын талант иясе итеп таныта. Бу осталык һәм талантның яралгыларын «Рисалә»дән һәм «Кыйсса»дан күпләп табарга мөмкин. Алар арасында мәкаль һәм афоризм югарылыгына күтәрелгәннәре дә шактый. Мәсәлән:

Җәһәтлек яманлыкдыр,
Бере аның наданлыкдыр...
Сабыйлык төш кеби улыр,
Егетлек кош кеби улыр,
Карилык буш-тәһи улыр...

«Рисалә»дә бер яңгыраган, мораль һәм рухи пакълеккә, димәк, дини-суфилык идеалларына дәшкән шигырьләр соңрак, чак кына эшкәртелгән, үзгәртелгән хәлдә яңадан яңгырыйлар. Бер карауга болар арасында артык үзгәлек тә юк сыман: бер үк сүзләр, бер үк сурәтләү чаралары, хәтта бер үк рифмалар. Әмма никадәре тирән мәгънәви, фикри үзгәлек монда! Әгәр «Рисалә»дә изге юлга дәшелгән егеткә гомере тиз узачагы искәртелеп, аның үзенә шайтан юлына кермәскә киңәш ителсә, Фәрхигә әйтелгән сүзләрдә аңаргашыйк егетнең дә форсаты узачаклыгы кисәтелеп, кызның үзенә өстенлектән (фәсъләт һәуасындан) масаеп «җәберләнмәскә», ягъни гыйшык бәхетеннән мәхрүм калмаска тәкъдим кылына.

...Нәтиҗә чыгарып әйткәндә, яшь Г. Кандалый поэмалары, әдәби тәҗрибәсез авторның өйрәнчек әсәрләре буларак, бер ае-

рым иҗатның төрле чорларын билгеләү өчен генә түгел, бәлки бөтен татар әдәбияты тарихындагы охравилыктан дөньявилыкка күчә башлау кебек мөһим этапларны өйрәнү, аңлау өчен дә зарур һәм кыйммәтле истәлекләр икән. Икенчерәк итеп әйтсәк, «Рисалә» һәм «Кыйсса» поэмалары конкрет шагыйрь иҗатының елга башы булулары белән бергә гомум әдәбиятыбызда барлыкка киләчәк борылышның да элгәрге этабын характерлый торган кайбер галәмәтләрен үзләрендә чагылдыруы белән әһәмиятлеләр.

* * *

Моңарчы берничә тапкыр җитлеккән Г. Кандалыйда да аның яшьлек чорына хас кайбер социаль-иҗтимагый чикләнгәнлекләрнең дәвам иткәнлеге хакында әйткән идек. Аларның берсе, һәм иң мөһиме, шагыйрьнең хезмәт кешесенә, димәк, материаль байлык җитештерүче хезмәтнең үзенә карата өстәнрәк карауга кайтып кала. Икенче җитешсезлек – ул ир-хатын арасындагы табигый мөнәсәбәтләрне беркадәр шәрәли төшүдән гыйбарәт. Биредә хәзер шагыйрь аңының, хаким катламнар вәкиле буларак, табигый сыйнфый чикләнгәнлеге нәтиҗәсе икәнлеген дә өстәү зарур.

Мәсьәләгә шулай сыйнфыйлык принцибыннан якын килсәк, шул ук вакытта проблемага чак кына югарыдан торып карасак, әлеге чикләнгәнлекнең гел субъектив сыйфат кына түгел, бәлки иҗтимагый күренешләргә карата үзенә күрә «объектив» мөнәсәбәт нәтиҗәсе булуы да ачыкланыр. Шагыйрь инануынча, «урак урып, печән чабып», көне-төне тиргә бата-бата тузан-туфракта аунауга караганда, йомшак сәкедә китап карый-карый, яисә гөжләп торган самавырдан чәй эчә-эчә сөйгән яр янында хозурланып утырулары, әлбәттә, яхшырак. Бүгенге позициядән бәяләгәндә, гаделсезлек булган хөкем, хаким сыйныф вәкиле Г. Кандалый өчен, әгәр аның мәнфәгатеннән һәм гомумән сыйнфый җәмгыятьтәге реаль мөмкинлекләрдән чыгып карасак, һичшиксез, дөрес!

...Бу әле зур, тулы дөреслек тә түгел. Игенченең ничек эшләгәнен, ни хәлдә яшәгәнен генә күрү җитеп бетми әле, аның ни өчен, нигә эшләвен, эшләргә мәҗбүр булуын да аңларга һәм шундый хезмәттән башка торып булмавын да онытмаска кирәк. Дөрес, Г. Кандалыйның «мажик хәлен» сурәтләвендә, һичшиксез, күренешләрне реалистик рәвештә сурәтләү омтылышы бар,

әмма бәя бирү һәм аңлау тулы, төгәл булмагач, әлеге реализм да өлешчә гәүдәләнеп, башлангыч хәлдә генә калган. Шул ук вакытта бу күренеш дөньяви татар поэзиясендә реализм принципларының чын-чынлап тернәкләнә, формалаша башлавының да галәмәте иде.

Тормыш чынбарлыгына менә шулай, гәрчә берьяклырак булса да, турыдан-туры якын килергә омтылу Г. Кандалый иҗатында кайбер социаль мотивларның элек күрелмәгән рәвештә калку гәүдәләнүен, кискенрәк яңгыравын тәэмин итте. Мәсәлән, гади крестьян (рухани дәрәҗәле лирик геройның ихтимал көндәше сыйфатында гәүдәләнгән мажик) образы, ягъни көне-төне эшләүдән арып-йончып беткән, иске киемле, пычрак чабаталы «надан ир» кыяфәте, шул заман чынбарлыгы өчен никадәр типик булган булса, аның шулай конкрет чаралар белән тасвирлануы да XIX йөз башы татар әдәбияты өчен шул кадәр үк зур яңалык иде. Мажикны тасвирлаганда, кер, тир, ертык кием, иске чабата, юеш ката, суган, торма, төтенле ызба, сасы ис төшенчәләрен төп сурәтләү чаралары итеп куллану, мөнәсәбәтнең вакыт-вакыт артык тупас булуына карамастан, әлеге образга сәнгатьчә җанлылык, социаль конкретлык бирә.

Автор позициясенең гаделсезлеген икърар иткән хәлдә, аның каләме белән тудырылган образның реалистик дөреслеген дә инкяр итү мөмкин түгел. Ул чор татар крестьянының ярлы һәм керле булуы гына түгел, бәлки надан, димәк, рухи, интеллектуаль культурадан мәхрүм хәлдә яшәве дә – бәхәссез факт. ...Г. Кандалыйның үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: тенденция идея ягыннан бик үк гадел булмаса да, сурәтләү чаралары, тарихилык җәяәтеннән тулаем дөрес иде. Крепостнойлык чорында икеләтә изелүгә дучар ителгән татар крестьяннарының авыр социаль чынбарлыгын, ирнең дә, хатынның да бер дәрәҗәдә үк коллык хәленә төшерелгәнлеген тасвирлауда шагыйрь кайчакларын зур гомумиләштерүләргә ирешә:

Әгәр ирнең хәле:
Гүйәки бер байар колы,
Байарның әмре аркылы
Эш эшләп, кабарып кулы,
Саладыр акча абрукка, –

рәвешендә гәүдәләндерелсә, аның хатыны да шундый ук изелүгә дучар булган:

Эш эшләп унике аең,
Гомер буен кышын-йайен,
Сызып бетеп йөрәк маен,
Каның да калмый кашыкка.
(Сәхипҗамал, III, II, 6)

Рухи һәм мәдәни казанышлардан читкә тибәрелгән, хәтта мәхрүм ителгән гади татар крестьяннары чынбарлыгында хатын-кызларның хәле аерата авыр була. Үзе тулысынча ислам дине өйрәтүләре тарафында булган, шуңа күрә көндәлекле гамәлләрендә «хатын-кыз – ярты кеше» дигән принципларны алга сөргән рухани Г.Г. Кандалый хәзрәткә каршы буларак, реалистик аңы уяна башлаган шагыйрь Г. Кандалыйның иҗатында хатын-кызларның әлеге авыр хәлләрен дөрес яктырту омтылышы киң урын алды. Гәрчә шагыйрь моны хатын-кыз бәхетсезлеге «надан иргә» кияүгә чыгу дип чикләнгән рәвештәрәк тәкъдим итәргә тырышса да, әлеге бәла-казаларның күп очракта ярлы тормыш белән бәйле икәнлеге ап-ачык иде. Г. Кандалый ирләр белән хатыннар арасындагы хокук тигезсезлеге биргән гарип мөнәсәбәтләрне дә ачык күрә һәм яшермичә күрсәтә. Аның инануынча, «надан ир» хөкем сөргән гаиләдә хатынның күргәне җәбер-золымнан гына гыйбарәт:

Тотып, чормап сач үрмәсен,
Ашатды камчы җөрмәсен...
(Сәхипҗамал, XII, 7)

Шулай итеп, шагыйрь Г. Кандалыйның язганнары рухани Г.Г. Кандалый хәзрәтнең табигый инануына да, көндәлек гамәлләренә дә каршы килә. Шагыйрь иҗатында гәүдәләнгән стихияле реализмның – табигый реализмның үзенчәлеге, документаль әһәмияте менә шуннан гыйбарәт, ләкин шагыйрь иҗатындагы андый социаль элементларны тулысынча очраклы рәвештә барлыкка килгән күренеш дип бәяләргә ярамый. Чынлыкта әлеге «стихиялекнең» үзе аңлылык һәм максатчанлык, ягъни билгеле бер ышанычның, эчке иманның чагылышы иде. Ул иманның эчтәлеген исә Г. Кандалыйның, хатын-кыз да, ирләр кебек үк, мәхәббәттә тигез хокуклы, шәхси бәхеткә лаек, дигән карашыннан гыйбарәт иде. Аның һәр әсәрендә диярлек мәгъшука (сөйгән кыз) белән мәгъшук (гашыйк ир) тигез хокуклы тарафлар сыйфатында гәүдәләнә. Г. Кандалыйда кыз өчен калым түләү (кәләшне

сатып алу) мотивы, йәисә мәгъшукага башка берәр юридик һәм матди чаралар ярдәмендә ирешү омтылышы бөтенләй диярлек күренми. Шагыйрь, киресенчә, мал өчен кызыгып, бай иргә чыгуны дөрес дип санамый. Мәсәлән, «*** Колак тотып ишет, җаный...» шигырендәге:

Каушыйк инде бу айда...
Ирадәң (теләгең, ихтыярың) әллә байларда?.. –

дигән сүзләрдән лирик герой үзен «ярлы» итеп күрсәтүе белән калым түләүче түгеллеген дә әйтә, бары байлык өчен иргә чыгучы кызларга карата үзенең тискәре мөнәсәбәтен дә белдерә. Шагыйрь бу ышанычын «Бән сезләрә бер сүземне...» дип башланган, моңарчы әдәбият фәнендә билгеле булмаган әсәрендә аерата калку гәүдәләндерә:

Надан ир малына кызма (кызыкма),
Алар сари (таба) кулың сузма,
Каралык көенә йөзмә, –
Ки булырсән гыйсйан алла (аллага каршы
баш күтәрүче)...
Разый булып ата-ана,
Бирәм дисә ки наданга,.
Алар ризалыкы өчен
Гомерлек хәсрәтә калма.

Шулай итеп, шагыйрь иргә чыгуда кыз балага ата-ана киңәшенә генә ияреп түгел, бәлки үз хисенә ышанып гамәл кылырга куша, малга кызыгуны исә алла ихтыярына каршы бару дип бәяли. Шагыйрьнең инануынча, барган киявенә мәхәббәт сүрелсә дә, хатын-кыз тормышы зинданга әверелә:

Хода кушса ушал йарга,
Мәхәббәт дөкәнсә (төкәнсә – бетсә) анда,
Аның илә мосахибдән (иш һәм әңгәмәдәшлектән)
Ки әфзаль (артык) зиндани, алла...

... Шагыйрьнең, мәхәббәт, шәхси бәхет ул малда түгел, ә чын хистә, һәм кеше хисен хөрмәтли белә торган галим, димәк белдекле кеше белән сөешеп яшәүдә, дигән фикере кызны мәһәр ише никяхның матди интерес якларыннан баш тартуга, мәһәр өчен хәтта ачы керәнгә дә риза булуга чакыруында ачык чагыла:

Ки галимдәй хәбәр килсә,
Атаң-анаң аңар бирсә,
Мәһәрә керәнләр еалса, –
Аны кабул әйләгел, җаный!
(*** Бән сезләрә бер сүземне...)

Шулай ук Г. Кандалый, мәхәббәт һәм тормыш кору мәсьәләсендә кыз үзе дә, язмышка буйсынып кына тормыйча, актив булырга тиеш, дигән фикерне эзлекле рәвештә алга сөрә. Әйтик, иҗатының чагыштырмача башлангыч чорында ук (мәсәлән, «Нисъф әл-мөлякат...» шигырендә): «Атаң ятка биргәнне тоймый калма», мәхәббәтсез кешегә «Бармыйм дигән сүзеңне телдән салма», – дип чакырган Г. Кандалый, соңгырак чор әсәрләрендә дә (Бән сезләрә бер сүземне...) үз хокукын яклауда кызларга оялып-имәнеп тормаска киңәш бирүен дәвам итә.

Шагыйрьнең икенче бер әсәре исә мәгъшукасына оялып-нитеп тормыйча үзенең кемне яратуын ата-анасына ачык әйтергә өндәве белән башланып китә һәм анда оялчанлык (монда: буйсынучанлык та!) бәхетсезлеккә сәбәп дигән фикер үткәрелә. Шул рәвешчә, иске дәвер татар кызын үз язмышына карата актив гамәлгә дәшү мотивы шагыйрьнең соңгы чор иҗат җимеше булган «Сәхипҗамал» әсәрендә йәнә дә көчлерәк яңгырап, тагын да калкурак гәүдәләнә (XIX бүлекчәгә карагыз.) Г. Кандалый кыз баланы ата-анасына карата гына түгел, бәлки мәхәббәтен тәкъдим итүче егеткә мөнәсәбәттә дә туры сүзле булырга дәшә:

Әгәр дә килмәсәң, алдап йөретмә,
Сәүмәгәнеңне бер дә эчдә тотма.
(*** Ки бән яздым сәңа, җанкәм ничә хат...).

Боларның барысы шул чор татар әдәбиятына яңа тематика, яңа геройлар белән бергә мәхәббәт мәсьәләсен аңлауда яңа шагыйрь килүен күрсәтә. Әлбәттә, шагыйрь иҗатында йөз биргән бу яңарыш, үзгәреш җиңел генә, шома гына бармый. Көчле талант ничек кенә иске кысалардан чыкмасын, шагыйрь аңында элекке тәрбиядән калган төшенчәләр, буталчыклар шактый иде. Вакыт-вакыт аның яңа фикерләрне алга сөргән дөньяви эчтәлекле шигырьләрендә дә иске әдәбияттан, дөресрәге, тәсауыф поэзиясеннән килә торган сурәтләү чараларын очратырга мөмкин. Мәсәлән:

Кулым йитмәс, ки тотсам, йар, үзеңне,
Күзем йитмәс, ки күрсәм, йар, йөзеңне, –

дип башланган шигырь, элекке «Алла гыйшкы» хакында лаф орган суфи шагыйрьләрнең әсәрләрен хәтерләтә. Соңрак, шулай беркадәре абстракт чаралар белән эретелгән строфаларны укыгач, нәкъ җитлеккән Г. Кандалыйча әйтелгән юлларга килеп чыгабыз:

Йөзең күрергә теләймен – үзеңне,
Билең кочып сүләшергә сүземне!..

Төгәл бер шигырьдә генә түгел, хәтта бер строфа эчендә дә шундый күчешләрне, дөресрәге, ике дәвернең янәшәлеген – «өйдәшлеген» күрергә мөмкин. Әйтик, түбәндәге бер генә бәйтнең алдагы юлы Алланы күздә тотып суфилар традициясенчә әйтелгән булса, икенчесе, һичшиксез җир кешесенә карата сөю хисен тасвирлый:

Без гарибләр (кимсетелгәннәр) йөзеңне күрсәк иде,
Билең кочып, ләбеңне (иреннәреңне) сурсак иде...
(Фиракындин күземдә йәш корымай)

Ниһаять, югарыда китерелгән мисаллардан «кыз язмышы» мәсьәләсендә ходайның нинди «позициядә торуы» да ачык түгел: бер урында ул язмышка буйсынучанлыкны алла инкярына каршы килү дип бәяләсә, икенче урында «ходай кушкан йарга» мәхәббәт бетү мөмкинлеген дә исәпкә ала...

Шагыйрь иҗатында йөз биргән мондый эзлексезлек, буталчыклык аның «надан» белән «мажик»ны, «бай» белән «галим»не, «бай надан» белән «ярлы галим»не бутавында гына чагылыш таба. Югарыда китерелгән мисалларның кайберләреннән күренгәнчә, Г. Кандалыйның «наданы» ярлы һәм томана «мажик» та, мал-милекле белемсез байгура да була ала. Шулай ук аның тәяаратлы, намазлы галиме дә кул көче белән туенучы гадәти игенчегә әверелә:

Әгәрчә ир галим улса,
Хәлаль кәсеб: иген иксә,
Бозу кыйлып (тәяарәт алу), намаз кыйлса,
Ушал ирдер ки рахманый (алла юлындагы кеше)...
Зирагатдән (иген чәчүдән) әгәр кайтса,
Тиз үк хәләленә әйтсә...
(Бән сезләрә бер сүземне...)

Димәк, шагыйрьнең «мажик» дип сүккәне гел ярлы крестьян булмаган кебек, аның «галим» дип олылаганы да, кайчандыр катькат тукылганча, байлар түгел икән. Кыска тына итеп әйткәндә, Г. Кандалый әлеге төшенчәләр ярдәмендә күпчелек очракта белдексез һәм белдекле, «динсез» һәм «дөрес иманлы» кешеләрне күз уңында тота. Шагыйрь кешеләрнең кешелеклелеген, шәхес буларак кыйммәтен билгели торган критерий сыйфатында аңын, белемен, рухи дәрәҗәсен ала. Дөньяны танып белүдә, кешеләр арасындагы күренешләргә бәя бирүдә мондый рухи критерийларны беренче планга кую мәгърифәтчелек идеологиясе оешкан һәм хөкем сөргән дәверләр өчен хас иде.

Дөрес, Г. Кандалыйның мәгърифәтчелеге шул тәгълиматның идеологларында чагылган максатчан фикер, системалы өйрәтү рәвешендә гәүдәләнми. Ул, Курсави, Мәржанилар шикелле, теоретик гыйльми трактатлар, публицистик китаплар язмаган, әлеге фикерне Утыз Имәни, Акмуллалар төсле нәфис әдәбият, шигырь аша пропагандалауны да үзенә максат итеп куймаган. Г. Кандалый, тормыш ләззәтенә ашкынучы хис иясе буларак, үз аңында оешкан, холкына муафикъ рәвештә тиз узылган әлеге теоретик фикерләрдән туп-туры гамәлгә күчкән. Ул, фикерне тәфсилләп нигезлисе урынга, кабалана-кабалана дигәндәй ашыгып, шашынып, аны әдәби образга – конкрет хөкемгә әверелдергән.

Г. Кандалый сөю хисенең дәрәҗәсен билгеләүдә «мәхәббәт ул алла кушкан эш», «сөю – пәйгамбәр сөннәте», ягъни мәхәббәт – иляһи күренеш дигән, иске карашлар өчен җитәрлек дәрәҗәдә кыю яңгыраган тезислар белән дә канәгатьләнми. Лирик геройның сөю хисләрен тасвирлаган чакта ул дөньяви кешегә – гадәти җир кызына булган мәхәббәтен АЛЛА алдындагы бурычыннан өстен куя. Дөрес, моның кайбер мисаллары аерым әсәрләрдә бер карауга аллага ялвару рәвешендәрәк «гадәти» яңгырый:

Намаз артларындин, җаный,
Телимен алладин сәни...
(*** Колак тотып ишет, җаный...)

Шулай намаз, ягъни аллага коллык белән янәшә куелган мәхәббәт тора-бара мәчеткә үк кереп китеп, андагы менбәрне– дини вәгазь кафедрасын – гыйшыклык хәлләрен игълан кыла торган трибунага әверелдерә:

Ишет хөтбә гыйшыклык мөнбәрендән:
Бәйан идәм мәхәббәт гъәнбәрендән.
(*** Ишет хөтбәгыйшыклык гъәнбәрендән...)

Кешенең сөю хисен иң калку гәүдәләндергән «Фәрхи» дә әлеге мотив көчәйтелә төшә:

Күз-кашыны мәсҗедә михраб идәм,
Сурәтенә көзгедик мәхабб идәм!

Димәк, кызның күз-кашы Мәчеттә кыйбланы, ягъни табына торган тарафны күрсәтүче урынга – михрабка, ә аның сурәте исә гадәти күзгә күренми торган серле җиргә (мәхаббка) – иляһи объектка әверелә икән. Кыскасы, әле генә ярдәм сорап Аллага мөрәҗәгать иткән шагыйрь, аның кодрәтенә ышануга кул селтәгән мәҗүсидәй, сөйгәненең образын табына торган потка әвереләдереп, шуңа сәҗдә итә...

Яшьлегендә гел дини тәрбия алган, «хак мөселман» буларак, формалашкан, соңрак руханилык вазыйфасын үтәп яшәгән ир агасының гади җир кызы – крестьян кызы образын шул рәвешчә алла образына каршы куюы да гадәти генә «юлдан язу» йәисә «динсезлек» күренеше түгел, бәлки шагыйрьнең мәхәббәт хисенә, кешенең шәхси, интим бәхете мәсьәләсенә мөнәсәбәте, иҗтимагый позициясе чагылышы иде.

...Г. Кандалый кеше матурлыгын чын-чынлап олылап, аның физик гүзәллеген күреп, тоеп сокланыр өчен сүз сәнгатенең генә җитеп бетмәвен яхшы сизә, шуңа күрә ул Мәгъшукасының кыяфәтен рәссамнардан ясатуны хыял итә:

Сурәтләр кыйлмага остад (остаз)
Сурәтеңне ясатып яәфтад (җитмеш).
Итәрдем халкара мәншүр (нәшер итү, тарату).
Иә сурәт кыйлгучыларга
Сәнең өчен варыйм микән? –
Сөеп йөргәнләрен, җаный,
Китә белмәс күз алдымдин...
(Шәфгый, III, 5; V, 2)

...Сөйгән ярның матурлыгын күрә белгән, чын гүзәллектән соклана алган Г. Кандалыйга мәгъшуканың сынын шулай рәсемдә тудыру бәхете насыйп булмый, шуңа күрә шагыйрь сурәтне сүзләр ярдәмендә генә ясау белән канәгатьләнә һәм бу юнәлештә ул традицион кара кашлар, алсу йөзләр, ак якутлар, нәргис күз-

ләр ярдәмендә тасвирлап, гүзәл кыз рәсемен тудырудан тыш, аңа хәтле әдәбиятыбызда мисалы күрелмәгән кыю, тоеп сокланырлык конкрет образлар тудыра:

Имиләреӊ икән зурлар,
Кояштик бирәдер нурлар,
Тамаша каладыр хурлар
Бу халемезгә оҗмахда!
(Сәхипҗамал, XXIII, 7)

Югарыдагы мисалны зур казаныш үрнәге сыйфатында бәяләүнең икенче бер сәбәбе дә бар. Ул шагыйрь кичергән иҗади үсүнең, яңага таба үзгәрүнең эчтәлегеннән гыйбарәт. Моны аңлар өчен тагын «Рисалә»гә әйләнеп кайтыйк. Әгәр әдәбиятка таба беренче адымнарын ясаган Г.Г.Кандалыйшәкерт шул поэмасында укучыларын җәннәттәге хур кызларыннан сокланырга чакырса, «Сәхипҗамал»да исә әлеге «иляһи» гүзәллеккә ия җәннәт чибәрләренең үзләрен җир кызының табигый матурлыгыннан сокландыра.

...Шагыйрьдә мәхәббәт хисенең дини ритуаллардан өстен куелуы, югарыда күргәнебезчә, Аллага ышанычка каршы куелуга кадәр барып җитә язган икән. Мондый фактларны бер «Фәрхи» әсәре өчен генә хас ялгызак күренеш дип карарга ярамый. Г. Кандалыйда мәхәббәтне, гомумән. дини иманга каршы кую очраклары да бар:

Бу инәлүләрем таш да белерде, –
Урыс кызы динен ташлап кәлерде.
(*** Китайларда бу сүзне күргәнем бар...)

Г. Кандалый җир тормышының күренеше булган мәхәббәтне шул тормышның чиге – «нәтиҗәсе» булган Үлем кебек фәлсәфи зур категория белән дә чагыштырып карый, хәтта мәхәббәтне үлемнән өстенрәк куя:

Гыйшыклык Мисаледер яхшы гөлдер,
Алалмасаң, ахыры бер үлемдер...
(Мәгъшукнамә)

...Мәхәббәтне болай «мәңгелек категория» итеп карарга омтылу Г. Кандалыйның Бәдига исемле бер кызга багышланган шигырендә гаять образлы һәм көчле әйтелгән. Мәсәлән, Зөләйханың – Йосыфка, Сәйфелмөлекнең – Бәдигыльҗәмалга,

Мәҗнүннең – Ләйләгә, Фәряадның Ширинга булган олы сөюләре, аларның мәхәббәт юлындагы ая-зарлары хакында язгач, шагыйрь үзендәге хиснең көчен дә шул олы мәхәббәтләр дәрәҗәсенә күтәреп бәяли:

Бу гашыйклык чабы китде
Сарапул берлә Самарга;
Йосыф берлә Зөләйхатик
Атымыз калды санарга.
(Сәхипҗамал, XVIII, 3)

Болай бер шәхси мәхәббәт иясен дөнья әдәбиятларындагы зур гашыйклар дәрәҗәсенә күтәрү, асылда шагыйрьнең үз мәхәббәтен олылау максатыннан килеп чыккан булса да, ул ахыр чиктә һәр конкрет мәхәббәт хөрмәткә, алкышка лаек дигән фикерне үткәрүгә хезмәт итә. Җенси сөю хисе ул гадәти генә мәел омтылышы түгел, бәлки көчле хис белән бер-берең̧ә тартылу аша ике җанның рухи кушылуы, берләшүе, ары таба бербөтенгә әверелүе дигән сүз:

Күз карашын җан эчендә җан идәм,
Шөгъләсене (яктылыгын) тән эчендә кан идәм...

Шагыйрь аңындагы мәхәббәткә карата булган менә шундый тирән мәгънәле гомум мөнәсәбәт аның конкрет әсәрләренә дә характерлы эчтәлек белән бергә кабатланмас сыйфатны – мәхәббәт лирикасында чын әдәби шедеврлар тудыру мөмкинлеген бирде. Әйтик, Мәгъшукасын иң матур, иң ягымлы сүзләр белән мактый, олылый, иркәли, эретеп җибәрер дәрәҗәдә назлый алуда шагыйрь искитәрлек хис юмартлыгы күрсәтә:

Ай гынам ла, көн генәм лә, гөл генәм,
Җан гынам ла, тән генәм лә, көн генәм!
Җәүһәрем лә, гәүһәрем лә, нур гынам,
Сәрвием лә, җәннәтем лә, хур гынам!..

Болай матур сүзләрне өсте-өстенә өеп хис «ябырылдыру»да, ябырылып ишелгән әлеге назлы хисләрне «тугылау» юлы белән гашыйкның Мәгъшукасенә булган ихлас омтылышын җыр югарылыгында гәүдәләндерүдә шагыйрь Сәхипҗамалга мөрәҗәгатендә аерата виртуозлык күрсәтә. Элек ул мактауны үзеннән, дөресрәге, сылу кыз сыйфатының үз күң̧еле аша ничек кичүен тасвирлаудан башлый:

Гөлем бул, гөл йыгачым бул,
Йә былбыл-сандугачым бул,
Бу дәрдемгә гыйляҗем (чара) бул,
Сәхипҗамал абыстай ла!

Шул рәвешчә, үз халәтен тасвирлаган шагыйрь аны шундый хәлгә төшергән чибәрнең күркәм сыйфатларына күчә:

Йөзең алсу кызыл гөлтик,
Йаңакың кызыл алматик,
Кызыл алма кеби кызны
Насыйб итәр микән алла?
Кашың кара тумышыңдан,
Битең һәм якты гөлбостан,
Сәнеңтик зифа җан дустдан
Аермасын кәрим (бөек) алла!

...Г. Кандалыйның әдәбиятыбызда тоткан бер мөһим урыны, аның мәхәббәт дигән гаҗәп хикмәтле, серле һәм олы күренешне шул рәвешчә әдәби фикер урталыгына әдәби герой сыйфатында куя алуыннан гыйбарәт. Дөресен әйткәндә, шагыйрь башка шигырьләрендә дә, «Сәхипҗамал» әсәрендәге кебек үк, теге яки бу гүзәлне генә йәисә бер үзенең гыйшык маҗараларын гына түгел, бәлки кешенең иң олы хисләренең берсе булган мәхәббәт дигән гаҗәеп хикмәтле күренешне төп герой итеп гәүдәләндерә алган.

...«Сәхибҗәмал» әсәренең төп герое сөю хисе, мәхәббәт дигән сүзләр очраклы гына әйтелгән, йәисә ялгыш ычкынган купшы гыйбарә түгел. Г. Кандалый ул, шагыйрь буларак, һәр җилфердәгән итәк артыннан олагып китүче примитив җилбәзәк түгел. Ул күпкә катлаулы һәм трагик шәхес. Бер үк вакытта аның катлаулыгы үзенең искитәрлек гадилегеннән килә. Ул, тормыш һәм гамәлләрендә, үзенчә садә кеше буларак, шигырьләренә үзенең сөйгәннәре белән бергә аңар артык кагылышы булмаган башка кызларның да исемнәрен керткән. Әйтик, аның Әминә дигәннәре сабакташ егетнең сөйгәне булса, аңа багышланган шигырьне Г. Кандалый әлеге иптәше исеменнән язган.

Җәмилә белән Рабиганең, хәтта Фатыйманың да шагыйрьнең үз сөйгәннәре булуы расланмый. «Фәрхисорур» исеменең реальлеге бик тә шөбһә тудырган кебек, «Бәгъидә» исеменең барлыкка килүе дә – зур аңлаешсызлык нәтиҗәсе. Бәдига дигән чибәргә

багышланган әсәр исә, чын гашыйкның өзелеп инәлүеннән бигрәк, кызны читтәнрәк күзәтүче шагыйрьнең мәхәббәт хакында гомумән фикер йөртүен, әлеге кыздан бераз көлеп алуын хәтерләтә. Гомумән, шагыйрь әсәрләрендә очрый торган һәр хатын-кыз исемен дә шагыйрьнең үз мәхәббәтенә бәйләргә нигез җитми. Алар Г. Кандалый әсәрләренә төрле сәбәпләр аркылы килеп кергән, кайберләре – очраклы исемнәр.

Хатыннарны өчәү-дүртәү итеп асраса да, шагыйрь Г. Кандалыйның чын мәхәббәте бер генә – Сәхипҗамал гына булган. Әдәби яктан иң көчле әсәрләренең берсендә чын-чынлап табыну объектына әверелгән Фәрхигә килсәк, монда мәсьәлә катлаулырак, һәм ул махсус карауны сорый.

Югарыда бер әйтеп узганымча, Фәрхи туташ исемен эченә алган әлеге шигырьләрнең башта Сәхипҗамалга адресланып язылган әсәрләрдән, аннары, мәхәббәте тәмам кире кагылгач, Сәхипкә ачу итеп, икенче чибәргә, Фәрхигә, «гыйшык тоткан» һәм шуңа өйләнергә ниятләп йөргән вакытта (уңышсыз мәхәббәт газабыннан акылсыз гамәлләр барлыкка килү киң таралган күренеш...) шагыйрь тарафыннан адресаты һәм беркадәр структурасы үзгәртелү нәтиҗәсендә оешкан булуы ихтималга якынрак. Киресенчә булганда, олы яшьтәге Г.Г. Кандалыйның кайчандыр үзе мәчет михрабы итеп табынган Фәрхиен аерып җибәрү факты аңлашылып җитми. Сәхипҗамалга багышланган әсәрләрендә: «юлыкдым аңлы-миңле җүләр ярга...», «отыйм дигәндә отылдым...», «соңындан көчкә котылдым, – ки биш ел соң...» – дигән ачы үкенүле сүзләре әлеге ялгышка, әлеге дуамал өйләнү һәм аерылышуга ишарә булса кирәк.

...«Сәхипҗамал» әсәренең төп герое исеме, аталган чибәр кыз булудан бигрәк, шул кызга карата туган хис – мәхәббәт дип танысак, бу әсәрнең жанры хакында барган бәхәсне (поэмамы, түгелме, дигән бәхәсне) икенчерәк югарылыктан торып хәл кылырга мөмкин шикелле – бу әдәбиятчыларыбыз алдында торган бурыч.

Г. Кандалый иҗатында гәүдәләнгән трагизм исә ул – беренчедән, шагыйрьнең идеалы белән реаль чынбарлыкның, шул нигездә сүзләр белән гамәлләрнең бәрелешүенә барып тоташса кирәк. Тормышында, конкрет гамәлләрендә рухани мохит җимеше сыйфатында полигамчы (күпсөяр – күп хатынлы) булган Г.Г. Кандалый хәзрәт, хисендә, идеалында моногамчы-берсөяр һәм чынлап та сөя белүче шагыйрь Г. Кандалый иде.

Икенчедән, чын гыйшыклык хисенә сәләтле, гадәти җир мәхәббәтен иляһи җыр югарылыгына күтәрә алырлык югары зәвык, нечкә күңелле эстет шагыйрьнең табигатьтән килә торган эчке гүзәллегенә аның тышкы кыяфәте – физик зәгыйфь үк булмаса да чыраеның ямьсезлеге туры килми иде. Сәхипҗамалның озак инәлдерүләрдән соң бер күнеп, аннары биргән вәгъдәләреннән кире кайтуы («Эшем дә йитдε чигенә, Сәхипҗамал кире чигенә...») шагыйрьнең шушы тышкы сыйфатына бәйле булса кирәк, һәрхәлдә, меңләгән шигъри юлларның берсендә дә, ялгышып кына булса да дигәндәй, лирик геройның үз кыяфәтенә (физик көченә, ирләрчә матурлыгына) ишарә итмәве әлеге ямьсезлек хакындагы хәбәрнең (И. Бәхтиев җыйган мәгълүматлардан) дөреслеген куәтли төшә.

Шул рәвешчә өзелеп, ихлас күңелдән сөйгән яр аның чын мәхәббәтен кире кагу нәтиҗәсендә шагыйрьнең үз Мәгъшукасы хакындагы шәхси көенүләре мәхәббәт турында гомумән уйлануларга, борчылуларга– олы кайгыга әверелә. Күп очракта Г. Кандалыйның гомумиләштергән рәвештә фәлсәфи фикер йөртүләргә күчүе аның күңелендә шәхсилек белән гомумилекнең шулай бәрелешүен, укмашуын, хәтта буталуын барлыкка китерде. Шагыйрьнең Сәхипҗамалга булган көчле мәхәббәтен тасвирлауга багышланган төп әсәре сөю хакындагы әлеге фәлсәфи сорау белән тәмамланган шикелле, мәхәббәтнең сере – табигате турында гомуми уйланулар рәвешендә язылган әсәрләре дә шактый. Мисал өчен аның «Бәдрелямигъ дилбәрә...», «Бер тамаша бу гыйшыклык...» дип башланган шигырьләренә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Әдәбиятка Г. Кандалый алып килгән яңалык – яңа тематика, яңа герой, яңа мөнәсәбәт сөю хисе дигән бер карауга үтә шәхси, интим күренешне шәхес бәхете, аның бәхеткә хокукы – шуларның һәммәсе аша кешенең җәмгыятьтәге дәрәҗәсе дигән зур киңлекләргә алып чыкты. ...Беренче әсәрләрен ясалма телдә язудан башлаган шагыйрь әдәби эшчәнлегенең соңгы чорында халык теленнән аерылмаслык дәрәҗәдә гади итеп язу югарылыгына күтәрелде.

...Шагыйрьнең Кол Галидән өйрәнә башлавын аның яшьлек чорына караган әсәрләреннән үк күрергә мөмкин. Мәсәлән, «Назме Йосыф» һәм «Нисфел мөлякат...» шигырьләре поэтик формалары буенча да, аерым мотивлары, сурәтләү чаралары ягыннан да шундый әсәрләрдән. Боларга «Унике күркә...» дип башланган

парчаны һәм Г. Кандалыйныкы булуы ихтимал «Мәдех кыйлсам, охшайүрсән...», «Кәҗә бәете» әсәрләрен кушып карасак, дәлилләрнең саннары тагын да ишәһ төшә.

Бу аталган миссаллардан «Нисф әл-мөлякат...» шигыре аерата игътибарга лаек. Аны әтрафлап анализлау, беренчедән, яшь Г. Кандалый ияргән үрнәкне төгәлрәк ачыкларга ярдәм итсә, икенчедән, аның каләменнән чыккан шигъри «хатның» башкалар тарафыннан да ничек эшкәртелүен, үзгәрүен, ягъни фольклорлашуын күрергә мөмкинлек бирә. Өченчедән, бу әсәрен язган чакта Г. Кандалый үзе дә шәкертләр репертуарындагы башка төр китаби фольклор истәлекләреннән файдаланган икән. Мәсәлән, әлеге шигырьнең 22 строфасында «Хатасыз һич кем булмас хакъдин үзгә» дигән бер юл бар. Ул – кулъязма китапларның бетем өлешендә кулланыла торган махсус формуладан үзгәртеп алынган. Укучылардан күчермәдә китүе ихтимал хаталар өчен алдан ук гафу үтенү нияте белән язылa торган, Г. Кандалыйга хәтле үк киң мәгълүм булган әлеге формула болайрак яңгырый:

Хат хатадыр, хатасын орма йөзгә,
Хатадин хали ирмәс (азат түгел) хакъдин узгә...
Хата ирсә – каләм илә сыйаяы (язу карасы),–
Фәкыйрь язгучының күпдер гөнаһы...

Соңрак чор Г. Кандалый иҗатындагы Кол Гали йогынтысын өйрәнгән чакта андый тәэсир күренешләрен ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төр сыйфатында әлеге истәлектәге кайбер сурәтләү чараларының язучыда демонстратив рәвештә турыдан-туры файдаланылуын (юлларны, строфаларны чак кына үзгәртеп, үз текстына кертеп җибәрүләрне), шулай ук әсәр геройларын төгәл атап, охшаш вакыйгалар, ситуацияләр хакында ачык хөкем йөртүләрне алырга кирәк.

...Г. Кандалыйга Кол Гали ясаган тәэсирнең икенче төрен борынгы шагыйрь тудырган кайбер образларның системалы рәвештә кабатлануы, үстерелә-үстерелә кулланылуы тәшкил итә. Конкрет мисал рәвешендә сәба (сәбах) җиле – иртәнге җил образын алырга мөмкин. Кол Галидә ул җил сөекле улыннан аерылган, олы хәсрәттән сукырайган карт атага алла кодрәте белән баласының исәнлеге хакында хәбәр китерүче иляһи зат сыйфатындарак тасвирлана һәм, әйтергә кирәк, сәнгатьчә көчле, матур тәкъдим ителә...

Сәба җиле образы Г. Кандалый иҗатында да аерата мөһим урын биләде. Дөрес, ул образ тәүге мәртәбә Г.Г. Кандалый шәкерт әсәренә («Рисалә», XVIII, 7) үлем якынлыгын хәбәр итүче галәмәт сыйфатындарак килеп керә. Әмма соңрак, шагыйрь иҗатында барлыкка килгән кискен борылыш нәтиҗәсендә, ул образ, әлеге серлелектән арынып, гади җир кешеләренә якын, хәтта аларның телләрен белүгә, серләрен аңлауга, хәлләренә керүгә сәләтле дөньяви күренеш – кеше өчен кадерле иртәнге җиләс җил рәвешендә гәүдәләнә.

...Илләр, сахралар, галәмнәр гизеп йөрүгә сәләтле сәба җиле, ихтыяҗы чыга калса, безнең татар авылларына кагыла, конкрет кешеләр белән очраша, гашыйкларның йомышларын үти:

Сәба йиле, исәр булсаң,
Парау атлыйг нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән
Сәхипҗамал абыстайга!
("Сәхипҗамал")

Шул ук вакытта Г. Кандалыйның сәба җиле гашыйклар арасында арадашлык итүче «өченче тараф» сыйфатында гына калмый, бәлки вакыт-вакыт аларның берсе белән кушылып китә яза, йәисә ихтыяҗларын үтәүдә аларның актив «хезмәттәшенә» әверелә:

Утырып сәба йиленә,
Очардем Парау иленә,
Куеп кулымны биленә,
Кысып Сәхипҗамалемне...
(«Сәхипҗамал», II, 4; XXI, 11)

Шулай итеп, Кол Галидә иляһи бер көч сыман серлелеккә өретелгән, шунысы белән абстрактлыгы көчәйгән, матур тасвирланган сәба җиле әдәби геройга әверелә. Сәба җиле образы шагыйрьнең картлык көнендә аңар тагын да якыная төшә, бала кайгысында интеккән хәсрәтле карт ата өчен иң якын сердәшкә әверелә. Улын өзелеп сагынган чакта туганнардан аерылышу темасына мөрәҗәгать иткән автор:

– Әйа йил, сән китәр булсаң...
Туганымны күрәр булсаң,
Дога дигел ки безләр дин, –

дип, үзенең иске дустына ялвара, шул рәвешчә җил образы яңа функцияләр исәбенә байый.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, борынгы язма истәлектән алынган, яңа психологик шартларда яңача трактовкаланган образда халык авыз иҗатыннан килә торган төсмерләр, әдәби чаралар аз түгел, Г. Кандалый борынгы шагыйрь яңгыраткан фикерләрне, шигъри сурәтләрне, анализның баш өлешендәге кайбер мисалларда чагылып киткәнчә, механик күчереп алу белән чикләнми. Ул үзе кабул иткән андый детальләрне иҗади үзгәртеп, сәнгатьчә үстереп ала. Мәсәлән, борынгы болгар-татар шагыйрендә егеткә гашыйк патшабикә Зөләйха «кол малайның» чәчләрен тарап, энҗеләр үрсә, Г. Кандалыйда сөйгән ярның чәчләрен татарча «майлап тарап үрү» белән галим ир шөгыльләнә («Сәхипҗамал», VIII, 9).

Безнең шагыйрь, кызга мөрәҗәгать итеп, «Сурәтең дөшемә керер, Дөшем эчрә күзем күрер» дип язса, укучы Зөләйханың төш күрүләрен искә төшерә. Сәхипҗамалның сүз тыңламыйча надан кияүгә чыгып, мажик иреннән күрәчәк ихтимал җәфалары хакында сөйләгән чакта шагыйрь үҗәт кыздан ничек көләчәген хыял итә:

Йибәрермен язып, көлеп:
«Менә, Сахиб, кияү сайла!».

Бу юлларны укыган чакта, изге төш күргәнлеге өчен, Йосыфны кыйнаучы көнче агаларының шәфкать сорап ялварган малайга: «Ялган төшең ярдәм бирсен!» – дигән мыскыллы җаваплары искә төшә.

Мондый сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә нык яшерелгән эчке уртаклыктан тыш, Г. Кандалыйда үрнәк әсәрдән кабулителгән детальләрне фольклорча әйтелгән шигъри юллар белән үреп, халык авыз иҗаты исәбенә баетып бирелгән очраклар да шактый. Әйтик, түбәндәге ике бәйтнең беренчесендә кайчандыр Кол Гали кулланган сурәтләү алымнары сизелеп торса, икенчесендә халык җырларын-алынган буяулар өстенлек итә:

Тулган айдик йөзең матур икәндер,
Ике битең кояш кеби икәндер.
Кашың кара сызылган күз өстендә,
Яңа айдик яауада – күк өстендә.
(«Фәрхи»)

...Г. Кандалыйның халык иҗатына кеше бәхетен, аның мәхәббәттәге хокукын гуманистик планда аңлаган Кол Гали мирасы аша килә. Фольклор байлыгына шул яссылыкта якынлашкан шагыйрь иҗатының зур өлешендә мәкаль һәм әйтемнәрдән, җыр һәм мөнәҗәтләрдән актив файдалана, образлы, кыска һәм йомры итеп әйтү юлында халыктана өйрәнә. Мәсәлән, халыктагы «сайлаган – сазга, очраган базга» дигән фикер сюжеты шагыйрьдә мондый конкрет үрнәкләрен таба:

Баралсаң мәндиинартыкка ярый ла,
Сәнеңтик сайлаган сазга тарый ла!

(«...Сөйгәнемә инанмасаң, Бәдига»
һәм «...Сәламулла күземнең карасыйга»)

Бу сайлавың гакыл азга,
Ки сайлаган кеше – тазга,
Йә төшәдер лә ул базга, -
Батып чыкмас, и җанкәй лә!

(«Сәхипҗамал», XX, 8)

...Г. Кандалый иҗатында фольклор традицияләре тоткан урынны дөрес күзаллар өчен, ниһаять, аның шигырьләренең формасы, стиле һәм сәнгатьчә техникасы мәсьәләләрен дә этраффлап өйрәнү зарур. Бу урында, андый махсус филологик проблемаларга тукталып тормыйча, бер характерлы күренешкә генә кыскача кагылып узу белән канәгатьләнәбез.

Г. Кандалый күпчелек шигырьләрен үзе яшь чакта ук яхшы үзләштергән ике үлчәмдә язарга яраткан: һәр берәмлеге унбер иҗектән торган бәйт (икеюллык) һәм юллары сигезәр иҗекле дүртьюллык (үзенчә әйткәндә: «дүрт пай» йәисә «робагый»). Шулардан безне беренче нәүбәттә сигезәр иҗекле дүртьюллыкларның эчке структурасы кызыксындыра. Халык иҗатында, мәгълүм булганча, кыска җырларның эчке төзелеше 2+2 формуласына туры килә (строфаның аналогия булдырыр, настроение тудырыр өчен әйтелә торган гомумирак мәгънәдәге беренче яртысы һәм җырның төп эчтәлеген тәшкил иткән соңгы икеюллы-ты). Г. Кандалый халык җырларының шушы сыйфатын киң файдаланып, 2+2 формуласы буенча төзелгән строфалардан тыш, әлеге алымны йәнә дә үстерә төшеп, 1+1+2 йәисә 2+1+1 формулаларын да тудыра.

...Аның күпчелек шигырьләрендә строфалар үзара бер-берсенә йомшак «ябыштырылган» шикелле, зур күләмле әсәрләре эчендә дә строфалар көлтәсеннән торган цикллар арасындагы оешканлык күзгә бәрелеп тормый. Шагыйрь иҗатындагы фольклор традициясеннән килә торган менә шушы хосусият Г. Кандалый әсәрләренең халыкта аерым бүлекләргә, хәтта строфаларга сүтелгән хәлдә таралуына киң мөмкинлек биргән; икенче яктан, шул ук күренеш, әлеге «өлешләрдән» йәнә бер «бөтенне» оештырырга омтылу аркасында, шагыйрь әсәрләре күчермәләрендә төрле «вариантлар» барлыкка килүне тәэмин иткән. Шагыйрь мирасындагы кабатлану, вариантлылык күренешенә Г. Кандалый шигырьләренең халыктагы яшәеш хосусияте дип карарга да тиешбез.

...Г. Кандалый, чуар күңелле мавыгучан ир-ат буларак, теге яки бу сәбәп белән игътибарын җәлеп иткән чибәрләргә (мәсәлән, Фатыймага, Җәмиләгә, Вәдигагә) тиз-тиз шигырь-мәдхия, йәисә мәхәббәт мәктүбе оештыруга иренмәгән, кайчакларда иптәшләре өчен дә шундый көйле хатларны язудан – заказ үтәүдән баш тартмаган. Ул кайбер әсәрләрен электән үк әзер строфаларны яңадан сипләү, чак кына үзгәртеп, өстәмәләр ясау юлы белән дә оештыру алымыннан киң файдаланган. Язылган һәм язылачак текстларга карата булган мондый иркле мөнәсәбәттә профессиональлек аңыннан бигрәк үзешчәнлек хисе, фольклорча иҗат башлангычы өстенлек итүен күрүе кыен булмаса кирәк.

Башкачарак итеп әйткәндә, эшчәнлегенең башлангыч чорында әдәби профессиональлеккә дәгъвә иткән («Рисалә» һәм «Кыйсса»ларны китаби кагыйдәләр белән оештырып, авторлыгын кат-кат ачык әйткән) Г. Кандалый иҗатының җитлеккән, ягъни шагыйрь буларак чын сәнгать осталары кодрәтенә ирешкән дәверендә үзен каләм белән кәсеп итүче дип түгел, бәлки халык авыз иҗаты дөньясының бер вәкиле сыйфатындарак хис кылган булырга тиеш. Шуңа күрә, аның соңгы дәвер әсәрләре тәмам халыкчан телдә язылган кебек, аларда авторлык дәгъвәләре дә бөтенләй яңгырамый.

Бер үк вакытта шагыйрь үзен тудырган, тәрбияләп үстергән мәдәни традицияләрдән дә тәмам аерылып китми шикелле. Сөйгәне Сәхипҗамалга аның саф ана телендә: «И матурым, гүзәлем лә, Ничек кенә түзәлем лә? Өзеләдер үзәгем лә...» дип, чын халыкчан һәм шагыйрәнә мөрәҗәгать иткәне, хәтта бер мәлгә тупас наданга әверелеп: «...Кеше сүзенә Бакып хур булма,

и дура!» – дип мишәрчәләп тә сүгә алганы хәлдә, теле ачылган иске язма әдәби стильне дә бөтенләй ташламый. Мәсәлән, Сәхипҗамал хакында ихлас сокланып, ихтимал, үзе өчен генә иҗат иткән бер әсәре – «*** Бәдре-лямигъ дилбәрә гыйшык тотышмын бинәва...» дип башланган, иске классик әдәбиятыбыз таләпләреннән бәяләгәндә бәхәссез шедевр дәрәҗәсенә күтәрелгән шигыре шуны раслый. Димәк, шагыйрьнең халыкчан гади итеп язуы, «мажикча» сүгенеп җибәрүе гадәти стихиялек күренеше, йәисә «ничек булдыра алса», шулай гына язу нәтиҗәсе түгел икән!

Г.Г. Кандалыйны бу елларда, күрәсең, тәсауыф әдәбиятында сурәтләнгән гаделлек хакындагы купшы сүзләр, нык яшеренгән социаль демагогия дә җәлеп иткән булса кирәк. Фаразның дөреслеккә якын булуын «Кыйсса»ның идеяләре күрсәтә. Матди байлыктан ваз, кичеп, дәрвишлек юлын сайлаган Ибраһим солтан, Эльдорадо эзләгән кебек, утыз-кырык ел ил гизеп йөреп тә, әллә нинди нәтиҗәләргә ирешә алмый: бер җирдә аны җәберләүчене кыйныйлар, икенче җирдә үзен тотып яралар, өченче урында мәсьәлә коры сүз, буш бәхәстән узмый. Нәтиҗәдә, кире кагу бар, раслау юк дәрәҗәсендә. Чын суфичыл әдәбиятта, мәгълүм булганча, «раслау» бик нечкә һәм эзлекле рәвештә эшкәртелә, шуңа күрә дә ул гасырлар буена кеше аңын били килгән.

Кыскасы, яшь Кандалыйда суфичылык идеясе җитәрлек дәрәҗәдә көчле булмый. Соңрак, реаль тормыш киртәләре белән турыдан-туры бәрелешкә кереп, китаби өйрәтүләр һәм шәхси омтылулар арасындагы аерманы ачыграк күрә башлагач, элекке нык булмаган суфичыл идеяләр нигездән үк җимерелә.

# ГАБДЕЛЬДЖАББАР КАНДАЛЫЙ[1]

*Азат Ахунов*

Кандалый Габдельджаббар Габдельмаджид угылы (1797, д. Ст. Кандал Ставропольского уезда Самарской губернии – май 1860, там же), поэт. Писал на татарском и арабском языках. Псевдоним «Кандалый» образован по названию родной деревни. Из семьи муллы. В течение 17 лет обучался в медресе Казанского, Тетюшского, Чистопольского уездов Казанской губернии, Ставропольского уезда Самарской губернии. Частая смена медресе была связана с тем, что в своих стихах и эпиграммах Кандалый высмеивал порядки и систему преподавания в этих учебных заведениях. Отличался большими способностями, в силу чего, ещё будучи шакирдом, привлекался к преподаванию арабского языка на младших курсах медресе. В 1824 г., после получения права на занятие духовной деятельностью, вернулся в родную деревню, был имам-хатибом. За критику в стихах мусульманского духовенства, воспевание женских образов (что противоречило сложившимся традициям), а также за нарушение некоторых норм шариата в 1840 г. собрание мусульманской общины Ст. Кандала поставило вопрос о лишении Кандалыя духовного сана. Это предложение не набрало достаточного количества голосов, но вынудило Кандалыя уйти с должности. В 1843 г. он возглавил организованную его единомышленниками 2-ю махаллю. В 1848 г. мусульманские власти назначили в его приход нового имама и мударриса. Таким образом Кандалый был отстранён от дел, что ограничило его влияние на жителей махалли. Около 2 лет провёл в заключении (время и причина ареста неизвестны).

Кандалый был разносторонне образованным человеком. Помимо усвоенных в медресе арабского и персидского языков, самостоятельно изучил русский, мордовский и чувашский. Умел переплетать книги, варить мыло, класть печи, чинить замки.

Своё первое крупное произведение – «Рисаләи-л-иршад» («Книга наставлений на праведный путь», около 1815/16 гг.)

---

[1] Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. Г.С. Сабирзянов. – Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 2006. Т. 3: К–Л. С. 217.

Кандалый написал в годы обучения в медресе. Это религиозно-дидактическая поэма, состоящая из вступления, 28 глав и заключения в виде мунаджата. Автор призывает читателей к праведности, которая, по его мнению, возможна лишь в рамках мусульманской религии. В поэме звучат мотивы бренности земного существования, подчёркивается необходимость подготовки себя к будущей вечной жизни. Для этого, считает Кандалый, необходимо изучать науки, делать добрые дела, отвергать зло, хитрость и коварство, не предаваться страстям, быть терпеливым. Высоко ценя учёность, Кандалый позволяет себе некоторое высокомерие по отношению к крестьянам. Труд хлебороба кажется ему недостойным образованного человека.

Следующее крупное произведение Кандалый – этико-философская поэма «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» («Сказание об Ибрагиме Адгаме») представляет собой часть большого сочинения (в полном объёме до нас не дошло), написанного предположительно также в годы учёбы. Название поэмы условно, дано по имени одного из главных героев, прототипом которого послужила реальная историческая личность – султан Балха Ибрагим Адгам (ум. в 874/875). В поисках истины он решил оставить трон и под видом дервиша отправился странствовать. Мудрость и набожность Ибрагима Адгама вызвали симпатии халифа Харун ар-Рашида (763/766–809), который предложил ему остаться советником при дворе. Однако Ибрагим Адгам предпочёл жизнь дервиша, выбрав путь служения Аллаху. В следующих частях поэмы говорится о юноше из д. Кандиле «Булгарской страны», который в поисках знаний отправился в странствие. На этом повествование обрывается. Заключительная часть сохранившегося текста имеет назидательный характер в духе произведений средневековой восточной литературы. Новаторская для своего времени поэма «Сәхипҗамал» («Сахибджамал») относится к позднему периоду творчества Кандалый. Она написана в эпистолярном жанре, в ней нет действия и единого сюжета. Впервые в татарской литературе воспета земная любовь к женщине:

Лишь за тебя молился я, молясь, с тобою слился я.
Свою молитву и мольбу облечь в стихи решился я.
О, редкой красоты кристалл, любовь моя, Сахибджамал!

(*Перевод Р. Морана*)

Кандалый создал обаятельный образ простой крестьянской девушки, затронул проблему безрадостной жизни татарской женщины, обречённой на тяжёлый физический труд и душевные страдания. Обращение поэта к девушкам с призывом самим выбирать возлюбленного, следовать велению сердца противоречило патриархальным установкам, что вызвало резкую критику со стороны мусульманского духовенства. Находясь в тюрьме, Кандалый написал на арабском языке комментарий к поэме Аллахияра Суфия «Субат аль-гаджизин» («Неукротимость немощных»).

Язык произведений Кандалый начала периода творчества отличается сложностью и архаичностью, содержит множественные арабо-персидские, огузские, чагатайские лексические и морфологические элементы. В творчестве позднего периода Кандалый обратился к общенародному языку. В его поэзию вошли слова из разговорной татарской речи, отрывки из эпических произведений, песни, пословицы, поговорки, идиоматические выражения.

При жизни Кандалый его произведения распространялись в рукописном виде. В 1859 в книгу С. Кукляшева «Диване хикәяте татар» («Сборник татарских рассказов») были впервые включены 8 строк поэта без указания имени. Ещё около 200 строк было опубликовано в «Записках Оренбургского отделения Императорского географического общества» (кн. 1, 1870), назывались они «татарскими и башкирскими народными песнями». В 1881 г. вышла «Мәгъшукнамә» («Книга влюблённых»), составленная в основном из стихов Кандалый, вновь без указания автора. Впервые авторство Кандалый указано в книге К. Насыри «Фәвакиһел җөласә» («Плоды бесед», 1884), в которую вошло свыше 1 тыс. строк Кандалый. В 1920-х гг. Академический центр Наркомата просвещения ТАССР вынес решение – изучить и систематизировать творческое наследие Кандалый. Но только в 1960 вышел первый сборник «Шигырьләр» («Стихотворения», 1960) под редакцией Х.У. Усманова. Наиболее полное издание произведений Кандалый подготовлено М.А. Усмановым – «Шигырьләр һәм поэмалар» («Стихотворения и поэмы», 1988), оно снабжено объёмным научно-исследовательским комментарием. В 1999 отдельной книгой была издана поэма «Сахибджамал».

## ЛИТЕРАТУРА


Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. Казань, 1975.

Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. Казань, 1922. 1 җилд.

Иртуган К. Шагыйрь Г. Кандалыйның кыскача тәрҗемәи хәле һәм шәхси хәяты // Безнең юл. 1927. № 8.

Бәхтиев И. Шагыйрь Г. Кандалый турында // Яңалиф. 1929. № 13.

Госман Х. Г. Кандалыйның яңа табылган әсәрләре // Совет әдәбияты. 1960. № 5.

Курбатов Х.Р. Г. Кандалый шигырьләрендә метрика һәм строфика // Татар теле һәм әдәбияты. Казань, 1977. 6 кит.

Тазюков Х. Г. Кандалый турында кайбер мәгълүматлар // Совет мәктәбе. 1978. № 6.

Татар әдәбияты тарихы. Казань, 1985. 2 том; Госманов М. Кандалый мирасын барлау юлында // Казан утлары. 1987. № 7.

## АВТОРЛАР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ

**Ахунов Азат Марс улы,** филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты, Шәрык һәм исламны өйрәнү кафедрасы доценты.

**Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы,** филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

**Бәширова Илида Басыйр кызы,** филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

**Вәлиди Җамал** (1887–1932), тел, әдәбият белеме галиме, педагог, тарихчы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе.

**Гыйльманов Дамир Шамил улы,** филология фәннәре кандидаты, Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты проректоры.

**Госман Хатип** (1908–1992), әдәбият белеме галиме, язучы, филология фәннәре докторы, профессор.

**Госманов Миркасыйм** (1934–2010), тарих фәннәре докторы, академик, археограф.

**Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы,** филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университетының татар әдәбияты кафедрасы профессоры.

**Мәҗитов Фәрит Хәбибулла улы,** Чардаклы районы, Абдулла авылы мәчете имам-хатыйбы.

**Миңнегулов Хатыйп Йосып улы,** филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты, татар әдәбияты кафедрасы профессоры.

**Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,** филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

**Мозаффарова Мингаян Гаяз кызы,** педагогика фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының Милли мәгариф лабораториясе өлкән методисты.

**Нурмөхәммәтова Нәҗия Сөнгат кызы,** Г. Кандалый оныгының оныгы, Ульяновск өлкә укытучыларының белемен күтәрү һәм камилләштерү институтының фәнни хезмәткәре.

**Садекова Айсылу Хөсәен кызы,** филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

**Сафиуллина Рузия Фәһим кызы,** филология фәннәре кандидаты, «Идел» журналының бүлек мөхәррире.

**Харрасова Рифә Фатхрахман кызы,** филология фәннәре кандидаты, доцент, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

**Хәсәнова Фәридә Фирдәвес кызы,** филология фәннәре кандидаты, доцент, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире.

**Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы,** филология фәннәре докторы, Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты профессоры.

**Шәфигуллин Равил,** шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Г. Кандалый исемендәге өлкә премиясе лауреаты, Ульяновск өлкәсе татар язучылары берләшмәсе рәисе.

**Шиһапова Чулпан,** Чардаклы районы, Абдулла авылы мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

**Яхин Фәрит Зәкиҗан улы,** филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

ЭЧТӘЛЕК

*Р.Ф. Сафин.* По следам наших предков… . . . . . . . . . . . . 5

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

Беренче бүлек

**Г. Кандалый һәм татар фәне**

*Ф.З. Яхин.* Г. Кандалый иҗаты һәм татар әдәбият белеме: әдәби-тарихи мәсьәләләр кысасында . . . . . . . . . . . . 13

*Х.Й. Миңнегулов.* Татар әдәбияты үсешендә Г. Кандалыйның урыны һәм роле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27

*М.И. Әхмәтҗанов.* Г. Кандалыйның иҗат стиле турында . . . 39

*Р.Ф. Харрасова.* Г. Кандалый иҗатында яктылык һәм караңгылык мифологемалары . . . . . . . . . . . . . . . . 43

*Ф.Ф. Хәсәнова.* «Бар гаебең ихласлык булган, шагыйрь!» яки мулла мәхәббәте турында уйланулар . . . . . . . . . . 63

*А.Х. Садекова, Р.Ф. Сафиуллина.* Религиозная философия творчества Габдельджаббара Кандалый . . . . . . . . . . . 73

*Ә.М. Закирҗанов.* Г. Кандалый иҗатында традиция һәм яңачалык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83

*И.Б. Бәширова.* Габделҗаббар Кандалый иҗаты – татар әдәби тарихының сагышлы бер дәвере . . . . . . . . . . . 96

*Р.Ф. Сафиуллина.* Габделҗаббар Кандалыйның мәхәббәт лирикасында фольклоризмнар . . . . . . . . . . . . . . . 114

*Ч. Шиһапова.* Якташ язучы иҗатын мәктәптә өйрәнү . . . . 132

*М.Г. Мозаффарова.* Мәгърифәтче Габделҗаббар Кандалый мирасын мәктәптә үзләштерү . . . . . . . . . . . . . . . 134

*А.М. Шарипов, Д.Ш. Гильманов.* Творчество Габдельджаббара Кандалый и деятельность современного педагогического вуза . 138

Икенче бүлек

**Г. Кандалый: халык хәтерендә һәм тарих сәхифәләрендә**

*Н.С. Нурмөхәммәтова.* Ерак бабам истәлекләре эзеннән... . 141

*Ф.Х. Мәҗитов.* Габделҗаббар Кандалый турында хатирәләр . 148

*Р. Шәфигуллин.* Сәхипҗамалның прототибы турында . . . . 150

Переводы стихов Габдельджаббара Кандалый . . . . . . . . . 154

Стихи хазрета *(Стихотворения Г. Кандалый в переводе Сергея Малышева)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154

Габдельджаббар Кандалый: второе приближение (*Переводы стихов и предисловие Алексея Саломатина*) . . 158

«Упаси от напастей лихих…» *(Стихи Г. Кандалый в переводе Максима Амелина)* . . . . . . . . . . . . . . . 164

*Ж. Вәлиди.*Татар әдәбиятының барышы (Габделҗәббар әл-Кандалый) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168

*Х. Госман.* Габделҗәббар Кандалый . . . . . . . . . . . 176

*М. Госманов.* Г. Кандалый: бер гомердә ике чор . . . . . . 197

*А.М. Ахунов.* Габдельджаббар Кандалый . . . . . . . . . . 232

Авторлар турында мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . 236

**ГАБДЕЛЬДЖАББАР КАНДАЛЫЙ**
**Через призму современности**

Редактор *М.Г. Муртазин*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *Л.Ш. Давлетшиной*

Подписано в печать 06.10.2015.
Формат 60×84 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 13,95. Уч.-изд. л. 11.
Общий тираж 500 экз. Первый завод 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20